ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 1 (348)
ГЫЙНВАР 2021

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҢ ЯХШЫЛАР АРАСЫНДА – БЕРЕНЧЕЛӘР

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Мәршидә Кыямова,
Нурия Мифтахетдинова, Луиза Шарова
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: «Абилимпикс» конкурсында җиңү яулаган
Гөлназ Сәгыйрова. Алексей Завалишин фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 450 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № Е-105
Басарга кул куелды: 25.01.2021
Басмадан чыкты: 28.01.2021

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә
2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4800 данә
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ИКЕНЧЕ ГАСЫР. КҮП ХӘРЕФЛӘР ДӨНЬЯСЫ

«Татарстан» журналы басмабызга быел гына язылган яңа укучыларына да, безнең белән бергә узган елдан, узган гасырыбыздан яңа елга, яңа гасырыбызга аяк атлаган барлык укучыларына да рәхмәтен белдерә. Журналга һәм гомумән укуга тугрылыгыгыз өчен рәхмәт әйтәбез. Чөнки укырга ярату гадәте барыбызга да хас түгел. Инстаграмдагы посттан да озынрак текстны укырга күпләрнең түземлеге җитеп бетми. Хәрефләр күп – зур тизлек белән бер-бер артлы алмашынып торган сурәтләрне карарга ияләшеп киткән баш мие өчен бу артык авыр эш.

Шуңа күрә укучыбызның әле һаман укырга яратуы белән горурланабыз. Димәк, ул уйлый, үсә, камилләшә һәм ял итә дә белә. Уку бит мизгел саен шалтырап торган телефоннарны һәм башка ыгы-зыгыны кабул итми. Җылы җәймәгә төренеп, кәнәфиегездә, диваныгызда җайлабрак урнашыгыз да укуга чумыгыз. Әйе-әйе, «Татарстан»ның нәкъ узган гасырындагыча калган күп хәрефләр дөньясына! Күңелле яллар сезгә!

Сезнең күп укый торган редакциягез.

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла
Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **942 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

100 яшь «Татарстан» журналына

#татарстанның 100 җәүһәре

#бары тик Татарстанда

«Yes, we can!» – «Без булдырабыз!»

Сайлау алды кампаниясендә президент Барак Обама кулланган «Yes, we can» («Без булдырабыз!») шигаренең, йомшак кына әйткәндә, оригиналь булмавы 2009 елның октябрендә Казанга АКШ дәүләт секретаре Хиллари Клинтон килгәч ачыклана. Минтимер Шәймиев кунакка постаментына «Без булдырабыз!» дип язылган канатлы барс сынын күрсәтә. «Сез бу шигарьне алты ел элек уйлап тапкансыз, кайткач, президент Обамага әлеге шигарь өчен сезгә бурычлы булуы хакындагы хәбәрне тапшырырмын», – дип, беренчелекне таныырга мәҗбүр була Хиллари Клинтон.

www.protatarstan.ru

© «Татарстан» журналы

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

6. Йортта кем хуҗа
Россия губернаторларының милли рейтингы лидерлары

10. «Алабуга» – алдынгылар башында
РФ махсус икътисадый зоналары рейтингы нәрсәне күрсәтте

12. «Цифрлы алгарыш» проекты
Кем гранд-финалга җитте

14. Хәзерге заман баһадирлары
Урта гасыр сугышлары фестивале кемне җәлеп итә

16. IT-технологияләр көнкүреш калдыкларына килеп җитте
«Чүп-чарсыз Россия» мобиль сервисы» проектын гамәлгә ашыруны кемгә тапшырдылар

18. «Абилимпикс»ны яулау
Гөлназ Сәгыйрованың җиңү шатлыгы

20. Ел гүзәле,
яисә Илебез студентлары арасында иң чибәр кызның адресын ничек белергә

22. Хәрби реконструкция дәресләре
2020 елның иң яхшы туристлык вакыйгасы нәрсә белән истә калды

24. «Алтын битлек» тылсымы
РФнең иң абруйлы театраль премиясенә кем лаек булды

26. Бүгенге заман герое
Иван ничек үз энеләрен янгыннан коткарган

30. «Космос разведчиклары» орбитасы
Иң яхшы өстәмә белем бирү педагогы – Казаннан

32. Мәңгегә истә кала торган милли код
Татарның каклаган казы белән чәкчәге ничек җиңүче булды

игелекле эшләр

40. Тормыш линиясе
Индус Таһиров белән сөйләшү

43. Туган телләр елы
Татар кызы Мәскәүдә кемнәрне ана теленә өйрәтә

46. Милли традицияләр
Чит илләрдә Яңа елны ничек каршылыйлар

49. Фотопроект
Абдулла Дубин тупланмасындагы Яңа ел открыткалары

мәңгелек кыйммәтләр

58. Тарих сәхифәләре
Яңарыш журналисты: Фатыйх Кәрими

62. Кече Ватан патриотлары
Сара Садыйкова дәвере

68. Милли мирас
Татар алфавиты нинди үзгәрешләр кичергән

72. Китап киштәсе
Кышкы елларда – затлы китап

82. Татарстан авыллары
Күпмилләтле Чыпчык



АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

31.12

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Президенты, – татарстанлыларга Яңа ел мөрәҗәгатендә:

– Без барыбыз да күпмилләтле илебез белән бердәм фикерләр һәм эшләр белән яшибез. Без бай тарихи-мәдәни һәм рухи мирасны, милләтара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклыйбыз һәм үстерәбез. Шуңа күрә 2021 ел Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде.

Фото: ТР Президентының рәсми сайты

12.01

Рәвгать Ханов, Минзәлә районының Иске Мунча авылы фермеры:

– Мин үземне эшлекле кеше дияр идем. Бу сыйфат нәселдән килә дип уйлыйм. Эшкә мөнәсәбәтем ягыннан мин ата-аналарым буынына охшаган. Бер ялсыз эшләсәләр дә, аларның хезмәте бик түбән бәяләнгән. Ә хәзер авыл хуҗалыгы тармагында эш сөйгән кешегә хезмәт хакы да тиешенчә түләнә.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

Фото: РФ Авыл хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайты

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

13.01

Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Дәүләт Советы Рәисе, – Россия Матбугаты көне белән котлап:

– Безнең уртак максатыбыз – патриотизмны, бердәмлек һәм гражданлык тойгыларын булдыру, зур һәм кече Ватаныбызга мәхәббәт тәрбияләү, милләтара тынычлыкны һәм конфессияара татулыкны ныгыту. Массакүләм мәгълүмат чараларында бу мәсьәләләрне яктырту Бөтенроссия халык санын исәпкә алу алдыннан аерым әһәмияткә ия.

акыллы гамәләр /

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

Бу санда тәкъдим итәбез:

Россия губернаторлары милли рейтингын ни өчен Татарстан Президенты җитәкләде

«Алабуга» ничек илнең иң яхшы сәнәгать-җитештерү тибындагы МИЗына әверелде

Кемнәр иң яхшылар арасында беренче булды

ИЛ КҮЛӘМЕНДӘ
ИҢ ЯХШЫЛАР



Барыбыз да җиңел сулап саубуллашкан 2020 елга бәя биргәндә, күпләр, мөгаен, бик үк шатлыклы булмаган мизгелләрне дә искә төшерерләр. Кызганыч, алар узган елның унике аенда шактый булды. Әмма тормыш мантыйгы шундый: аны, тормышны, җиңелүләр, уңышсызлыклар һәм авырлыклар түгел, ә каршылыкларны үтә белү, түземлелек, сабырлык һәм җиңүләр алга этәрә. Ә инде Татарстан һәрвакыттагыча җиңә белүен проблемалы 2020 елда да раслый алды.

Әлеге җиңүләрнең кайберләрен – иң-иңнәрен – «Татарстан» яңа 2021 елга аяк басканда укучыларыбызның исләренә төшерергә ниятләде. Әлбәттә, аерым мәгънә салып: һәр казаныш – безнең һәм сезнең мөмкинлекләрне раслаучы күрсәткеч. Һәм киләчәккә иң яхшы, иң өметле фараз. Без җиңәбез һәм җиңәчәкбез, чөнки каршылыклар кичәргә, түзәргә, сабыр итәргә, даһи ачышлар ясарга һәм зирәк карарлар кабул итәргә күнеккәнебезне әле онытмаганбыз. Димәк, барысы да яхшы булачак.

БЕРЕНЧЕЛӘР АРАСЫНДА ИҢ ЯХШЫЛАР, ИҢ ЯХШЫЛАР АРАСЫНДА БЕРЕНЧЕЛӘР

ГУБЕРНАТОРЛАРНЫҢ 2020 ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

1 УРЫН

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

мөһим

Рейтингны төзүчеләргә төбәкләрдәге вазгыять һәм тенденцияләр турында үз фикерләрен урыннардагы экспертлар җиткерә. Бу ике мең ярымнан артык кеше (экспертлар саны даими үсә, алар арасында ротацияләр үткәрелеп тора), алар алдан кисәтүләрсез, катгый яшеренлек шартларында төбәкләрдәге вазгыять һәм тенденцияләр турындагы фикерләрен рейтингны эшләүчеләр белән уртаклашалар.

МИЛЛИ РЕЙТИНГЫ

2 УРЫН

СЕРГЕЙ СОБЯНИН
ФЕДЕРАЛЬ ӘҺӘМИЯТТӘГЕ МӘСКӘҮ ШӘҺӘРЕ

3 УРЫН

ЕВГЕНИЙ КУЙВАШЕВ
СВЕРДЛОВСК ӨЛКӘСЕ

4 УРЫН

АЛЕКСАНДР МООР
ТӨМӘН ӨЛКӘСЕ

5 УРЫН

АЛЕКСЕЙ ДЮМИН
ТУЛА ӨЛКӘСЕ

6 УРЫН

АЛЕКСАНДР ДРОЗДЕНКО
ЛЕНИНГРАД ӨЛКӘСЕ

7 УРЫН

РАМЗАН КАДЫЙРОВ
ЧЕЧЕН РЕСПУБЛИКАСЫ

РЕЙТИНГ ТУРЫНДА

Губернаторларның милли рейтингы – Россия Федерациясе субъектлары башлыкларының эшчәнлегенә бәя бирүгә багышланган еллык тикшеренү. «Милли рейтинг» масштаблы проекты кысаларында аны «Рейтинг» Мәгълүмати коммуникацияләр үзәге (МКҮ) үткәрә. Лидерлар һәм аутсайдерлар читтән торып тутырылган анкеталарга, эксперт җәмәгатьчелегеннән сораштыруларга таянып билгеләнә. «Губернаторларның милли рейтингы»на махсус рәвештә төрледән-төрле һөнәри һәм социаль катламга караган мөмкин кадәр күбрәк сандагы экспертлар җәлеп ителә, дип раслый рейтингны төзүчеләр. Экспертларның мондый составы тикшеренүләр нәтиҗәләрен, экспертлар җәмәгатьчелегенең күбрәк хәбәрдар булуын һәм анализ ясый алырга әзерлеген истә тоткан хәлдә, «гади кешеләр» фикеренә максималь якын китерергә мөмкинлек бирә.

Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: анкеталарда теге яисә бу регион башлыгының эше формаль яктан гына бәяләнми, анда экспертларга үз фикерләрен нигезләргә дә мөмкинлек тудырыла. Мондый нигезләүләр теге яисә бу РФ субъекты җитәкчесенең уңышлары һәм уңышсызлыклары сәбәпләрен тирәнтен ачыкларга ярдәм итә. Моннан тыш, әлеге нигезләмәләр, экспертлар тарафыннан үткәрелгән персональ аналитик интервью мәгълүматлары кебек үк, «Милли рейтинг»ның аналитик өлешен төзүдә нигез булып тора.

Читтән торып анкеталаштыруның конфиденциаль статусы респондентларның ихласлыгын арттыруның мөһим ысулы булып тора, дип саныйлар тикшеренү авторлары. «Үз фикерләрен киң җәмәгатьчелеккә җиткерергә теләгән экспертлар, «Рейтинг» МКҮ редакциясе белән килештергәннән соң, моны эшләү мөмкинлеге ала.

Шунысын да истә тотарга кирәк: рейтингны төзүчеләр әледән-әле тикшеренүләрнең гомуми нәтиҗәләренә каршы килгән позициядә торучы экспертларга да сүз бирәләр. Кайчак рейтинг битләрендә бөтенләй капма-каршы фикердә торучы экспертлар чыгыш ясый. Мондый тәҗрибә уйлап эшләнелгән, һәм бу җәмәгатьчелеккә хас максималь киң фикер төрлелеген халыкка җиткерергә булыша. «Милли рейтинг» кысаларында җәмәгатьчелек каршында үз фикерен белдерүче экспертлар моны тикшеренүләрнең азаккы нәтиҗәләре билгеле булганчы эшлиләр».

– Бездә үз карамагындагы территорияләрнең чын хуҗасы булган губернаторлар аз. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов бу яктан искәрмә булып тора.

Михаил БОЧАРОВ, социолог, Төбәк проблемалары институты генераль директоры урынбасары:

– Бездә үз карамагындагы территорияләрнең чын хуҗасы булган губернаторлар аз. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов бу яктан искәрмә булып тора. Ул пандемия чорында әлеге дә баягы иң альтернатив гамәлләр планын уйлап таба алды. Сүз уңаеннан, бер сәгать эчендә өйгә кирәкле даруларны китерергә сәләтле «Сбер Еаптека» дип аталган даруханәләр хабы, илдә беренчеләрдән булып, Татарстан башкаласында Рөстәм Миңнеханов һәм Саклык банкы идарәсе рәисе урынбасары Ольга Голодец катнашында ачылды. Миңнеханов халык мәнфәгатьләрен дә, үзәк мәнфәгатьләрен дә истә тота алды – губернатор-сәясәтче нәкъ менә шулай эшләргә тиеш тә, чөнки эшендәге барлык җитешсезлекләр аның рейтингында тискәре чагылыш табачак, ә җиңүләре, киресенчә, аның урынын ныгытачак. Тиз арада кырыс чаралар керткән һәм аннан соң шактый тиз аларның иң мөһимнәрен гамәлдән чыгарган Татарстан ысулы иң дөрес адымнарның, адекват карар үрнәкләренең берсе булды.

мөһим

Читтән торып анкеталаштыруның конфиденциаль статусы респондентларның ихласлыгын арттыруның мөһим ысулы булып тора. Рейтинг таблицалары буенча азаккы карарны «Рейтинг» МКҮнең Экспертлар советы кабул итә, ул шулай ук читтән йогынтыларны булдырмас өчен анонимлык принципларына таянып эшли. Танылган сәясәт белгече, Икътисад югары мәктәбе профессоры Олег Матвейчев аның рәисе булып тора. Экспертлар советы тарафыннан анкеталаштыру йомгакларына төзәтмәләр кертү тапшырылган мәгълүматның һәм куелган бәяләрнең дөреслеген тикшерү өчен генә эшләнми. Әлеге орган тикшеренүләрне төрле манипуляцияләрдән якларга да тиеш. Калган яктан тикшеренү объектларының рейтинг таблицаларындагы урыны анкеталаштыру йомгакларының уртача арифметик нәтиҗәләренә нигезләнеп билгеләнә.

Александр МАЛЬКЕВИЧ, журналист, сәясәт белгече, РФ Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Милли кыйммәтләрне яклау фонды президенты:

– Эпидемиологик яктан тотрыклы булмаган 2020 ел дәвамында Татарстанда COVID-19 га кагылышлы вазгыять имин булып калды: республика пациентларның гомуми саны буенча РФ субъектлары арасында 73 нче урынны били. Ковидка каршы көрәш юнәлешендә Казанда Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсенең яңа бинасын төзү проектының әһәмиятле гамәл булуы очраклы түгел. Аны рекордлы кыска срокларда – 100 көн эчендә җиткерделәр. Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсенең яңа бинасы – 15 мең квадрат метр мәйданны билгән дүрт катлы бина ул, 232 авыруны кабул итәргә сәләтле.

Катлаулы вазгыятькә дә карамастан, 2020 елда Татарстан Республикасында төзелеш эшләре бер генә көнгә дә туктатылмады, алар куркынычсызлык кагыйдәләрен максималь дәрәҗәдә үтәп алып барылды. Медицина үзәген сафка бастыру белән беррәттән, узган елның иң мөһим проектлары арасында ТР башкаласы өчен гаять әһәмиятле, 1969 елдан бирле көтелгән Зур Казан боҗрасын (ЗКБ) төзүне билгеләп үтәргә кирәк. ЗКБ – шәһәрдә боҗра буенча өзлексез хәрәкәт итү магистрале, трассаның салынып беткәннән соңгы гомуми озынлыгы 34 километрга якын, аның буенча Россиядә иң озын трамвай юлы узачак. 2020 елның 30 августында ЗКБның беренче чираты тапшырылды, 2020 елның 7 декабрендә тест режимында икенче этапта хәрәкәт ачылды.

2020 елда алданган өлешчеләрне торак белән тәэмин итү буенча башкарылган эш елның җитди казанышы булып тора. Бу елда Казанда, Яр Чаллыда һәм республиканың Питрәч районында яшәүче 400 гаилә өй туйларын үткәрә алды. Ел ахырына кадәр Алабугада тагын бер йортны кулланучыларга тапшыру планлаштырылган.

РФнең әлеге субъектының роле һәм әһәмияте турында сөйләгәндә бер мөһим нәрсәне әйтик: 2020 елда Татарстан РФ бюджетыннан, COVID-19 пандемиясе китергән зыянны бетерүгә дип, 13,6 млрд сум акча алды. Бу ил төбәкләре арасында дәүләт бюджетыннан бүлеп бирелгән иң зур дотация. Ике транш кысаларында барлыгы 56 субъектка 300 млрд сум акча бүленде. Татарстанга акчаның иң зур өлеше туры килде. Бүленгән акчаларның күләме буенча икенче урында Краснодар крае (11,7 млрд сум) тора. Лидерлар өчлегенә тагын Свердловск өлкәсе (9,9 млрд сум) керә. Бишлектә исә Башкортостан (9,7 млрд сум) һәм Кемерово өлкәсе (9 млрд сум) санала. Төбәкләр өчен өстәмә ярдәм бүлеп бирү Россия Президенты Владимир Путин күрсәтмәсе белән эшләнде. Шул ук вакытта күрсәтмәдә бер шарт билгеләнде: игътибарны инвестицион чыгымнар үсешенең югары темпларын раслаган территорияләргә күрсәтергә.

2021 елда алданган өлешчеләр проблемасы Татарстанда тулысынча хәл ителәчәк, моның өчен тагын 8 йортны төзеп бетерергә кирәк.

Дөньяда һәркемгә дә кагылган эпидемиологик катастрофа елыннан соң килүче 2021 елның Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителүе символик мәгънәгә ия. Бу турыда төбәк башлыгы Рөстәм Миңнеханов 2020 елның сентябрендә ТР Дәүләт Советына еллык Юлламасында белдерде. Татарстан Президенты республикада яшәүче барлык милләт вәкилләренең: русларның, чуваш, удмурт, мордва, мари һәм башкаларның мәдәниятләрен һәм телләрен саклау һәм үстерү өчен шартлар тудырылырга тиеш, дип басым ясады.

Моңа бәйле рәвештә 2021 елның апреленә билгеләнгән киң колачлы вакыйга – халыкның җан исәбен алу бигрәк тә актуаль. Шул ук вакытта гражданнар өчен гадәти сораштыру форматы кулланылмаячак. Бу халык санын алуда беренче мәртәбә цифрлы технологияләр ярдәмгә киләчәк: гражданнар әлеге процедураны дәүләт хезмәтләре порталында мөстәкыйль эшли алачак, монда үзең өчен дә, гаилә әгъзалары өчен дә исәпкә алу битләрен тутыру мөмкинлеге бирелә. Фатирлар буйлап йөргәндә кәгазь документлар түгел, планшетлар кулланылачак. Планшетларга исәпкә алу битләрендә хаталарны булдырмаска, мәгълүматны җыю һәм эшкәртүнең сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирә торган махсус программа урнаштырыла. 2010 елгы җан исәбен алу йомгаклары буенча республика халык саны буенча Россиядә 8 нче урынны били иде. Бу юлы ничек булыр, карарбыз.

Исегезгә төшерик, Татарстан илнең иң күпмилләтле территорияләренең берсе булып тора. 2010 елгы Бөтенроссия халык санын алу мәгълүматлары буенча республикада 173 тән артык милләт вәкиле гомер итә.

«АЛАБУГА» – ИЛНЕҢ ИҢ ЯХШЫ МАХСУС ИКЪТИСАДЫЙ ЗОНАСЫ

2020 елда Россия махсус икътисадый зоналары арасында инвестицион җәлеп итүчәнлек буенча, IV Милли инвестицион рейтинг нәтиҗәләренә караганда, «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы МИЗ иң яхшысы дип табылды.

МӨҺИМ

«Алабуга» әйдәп баручы дөньякүләм инвестицияле мәйданчыклар рейтингында даими рәвештә катнашып килә – МИЗ Financial Times төркеменә керүче fDi журналы версиясе буенча алты мәртәбә эре проектлар өчен Европада иң яхшы мәйданчык буларак танылды. Шулай ук «Алабуга» Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан ясалган анализ йомгаклары буенча иң нәтиҗәле МИЗ дип табылды.

Сергей Галкин, Россия Федерациясе икътисадый үсеш министры урынбасары:
– Махсус икътисадый зоналарның милли рейтингы – бизнесны алып баруның уңайлыгы ягыннан мәйданчыкларның җәлеп итүчәнлегенә бизнесның үзе һәм экспертлар тарафыннан бәйсез бәя бирү ул. Икътисадый үсеш министрлыгы әлеге бәйсез бәяләмәнең нәтиҗәләрен игътибар белән күзәтә. Безнең өчен читтән объектив карашның булуы, бизнес һәм регионнар ягыннан кире элемтә урнаштырылуы мөһим. Болар барысы да МИЗларда инвестицияле эшчәнлекне стимуллаштыру өчен уңайлы шартларны тәэмин итү өчен кирәк.

СӘНӘГАТЬ-ҖИТЕШТЕРҮ ТИБЫНДАГЫ МИЗ

МИЗ исеме	Россия регионы	Рейтингтагы урыны	Рейтингтагы урынының үзгәрүе	Гомуми балл
1 ТӨРКЕМ. МИЗның югары инвестицион җәлеп итүчәнлеге (100%тан күбрәк)				
«Алабуга» СҖТ МИЗ	Татарстан Республикасы	1	0	10,73
«Липецк» СҖТ МИЗ	Липецк өлкәсе	2	0	10,34
«Тольятти» СҖТ МИЗ	Самара өлкәсе	3	+3	9,42
«Ступино Квадрат» СҖТ МИЗ	Мәскәү өлкәсе	4	-1	9,10

РЕЙТИНГ ТУРЫНДА

Рейтингны Россия Икътисадый үсеш министрлыгы Россия кластерларын һәм технопаркларын үстерү ассоциациясе белән берлектә төзи. Россиянең 13 регионында урнашкан 16 махсус икътисадый зона эшчәнлеге 28 күрсәткеч буенча экспертлар тарафыннан бәяләнде. Әлеге күрсәткечләр потенциаль инвесторга үз җитештерүләрен урнаштыру өчен иң яхшы урынны сайларга булышырга тиеш. Экспертлар МИЗ резидентлары эше күрсәткечләрен, икътисадый зона объектларына һәм идарә органнары эшчәнлегенә салынган акчаларның рентабельлеген, җәлеп ителгән инвесторларның һәм ачылган эш урыннарының санын, инвестицияләр һәм капиталь кертемнәр күләмнәрен, товарларны сатканнан соң кергән керемнәрне, федераль һәм региональ бюджетлар акчаларын тотуны, салым һәм таможняга чигерелгән акчаларның күләмнәрен чагыштырдылар.

ҖИҢҮЧЕ ТУРЫНДА

Узган елда рейтингта беренче урынны алган «Алабуга» махсус икътисадый зонасы әлеге позициясе дүртенче ел рәттән беркемгә дә бирми. Җиңүче МИЗда эшкуарлык эшчәнлеген алып бару һәм җир ресурсларын нәтиҗәле куллану өчен уңай шартлар тудырылуын экспертлар аеруча басым ясап билгеләп үттеләр. Җәлеп ителгән резидентлар саны «Алабуга»да иң зурысы, ә аның Россия – Төркия мөнәсәбәтләрен үстерүгә керткән өлеше РФ Президенты Владимир Путин тарафыннан да югары бәяләнде. Россиянең сәнәгать-җитештерү тибындагы 10 махсус икътисадый зонасында алынган барлык керемнең – 72%ы, шулай ук резидентлар тарафыннан фактта кертелгән инвестицияләрнең 50%ы «Алабуга»га туры килә. Бүген биредә 33 предприятие эшли, резидентлар тарафыннан 212,4 млрд сум акча кертелгән, 7 меңнән артык эш урыны булдырылган.

МӨҺИМ

«Алабуга» СҖТ МИЗның югары инвестицион җәлеп итүчәнлеге, беренче чиратта, резидентларга идарәче компания тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең киң спектры белән аңлатыла: энергияне транспортлау, логистика һәм таможня үзәге хезмәтләре, мәгълумати технологияләр белән идарә итү өлкәсендәге хезмәтләр, өстәмә хезмәт күрсәтү, капиталь төзелеш белән идарә итү хезмәтләре, дәүләт үсеш институтлары белән уртак финанслауга ирешү өчен резидентларга ярдәм күрсәтү һәм башкалар.

ҮСЕШНЕҢ ӨСТЕНЛЕКЛЕ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

Полимерлар эшкәртү

Автомобиль төзелеше

Төзелеш материаллары

Композит материаллар

АЧЫЛГАН ЕЛЫ **2005 ел.**

РЕЗИДЕНТЛАР САНЫ **66**

ШУЛ ИСӘПТӘН ЧИТ ИЛЛӘРДӘН **27**

МӘСКӘҮГӘ КАДӘР АРА ЕРАКЛЫГЫ **1040 км**

КАЗАНГА КАДӘР АРА ЕРАКЛЫГЫ **213,4 км**

РЕЗИДЕНТЛАР САНЫ	2012 ел.	2013 ел.	2014 ел.	2015 ел.	2016 ел.	2017 ел.	2018 ел.	2019 ел.
	33	36	43	47	58	64	66	68

ТУПЛАНГАН НӘТИҖӘЛӘР БУЕНЧА МИЗда КЕРТЕЛГӘН ИНВЕСТИЦИЯЛӘР КҮЛӘМЕ*

5,1% млн сум 8 626
Региональ бюджет акчалары

10,1% млн сум 17 078,0
Федераль бюджет акчалары

79,8% млн сум 134 690,6
Резидентларның бюджеттан тыш инвестицияләре

5,0% млн сум 8 395,9
Идарәче компания инвестицияләре

САЛЫМ ТАШЛАМАЛАРЫ, 2019 ел

81,2% млн сум 13 995,9
МИЗ резидентлары түләгән салымнар, таможня җыемнары, иминият кертемнәре

18,8% млн сум 3 249,5
Салым, таможня җыемнары, иминият кертемнәре буенча МИЗ резидентларына бирелгән ташламалар

ТУПЛАНГАН НӘТИҖӘЛӘР БУЕНЧА МИЗда ШӘХСИ ИНВЕСТИЦИЯЛӘР ДИНАМИКАСЫ, МЛН СУМНАРДА



Тупланган нәтиҗәләр буенча яңа ачылган эш урыннары **6 917**

Резидентларның керемнәре, 2019 ел **82 597,29 млн сум**

шул исәптән экспорттан **8 068,4 млн сум**

МИЗ территориясендә хезмәт җитештерүчәнлеге **11,9 млн сум/кеше**

* Чыганагы федераль һәм региональ бюджет саналган акчаларның фактта үзләштерелгән күләме

XXI ГАСЫР МАРАФОНЫ

Татарстанның ике командасы «Цифрлы алгарыш» Бөтенроссия конкурсының гранд-финалында җиңде.

Берничә этапта үткән ярыш – хакатонда – цифрлы икътисад өлкәсендә эшләгән IT-белгечләр, дизайнерлар һәм идарәчеләрдән торган командалар катнашты. Аларның бурычы – Россиянең эре компанияләре, министрлыклары һәм ведомстволары тарафыннан тәкъдим ителгән кейсларга ярашлы рәвештә цифрлы продуктлар тудыру. 2020 елда «Цифрлы алгарыш» икенче мәртәбә үткәрелде, пандемиягә бәйле рәвештә – онлайн-форматта. Гранд-финалда командалар каршына бурычларны «Россия почтасы», «Росатом», «Саклык банкы», «Россия челтәрләре», «Газпромбанк», «Ростелеком» ГАҖ, «ВКонтакте», «Россия ЭЭМ» һәм башкалар куйды. InnoAI һәм IT Navigator дип аталган Татарстан командалары үз төркемнәрендә беренче һәм икенче урыннарны алды. Кейсларны чишү өчен 48 сәгать вакыт бирелде. Мәҗбүри шарт – финал питчингы, биш минут эчендә тармак экспертлары каршында яңа продуктны презентацияләү.

Иннополисның InnoAI командасы беренче урынны яулады, ул Россия ЭЭМның Мәгълүмати технологияләр, элемтә һәм мәгълүмат саклау департаменты кейсының иң яхшы чишелешен – туры сөйләмне кыек сөйләмгә күчерү өчен программа эшләп күрсәтте. Җиңүчеләргә 750 мең сумлык сертификат тапшырылды.

– Безнең һөнәри бурычларыбыз компьютерның «күз күреме» белән бәйле, әмма безгә үзебез өчен яңа булган лингвистик анализ өлкәсендә эшләп карау кызыклы булды. Без Python-алгоритм төзедек, аның нейрочелтәрләре тәкъдим ителгән материалны рус теленең билгеле бер кагыйдәләрен һәм ЭЭМ текстларының үзенчәлеген

Фото: «Цифрлы алгарыш» конкурсының матбугат хезмәте

исәпкә алып эшкәртергә сәләтле. Кулланучыга бу алгоритм текстларны, аудиоязмаларны, фотографияләрне, сканланган сурәтләрне йөкләү тәрәзәсе булган, гади идарә ителешле интерфейс буларак күренә, – дип сөйли InnoAI командасында катнашучы Ибраһим Миргалимов. – Без нигездә яхшы һөнәри әзерлегебез һәм башка хакатоннарда катнашу тәҗрибәсе аркасында җиңдек, дип уйлыйм. Командабыз әгъзасы Семён Киселёвны әлеге кейс бик илһамландырды, һәм әлеге энтузиазм аңа эшне уңышлы башкарып чыгарга булышты.

Яр Чаллы һәм Әлмәт белгечләреннән торган IT Navigator командасы «Россия челтәрләре» тарафыннан куелган бурычны чишүдә катнашты һәм икенче урынга лаек булды. Алар компания хезмәткәрләренең рационализаторлык тәкъдимнәрен йөкләү һәм эшкәртү өчен кушымта булдыру кейсын чиштеләр. Икенче урынга 500 мең сумлык сертификат тапшырылды.

– Бу безнең икенче хакатон. Безнең бизнес-процессларны оптимальләштерү буенча һөнәри тәҗрибәбез бар, безнең тректа нәкъ шул кирәк булды да. Иң катлаулысы техник өлеш түгел, кушымта ия булырга тиешле характеристикаларны сайлау булды. Эшкә керешүгә бик күп идеяләр һәм фикерләр туды, ләкин без боларның барысын да билгеле бер вакыт эчендә гамәлгә ашыра алмаячагыбызны аңладык. Безгә өч мәртәбә экспертлар белән аралашу, прогрессны күрсәтү һәм кире элемтә алу мөмкинлеге бирелде. Бу нык ярдәм итте – шул рәвешле без компания өчен нәрсә мөһим булуын һәм нәрсә өстәмә кыйммәт тудырачагын ачыкладык, – дип аңлатты IT Navigator командасында катнашучы Ольга Кузнецова. – Без шулай ук уңышыбызның 80 проценты диярлек сыйфатлы презентациягә бәйле булачагын аңлый идек. Моны ничек идеаль рәвештә башкарып чыгу идеясе миндә проектны яклау көнендә, иртәнге биштә туды. Нәтиҗәдә барысы да яхшы үтте. Без әлеге проект буенча «Россия челтәрләре» белән хезмәттәшлекне дәвам итәргә өметләнәбез, ләкин ниндидер сәбәпләр аркасында элемтә өзелә икән, башлаган эшебезне үзебез эшләп бетерәчәкбез. Хакатон вакытында аның базарда перспективалы продукт булуына инандык.

– Катнашучыларның күнекмәләрен үстерү өчен, без конкурс барышында гамәли бурычлар куюны мөһим саныйбыз. Бүген бөтен дөнья катнаш онлайн-офлайн форматта яши. Бу IT-карарларга һәм аларны хәл итәргә сәләтле командаларга Россиядә моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә ихтыяҗ булуын раслый. Шулай итеп, үзебезне күрсәтү, сәләтләребезне ачу һәм ил күләмендә уңыш казану өчен уникаль мөмкинлекләребез бар, – дип билгеләп үтте РФ Президенты Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары Сергей Кириенко хакатонда җиңүчеләрне котлау тантанасында.

БЕЗНЕҢ ЗАМАН РЫЦАРЬЛАРЫ

2020 елда «Бөек Болгар» халыкара урта гасыр сугышлары фестивале вакыйгалы туризм өлкәсендә Russian Event Award IX Милли премиясенең Гран-при иясе булды. Әлеге номинациядә Россия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Молдованың 59 төбәгеннән 390 проект катнашты.

Елына бер тапкыр меңнәрчә халык Иделнең биек ярындагы борынгы Болгарның тынычлыгын боза: күпгасырлык корылмалар янында ук диярлек рыцарь отрядлары урнаша, шау-шулы ярминкә гөрли, көрәш һәм турнирлар өчен мәйданчыклар әзерләнә. Сорнай, гөслә, бузука, жалейка, флейтада уйнаучы музыкантлар иртә таңнан төн уртасына кадәр зур сәхнәдә берберсен алыштыра...

«Бөек Болгар» урта гасыр сугышлары фестивале – тамашачылар өчен гаять кызыклы аттракцион, барыннан да бигрәк ул үзенә генә хас мохите белән таң калдыра. Биредә уздырылган берничә сәгатьтә үткәннәр турында шул ук вакыт эчендә тарихи хезмәтләрне өйрәнгәндәге кадәр үк яңалык белергә мөмкин. Фестивальдәге бөтен нәрсә – аутентик, ягъни IX–XV гасырлар оригиналының төгәл күчермәсе булып тора. Бу кием-салымга да, реконструкторлар командалары лагерендагы көнкүреш предметларына да һәм, әлбәттә инде, сугышчыларның экипировкасы һәм коралларына да кагыла. Фестивальнең ике көнендә тамашачылар әлеге предметларны ясау буенча бик күп мастер-классларда, тарихи биюләр өйрәнүдә яки урта гасырлар костюмы конкурсында, укчылар турнирында яисә сөңге ату ярышында катнаша ала.

«Бөек Болгар»ның аудиториясе даими үсә. 2019 елда анда 30 меңнән артык кеше булган. Быелгы пандемия елында, сентябрь азагында булса да, җиденче фестиваль барыбер үткәрелде. Ул Татарстаннан һәм башка төбәкләрдән 20 меңнән артыграк тамашачыны җыйды.

«Фестиваль искиткеч булды. Урыны да бик уңышлы, күп нәрсә белән танышырга мөмкин. Әлбәттә инде, иң җәлеп иткән урын – ярыш мәйданы. Тимер киемнәргә төренгән алыпларның бер-берсен балта белән тукмавын тамаша

Фото: «Бөек Болгар» фестиваль төркеме ВКонтактеда vk.com/greatbolgar

кылу бик тәэсирле булды», – дип язып калдырган Ульяновскидан килгән Марк Кулаков.

«Искиткеч фестиваль! 26 сентябрьдә Самарадан зур экскурсия төркеме булып килдек! 4 сәгатьтә 290 чакрым ара үтеп килүебезгә бер дә үкенмәдек! Бөтен туристлар таң калды! Самара фестивальне оештыручыларның һәркайсына зур респект юллый! Бөек һәм кунакчыл Болгар», – дип яза Татьяна Сафина.

«Фестивальне 2014 елдан бирле калдырганым юк, бу – календаремда кызыл маркер белән билгеләнгән чара. Һәм һәрвакыт төн кунарга дип киләбез – концертны, фаер-шоуны һәм палаткада йоклауны ел буена көтеп алабыз. Хисләр, драйв – искиткеч! Без бу ике көнне бик рәхәттә үткәрдек, оештыручыларга, спортчыларга, сәүдә вәкилләренә рәхмәт, һәм һава торышы өчен Аллаһ Тәгаләгә аерым рәхмәт!)» – дип яза Казаннан Роза.

Әмма «Бөек Болгар»га бүтән төбәкләрдән һәм хәтта чит илләрдән профессиональ реконструкторлар килмәсә, боларның берсе дә булмас иде. 2017 елдан чара халыкара статуска ия: биредә HMB Russia химаясендә бишкә биш клуб командалары арасында тарихи урта гасыр сугышлары буенча Европа Гран-при ярышлары һәм бергә бер сугышлары буенча Донжон кубогы этабы узды. 2020 елда фестивальдә Россиядә беренче тапкыр тарихи фехтование буенча HEMA (Historical European Martial Arts) ярышлары уздырылды.

Проектның «Барысы да чынбарлыктагыча!» дигән шигаре аның асылын ача. Мәйданда чын сугышлар бара. Бердәнбер аермасы – коралның махсус үтмәсләндерелүе. Үзләрен урта гасырлар рыцаре итеп тоярга теләүчеләр моны махсус мәйданчыкларда эшли ала. Ихтимал, «Бөек Болгар»ның төп казанышы – аның замандашларыбызга тарихны тоемлау мөмкинлеген бирүендәдер.

МОБИЛЬ КУШЫМТА ЯРДӘМГӘ КИЛӘ

КФУның Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм массакүләм коммуникацияләр институты студенты Роберт Ногманов үзенең «Чүп-чарсыз Россия» мобиль сервисы» дип аталган проектын тормышка ашыру максатларына Яшьләр эшләре буенча федераль агентлык грантын отты.

– Бервакыт без гаилә белән гаражыбызны җыештырырга уйладык. Анда кайчандыр бик мөһим саналган кирәк-яраклар шактый, кирәге чыгар дип, әти-әниләр аларны ташламаган, күрәсең, – дип сөйләп китте Роберт, проект идеясенең ничек барлыкка килүен аңлатып. – Кайчан да булса хуҗалыкта ярап куярлар, дип уйлаганнардыр инде. Мин әйтәм: «Карагыз әле, ташларга кызганыч булса, әйдәгез боларның барысын да эшкәртергә илтеп тапшырыйк?» Нәтиҗәдә иске, инде кирәге калмаган отверткалар, перчаткалар, төзәтерлеге калмаган газон чапкычы пычагы, тагын әллә нәрсәләр – барысын да кабул итү пунктына илтеп тапшырдык. Чыгарып ташламадык, бераз акча да эшләп алдык – машинага бензин салырга җитте. Бу әти-әниемә ошап китте. Бераздан нишләп әле чүп-чарларны аерып, әйтик, пластикны үзенә, пыяла һәм кәгазьләрне үзенә аерым җыймаска дигән идея туды.



Ләкин җыю бер мәсьәлә, ә боларның барысын да кая илтергә кирәклеген белү – икенче. Эзләү системаларында – төрледән-төрле мәгълүмат. Мәсәлән, икенчел чимал тапшыру пунктын эзләп табасың, киләсең, ә ул инде күптән ябылган. Шул рәвешле Робертның башына тулысынча автоном мобиль кушымта эшләү идеясе килә.

Һәм менә күз алдына китерегез: смартфонда кушымта ачыла – экранда икенчел чималны кабул итә торган пунктлар күрсәтелгән карта пәйда була, анда сезгә хезмәт итәрлеге калмаган предметларны һәм әйберләрне кабул итеп алырга һәм аларга икенче тормыш бирергә әзерләр. Өстәвенә, аз булса да, акча бирәчәкләр. Бу урында Җирне киләчәк

Фото: Александр Ефремов

буыннарга саклап калу кебек күркәм эшкә үзеңнең шәхсән катнашуыңны тою мөһим булуын билгеләп үтәргә кирәк. Сүз уңаеннан шунысын да искәртик: социологик сораштырулар нәтиҗәләренә карaганда, әгәр түләсәләр, сез чүп-чарны аерым фракцияләргә бүлергә һәм аны махсус мәйданчыкларга илтергә ризамы дигән сорауга респондентларның 90%ы уңай җавап биргән.

Бәхеткә, мәгълүмати технологияләр бүгенге көннең иң актуаль проблемаларының берсен хәл итү – чүп-чарны сортларга аеру һәм эшкәртүгә дә килеп җитте. 2021 елның маеннан татарстанлыларга әлеге проблеманы чишү өчен мобиль кушымта ярдәмгә киләчәк. Бу икенчел чималны кабул итү пунктлары һәм аны категорияләр буенча уңайлы итеп сортларга аеру фильтрлары күрсәтелгән карта формасында булачак. Әлеге сервисның инде гамәлгә ашырылган тиңдәшләреннән төп аермасы – утильләштерү проблемасына комплекслы якын килү. Монда процессның барлык якларын – калдыкларны тапшырырга теләүчеләрне, утильләштерү пунктларын – берләштерү күздә тотыла. Шулай ук кушымтада экология темасына кагылышлы белем бирү экогиды да эшләп китәргә тиеш.

Проектның авторы үзе болай ди:

– Минем проектым көнкүреш калдыкларын сортларга аерырга һәм тапшырган өчен акча да алырга теләгән, әмма моны ничек эшләргә кирәген белмәгән кешеләргә кызыклы булыр. Проектның башка үзенчәлекләре арасында акча түләү системасын кертү, партнерлар белән эшләү, кабул итү пунктына кадәрге юлны күрсәтү-сурәтләү, мәгълүмати автономлыкны тәэмин итү механизмнары бар...

Сүз уңаеннан, мобиль кушымтада кабул итү пунктларын тапшырылачак чимал типлары буенча аерырга мөмкин булачак – калдыклар өчен сезгә түләячәкләрме яисә бу бушлай тапшыру пунктларымы. Әйтик, чүпрәк калдыклары, иске текстильне бездә беркайда да акчага җыймыйлар. Моннан тыш, эшкәртүгә бирелми торган әйберләр була – терекөмешле лампалар, градусниклар, батарейкалар... Аларны махсус урыннарда кабул итәләр, болар өчен дә акча түләнми. Хәзер уйлап карыйк: тотылган әйберләрне тапшырган өчен реаль акча алып булмый торган кабул итү пунктлары шулкадәр күп икән, нигә әле эчке валюта системасын кертмәскә, ди? Аңа мобиль кушымта партнерларында, мәсәлән, бер чынаяк кофе алырга мөмкин булса.

– Мобиль кушымтада гамәлгә ашырылачак тагын бер функция – һәр кулланучы кушымтага үзе белгән икенчел чимал кабул итү пунктын өсти ала, – дип аңлата Роберт. – Әйтик, идарәче компания офисында – макулатура, ә стоматология клиникасында батарейкалар кабул ителүе турында ишеткәнсең, ди, ләкин әлеге мәгълүмат бернинди сервиска да теркәлмәгән, син бу турыдагы хәбәрне калган кулланучыларга җиткерә аласың.

Проект авторы фикеренчә, иң мөһиме – яңа сервис әйләнә-тирә мохиткә китерелгән йөкләнешне сизелерлек дәрәҗәдә киметә ала.

«КҮП НӘРСӘ ҮЗЕБЕЗДӘН ТОРА»

Гөлназ Сәгыйрова, «Абилимпикс» милли чемпионатында «Флористика» компетенциясендә беренче урын алып, Россия чемпионы булды.

Йоклап киткән кебек кенә булган иде, телефоны шалтыраудан уянып китте.

– Йокламыйсыңдыр инде? Уяндыңмы? Сәгать сигездә мәйданчыкта булырга кирәк. Син барысын да булдырачаксың! Син бөтен кешедән дә күбрәк әзерләндең, белгәннәреңне тулысынча күрсәт кенә...

Тренеры Алёна Дмитриевна Блинова тавышы Гөлназны нәкъ иртәнге сәгать алтыда уята. Һәм канатлар куя!

– Бүгенгә милли чемпионатта лидерлык – минем иң зур җиңүләремнең берсе. Дөресен генә әйткәндә, җиңүдән соң минем күңелем төшкәндәй булды. Шатлана алмыйм кебек. «Булдырдым! Шәп! Мин булдыклы!» дип мактана алмыйм. Әлбәттә, бу минем казанышым гына түгел. Тренерларым минем белән көненә 15әр сәгать эшләде. Шул ук Алёна Дмитриевна мине ике ай буе ял көннәрендә дә, бәйрәмнәрдә дә өйрәтте. Бу кешеләр каршында җаваплылык хисе тойгач, сынатырга хакым юк иде. Һәм мин хәлемнән килгәннең барысын да эшләдем кебек...

Сынау башлангач, Гөлназ чак кына сынатмый кала: беренче модулен – ботаклар белән флористика композициясен ясауны ул сыбызгы тавышына өч минут кала гына төгәлли. Ә вакытка сыешмасаң, ун балл алына! Әмма ул өлгерә!

Икенче бирем – букетны спираль буенча җыю. Монысында Гөлназ инде ул кадәр көчле дулкынланмый. Мөмкин кадәр күбрәк балл тупларга тырышып, биремне хәтта катлауландыра да. Бу юлы вакытыннан 15 минутка алданрак төгәлли. Чәчәкләр турында ул тере җан ияләре хакында сүз баргандай сөйли:

– Букет һәм композицияләр җыю – чәчәкләрне үзең теләгәнчә туплап кую гына түгел. Чәчкәләр, яфраклар, ботаклар һәрвакыт үзара серләшә, кайвакыт хәтта ачуланыша да ала. Композиция төзегәндә, аларның бер-берсен тулыландыруы, матурлыкларын ачуы мөһим, төсмерләрен дә яраштырырга кирәк. Мин катлаулы, көтелмәгәнчә берләштерүләрне яратам. Аларны бөтен флорист ясый да алмый, чөнки бу кыюлык сорый.

Үз көченә ышануга ул үзе ирешкән. Талантлы дизайнер, чигүче, тегүче, визажчы һәм флорист (барлык һөнәрләрне кыз соңгы берничә ел эчендә генә үзләштергән) булып танылганчы, аңа бик күп укырга һәм эшләргә туры килгән:

– Әлки районы Татар Борнае авылында мәктәпне тәмамлагач, әнием миңа: «Кызым,

Фотолар: Гөлназ Сәгыйрованың шәхси архивыннан, Александр Ефремов

ярар, аттестат алдың, шул җитәр», – диде. Мин аның белән бәхәсләшмәдем, әмма дус кызым белән Казанга китеп бардым. Өйдә, дәваланырга барам, дидем, ә үзем көллияткә документларымны тапшырдым. Әгәр укырга керсәм, ничек булса да укыячакмын дип, үз-үземә сүз бирдем. Керә алмыйм икән инде – әни әйткәнчә булачак.

Гөлназ Казанда укый да, берничә һөнәр дә үзләштерә. Мәсәлән, борынгы татар чигешенә ул бер галереяда өйрәнә. Кыз бүген дә ниндидер яңа эшкә тотынудан курыкмый:

– Мине тәвәккәл, диләр. Чакырсалар, шунда ук барам, очам, теләсә нинди проектка алынам. Ул кызыклы һәм иҗади гына булсын. Ә нәрсәдән куркырга соң? Бүген минем тормышымда күп нәрсә кемнәндер түгел, бары тик үземнән генә тора. Мин үземнең физик сәләтләремне аек бәялим. Бик күпләр, хәтта тулысынча сау-сәламәт кешеләр дә, миннән көнләшергә мөмкин.

2018 елда Гөлназ «Абилимпикс» чемпионатында – тегүче, 2019 елда исә визажчы сыйфатында катнаша. Шул ук вакытта инвалидлыгы булган хатын-кызлар арасында үткәрелгән VI республикакүләм «Татарстан энҗесе - 2019» гүзәллек конкурсында катнаша һәм тамашачыларга милли бизәкләр кулланылган заманча кием коллекциясен тәкъдим итә, Миланга бару хокукын яулый (дөрес, пандемия аркасында әлегә бу чара кичектерелгән, әмма ул барыбер булачак бит).

– Мин тагын шуңа өметләнәм: «Абилимпикс» дөнья чемпионаты онлайн түгел, гадәти режимда үтсен иде инде. Бу шулкадәр энергия бирә! Хәзер исә мин чынлап торып җиңүемә дә ышана алмыйм әле. Үткән ярышларда Татарстаннан булган һәр катнашучы өчен безнең ничек сөенгәнебезне күрсәгез иде! – ди кыз. – Минем өчен теләсә нинди эш – тәҗрибә ул. Һәм мин кешеләргә гел уңай энергия генә бирергә тырышам. Без яхшыга өметләнсәк, яхшы була, начарлык көтсәк, үзебезгә үпкәләргә генә кала. Күп нәрсә безнең үзебездән тора...

P.S. «Татарстан» шулай ук редакциябез фотографы Александр Ефремовны да тәбрикли. «Абилимпикс – 2020» милли чемпионатында «Фотограф-репортер» компетенциясендә («Белгечләр» категориясендә) ул беренче урын яулады!

ГҮЗӘЛЛӘР ГҮЗӘЛЕ

Казан студенткасы Анна Семёновыхның гүзәллеген 2020 елда дүрт тапкыр «иң-иң» дип бәяләгәннәр! Гыйнварда ул «Татарстан гүзәле – 2020» республика бәйгесе таҗына лаек була. Аннары Севастопольдәге Халыкара «Кара диңгез энҗесе – 2020» конкурсында диңгез буе халкын таң калдыра. Чебоксарда узган «Россия туризмы гүзәле – 2020» Бөтенроссия бәйгесендә Анна беренче вице-мисс титулын яулый. Һәм инде ел азагында, декабрьдә, чибәр кыз «Россия студентлары гүзәле – 2020» Бөтенроссия конкурсы таҗын Татарстанга алып кайта.

– Бәйгеләрдә республикадан берүзең генә катнашу бик зур җаваплылык йөкли, – дип саный Анна. – Шунлыктан үз нәтиҗәләремне һәрвакыт болай бәялим: ялгышканмын икән, бу бары тик минем генә хатам, ә инде җиңгәнмен икән, бу Татарстаныбызның уңышы.

Аня «Татарстан гүзәле» иҗтимагый оешмасына бик рәхмәтле, чөнки чараларга әзерләнгәндә дә, катнашканда да – һәрчак аларның ярдәмен тоеп килгән. Онлайн тавыш бирү вакытында мәгълүмат туплаганда, барлык иҗади сынауларга әзерләнгәндә, костюмнар сайлаганда булышлык аеруча зур булды, ди кыз. Анна әйтүенчә, матур җиңүләр яулау бик күп хезмәт таләп итә, боларның барысын да ерып чыгу аның берүзенең генә хәленнән килмәс иде.

Анна Казан дәүләт мәдәният институтының социаль-мәдәни һәм гаммәви коммуникацияләр факультетында укый. Булачак һөнәре – социаль-мәдәни эшчәнлек менеджменты. Ул чаралар оештыру белән шөгыльләнергә ярата һәм, Event-индустрия үсеш өчен менә дигән урын, дип саный, чөнки халыкка икмәк кенә түгел, тамаша да кирәк бит.

Теләсә кайсы чараны эшләү үзеңне оештыра белүдән башлана, шунлыктан иң яхшы тактика – әзерләнүгә җаваплы карау һәм сәхнәдә лаеклы чыгыш ясау, дип фикер йөртә кыз. Аны җиңелүләр (гәрчә әлегәчә җиңелгәне булмаса да) дә куркытмый, чөнки ул үз көчен дөрес бәяли белә, һәр конкурста бик көчле катнашучылар булуын таный, жюри карары исә һәрвакыт көтелмәгән, әмма күңелгә хуш килерлек була.

Фото Анны Семёновых архивыннан

Дүрт тапкыр җиңү яулаган гүзәл үзенең Татарстанда укуы белән горурлана:

– Студентлар - Татарстанның алтын резервы, - ди «Россия студентлары гүзәле - 2020». – Шунлыктан күп проект яшьләрнең иҗади куәтен ачуга һәм үстерүгә юнәлтелгән: «Россия студентлары язы», «Беренче курслар көне», актив мәктәпләре, иҗат, спорт, фән кебек төрле юнәлешләр буенча оештырылган грант конкурслары... Әлеге бәйгедә җиңү бөтенроссия һәм халыкара иҗади проектларда Россия студентларын таныту мөмкинлеген бирә. Һәм, әлбәттә инде, сәхнәдән туган республиканың һәм уку йортының исемнәрен яңгырату – бик куанычлы.

Анна Семёновых башка илләрдәге халыкара конкурсларда да көчен сынап карарга тели. Хәзер исә ул пандемия аркасында кичектерелгән «Россия гүзәле» бәйгесенең финалын көтә. Элеккеге җиңүләре сөендерсә дә, гүзәл кызга йолдыз чире йокмаган. Аня фикеренчә, әлеге «чирдән» иң яхшы чара - даими хәрәкәттә һәм үсештә булу.

– Җиңүдән соң биш минут шатланырга һәм әлеге җиңүгә өлеш керткән һәркемгә ихластан рәхмәт әйтергә кирәк. Сәхнәдән төшкәндә, син инде чираттагы адымыңның нинди буласын уйларга тиешсең.

Чибәрлегеннән тыш, Аннаның башка күркәм сыйфатлары да бар. Мәсәлән, ул безнең «Татарстан» журналы белән бергә Буадагы картлар йортына барды. Анда визажчылар, стилистлар, косметологлар һәм журналистлар командасында басманың ел саен үткәрелә торган «Әбиләрне матурлау» махсус проектында катнашты:

– Минемчә, тышкы кыяфәтне матурлау гына дөньяны үзгәртә алмый, әмма мондый тәҗрибә кешенең эчке халәтен, кәефен яхшыртырга тиеш, нәтиҗәдә әйләнә-тирә җиһан да тамырдан үзгәрергә мөмкин. Бу очрашу искиткеч булган иде! Һәм аны бик күп матбугат чараларының яктыртуы да үзен аклый. Чөнки игелек эшләү – күркәм гамәл, бу турыда күбрәк кеше белгән саен, ул тормышыбызда киңрәк тарала ала.

PRESSA

БАТЫРЛЫКНЫ ЯҢАДАН АЧУ

«Әлбәден» Хәрби уеннары» фестивале вакыйгалар туризмы өлкәсендәге Russian Event Awards 2020 Милли премиясенең «Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышланган иң яхшы туристик вакыйга» номинациясендә җиңүче булды.

– Туктарга! Комиссарлар, командирлар, минем янга! – майор Петр Гавриловның фәрманы Брест крепосте форты гарнизоны өстенә тарала. Атыш тавышлары ишетелә, форт алдындагы кырда бер-бер артлы аны саклаучылар авып төшә. Күктә дошман самолеты әйләнә, туктаусыз бомбалар шартлый. Гаврилов немецларның көтелмәгән һөҗүменнән исән калган чик буе подразделениеләре белән командалык итүне үз кулына ала. Немецлар бер көн эчендә алырга ниятләгән Брест крепостеның оборонасы бер айга сузыла. Бик азлар гына исән кала, шуларның берсе – Гаврилов, ул әсирлеккә төшә. Тик аңа кадәр соңгы алышка чыга әле... Берүзе...

Бөек Ватан сугышының беренче көнендәге вакыйгаларның реконструкциясен Брест крепосте оборонасы каһарманының туган авылы Әлбәдендә (Татарстанның Питрәч районы) уза торган «Әлбәден» хәрби уеннары» фестивалендә күрергә була. Биредә фестиваль өчен дип, махсус форт төзелгән – крепостьның Гаврилов капонилары һәм Кобрин капкаларын да кертеп. Гарнизон солдатлары соңгы тамчы каннарына кадәр крепостьны саклаган урыннар бу. 2020 елда, премьера узган 2019 елдан аермалы буларак, реконструкция кечерәк форматта узды, әмма чараны оештыручылар киләсе җәйгә зур планнар кора. Проектта волонтерлар – студентлар һәм мәктәп укучылары актив катнаша.

– Бүгенге яшьләр Бөек Ватан сугышында җиңүгә безнең якташларыбыз – Татарстанда туып-үскән каһарманнарның нинди зур өлеш кертүен белми диярлек. Тарих әкренләп онытыла, тик моңа юл куярга ярамый. Көчле тәэссоратлар калдыра торган проектларга җәлеп итеп, яшь буында тарихыбызга карата кызыксыну уятып була, дип саныйбыз без. Советлар Союзы Герое Петр Гаврилов – безнең легендар якташыбыз. Шуңа да биредә уздырылачак хәрби уеннарның төп герое ул булырга тиеш, дип хәл иттек. Брест крепосте өчен барган сугышларны

Фото: ВКонтактедагы «Помни героя!» проекты төркеме

реконструкцияләү идеясе әнә шулай барлыкка килде, – дип сөйли фестивальнең идея авторы, төп оештыручысы һәм башлап йөрүчесе Наилә Таҗиева.

Быел тамашачыларга крепостьның 1941 елгы оборонасын гына күрсәтеп калмаячаклар, 1944 елда аны азат итүне дә реконструкцияләргә планлаштыралар. Оештыручылар фестивальне 22 июнь тирәсендә үткәрергә хәл иткән. Программа хәзердән үк саллы күренә: патриотик җыр конкурсы, яшьләр арасында спортның хәрби-гамәли төрләре буенча республика күләмендәге чемпионат, реконструкторлар өчен ярышлар, «Сугыш булмаячак» дип аталган иммерсив тамаша (1941 елның тынычлыкта үткән соңгы көне турында), шулай ук сугыш төрләре буенча мастер-классларны үз эченә алган хәрби-тарихи клублар мәйданчыклары, шул чор антуражында шәфкать туташлары конкурсы, сугыш чоры модасын күрсәтү, 1940 нчы елларга караган хәрби бүләкләр, кораллар, ретромобильләр һәм уникаль техника күргәзмәсе, зур концерт.

Сүз уңаеннан, хәзерге вакытта Әлбәдендә Петр Гавриловның мемориаль комплексы проекты буенча эш бара. Җәй көне узачак фестиваль вакытында аның хөрмәтенә һәйкәл ачылачак.

«Дөреслек яклауга мохтаҗ түгел», – дип әйткән Икенче бөтендөнья сугышын үзган фотожурналист Говард Чапник. Шуннан соң күп гомерләр үтте, дөньяда зур үзгәрешләр булды. Бүген дөреслекне якларга, аның шаһитларын эзләргә кирәк. «Әлбәден»дә һәркем шушы рольне башкара ала.

Фото: Евгений Кулешов

«АЛТЫН БИТЛЕГЕН» ТАПКАН ТЕАТР

2020 ел ахырында В.И. Качалов исемендәге Казан академия Зур рус драма театрының баш режиссеры Александр Славутскийга театр сәнгате үсешенә керткән фидакарь хезмәте өчен «Алтын битлек»нең махсус премиясе бирелде.

Мөгаен, әлеге хезмәтнең зур өлеше Славутскийның Татарстанда, Россиядә, Франциядә, Кытайда, Төркиядә һәм башка илләрдә танылу алган театр оештыруыннан гыйбарәттер.

Бер күрүдән үк кабынган ярату булмый әле ул. Александр Славутский Казанга беренче тапкыр 90 нчы еллар башында килә. Аңа кадәр режиссер шактый саллы иҗат тәҗрибәсе тупларга өлгерә: Читада – баш режиссер, Ростов драма театрында һәм Мәскәүнең К.С. Станиславский исемендәге театрында сәнгать җитәкчесе булып эшли.

«Казанга мине театрның директоры Григорий Первин чакырып китерде. Килдем. Шәһәрдә юеш, пычрак. Үзәк универмагның беренче катында машиналар саталар. «Волга» кунакханәсендә – тараканнар. Театр таралып ята. Кул гына селтәдем». Славутский туган Чиләбе шәһәренә кайтып китә, анда спектакльләр куюын дәвам итә һәм ярты елдан соң янә Казанга җыенып килә. «Ул вакытта Минтимер Шәймиев белән сөйләштек. Ул ышандыра белә. Һәм мин эшләп карарга тәвәккәлләдем: ни булса, шул булыр».

Яңа эш уңышлы килеп чыга. Александр Славутский театр гына төзеп калмый, ә аның принциплары буенча яши торган үзенә бер галәм барлыкка китерә. Шуларның берсе – театр кеше өчен һәм кеше турында булырга тиеш.

«Кеше алдында һавалы буласым килми. Тамашачының күпчелеге сәнгатьне аңлап бетерми, шуңа да аның фикеренә түгел, театраль элитадан булган өч-дүрт тәнкыйтьчегә йөз тотарга кирәк, дигән киң таралган фикер бар. Мин алай уйламыйм. Театр килгән кешегә кызыклы һәм аңлаешлы булырга тиеш», – ди Славутский.

Ул үз сәхнәсендә чирек гасырдан артык классика куя. Күп кенә әсәрләр безгә мәктәптән үк таныш, әмма Качалов театрының залы һәрвакытта да тулы була. Спектакльләр еллар буена бара, һәм аларга еллар буена тамашачы йөри. Сере нидә? Сере шундадыр, мөгаен: Качалов театры режиссерының тагын бер принцибы – аныңча, театрда һәрбер нәрсә дә матур булырга тиеш, гәрчә ул фаҗига булса

да һәм кан коелса да. Славутский гүзәллек тудырганда саранланмый. Сәхнә бизәлеше, костюмнар, музыка – боларның һәркайсын ул камил дәрәҗәгә җиткерә, сәгать механизмыннан да төгәлрәк итеп башкара. «Театр тамашачы өчен бәйрәм булырга тиеш. Күңел ачу мәгънәсендә түгел, ә рухи күтәренкелек мәгънәсендә», – дип ышандыра режиссер.

Качаловлылар өчен һәр спектакль – яңа дөнья. Бу дөньялар эчтәлекләре ягыннан шактый аерыла, әмма уртак яклары да бар. «Мин гомерем буена бер спектакль куям – үзем турында спектакль», – ди Славутский. Озакламый ул премьера чыгарачак – Максим Горький пьесасы буенча эшләнгән «Васса Железнова» спектакле. «Бу пьесада һәр нәрсә миндә кайтаваз таба: көчле кеше, хатын-кыз, ул ирешкән хакимлек, шул ук вакытта – ялгызлык та. Мин нәрсә эшләсәм дә, аңа көрәш аша, кыенлыкларны җиңеп чыгу аша килем. Менә шул инде ул асылда хезмәт, әмма бу килеш ул әле беркемгә дә кызык түгел. Нәтиҗәсе кызык», – дип саный режиссер.

Ә нәтиҗәне санап китәргә дә була: театр механизмының өзлексез эшләве, актерларның иҗат белән янып яшәве, бинага яхшы ремонт ясалуы, аншлаглар, күпсанлы гастрольләр. Соңгы чирек гасырда Качалов театры үз йөзен тапты. Һәм үз «Алтын битлеген» дә...

Александр Славутский белән әңгәмәне
«Татарстан» журнылының февраль санында укыгыз

«ЧЫН ИР-ЕГЕТ ҮСӘ...»

Татарстанның Алексеевск районы Зур Полянка авылыннан 14 яшьлек Иван Павлинов өйләрендә чыккан янгыннан өч энесен коткарып кала.

Бу гамәлен ул батырлык дип санамый. Аны күбрәк «Безнең заман геройлары» республика премиясен тапшыру тантанасына һәм «Бәләкәй батырлар форумы»на килгән башка балаларның батырлыклары сокландыра.

– Менә Яр Чаллыдан Аня Соловьёва тренировкаларның берсендә бассейн төбендә хәрәкәтсез яткан малайны күреп ала. Тренерга хәбәр итә дә, уйлап та тормастан, суга чумып, аны өскә алып чыга. Әгәр ул яшен тизлегендә реакция күрсәтмәгән булса, малайны коткарып кала алмаслар иде. Чистайдан җиде яшьлек Радмир Галимов бер кызны педофилдан коткара... Ә үземне герой дип санамыйм. Үземнекеләрне – энекәшләремне коткардым, ә бу – табигый.

Иван Павлиновка бирелгән «Яшь герой» көмеш йолдызы Россия Герое йолдызына бик тә охшаган. Дөрес, балаларныкын бәләкәй генә самолет та бизи. Бу иҗтимагый бүләк «Бердәм Россиянең Яшь Гвардиясе» башлангычы белән 2018 елда барлыкка килә, һәм аны Россиянең яшь гражданнарына батырлык кылган өчен бирәләр.

19 ноябрь иртәсе Павлиновлар өендә гадәттәгечә башланып китә. Әнисе – картлар һәм инвалидлар интернат-йортында кизүдә. Өч энесе – ун яшьлек Егор һәм җидешәр яшьлек игезәкләр – Захар белән Тимофей йоклыйлар әле. Өйдә өлкән кеше урынына калган Иван мәктәпкә җыена. Кинәт кенә янгын сигнализациясе тавыш бирә башлый. Иван ни булганын карарга дип ишекне ачса, анда веранданы ялкын чорнап алган...

– Бүлмәгә төтен кереп тулганчы, малайларны чыгарып өлгерергә кирәк, дип кенә уйларга өлгердем, – ди Иван. – Алар йокылы-уяулы килеш нәрсә булганны аңлап та бетермиләр иде әле. Бөтен нәрсә шундый тиз булды, мин хәтта янгын кайчан башланганын аңламый да калдым. Төтен ургылып керде, шунда ук сулап булмый башлады.

Фото: Александр Гайнетдинов, «Татар-информ» МА

Иван энеләре һәм яраткан эте Фроська белән.

Нинди киемнән йоклаган булсалар, шул киемдә мин коеп төшергән тәрәзә аша бер-бер артлы урам ягына сикерделәр. Ярый, өлгердек әле...

Иван, энеләрен урамга чыгаруга, тәрәзә аша аларга курткаларын да бирә һәм өйдә калган телефоны белән документларын эзли башлый.

– Шуннан искә төште: документларны әни ксерокопия ясатыр өчен үзе белән алган иде. Телефонны тапмадым. Анысы ярар, иң мөһиме – үзебез исән калдык. Этләребез – Фроська белән Чернушка да. Чернушкага азрак зыян килде – йоны бераз өтелде, – дип борчыла Иван. – Энекәшләр йортны ут ялмап алганны күргәч, елап җибәрделәр. Курыктылар. Мин аларны шунда ук әнинең сеңлесенә җибәрдем, бәхеткә, алар бездән юл аша гына яшиләр. Аларга хәтта салкын да тимәде, гәрчә кардан яланаяк йөгерсәләр дә. Ә уртанчы энем Егорка китмәде, мине көтте... Хәзер тынычландык инде, барыбыз да. Өебез генә янып бетте – шунысы кызганыч.

– Мин эштән очып кайтып җиткәндә, йорт ут эчендә иде инде. Аллага шөкер, балалар чыга алганнар, – дип искә ала Иванның әнисе Анна Геннадьевна. – Авыл кешеләре әйтүенчә, йорт санаулы минутлар эчендә янып беткән: әле генә төтен күренгән, шунда ук ялкын күтәрелгән.

Иван улым – мөстәкыйль малай ул. Мин эштә чакта энеләрен карый. Ашата, дәресләрен әзерләшә. Ул минем терәгем. Әлбәттә, аңа мондый сынаулар аша үтәргә туры килер дип көтмәгән идем. Аның югалып калмавы, иң элек энеләрен коткарырга кирәклеген аңлап, тиз арада карар кабул итүенә сокландым. Чын ир-егет үсә...

Яңа ел алдыннан – 31 декабрьдә – Зур Полянка авылында Алексеевск районы башлыгы Сергей Демидов 14 яшьлек Иванга яңа йорт ачкычын тапшырды. Торак сатып алу өчен акчалар ТР Президенты кушуы буенча бүлеп бирелгән. Моннан тыш, район бюджеты хисабына җиһазлар, техника сатып алынган, ремонт ясалган.

БЕР ОЯДА – УНБИШ БАЛА

Балтач районынында аларны белмәгән кеше юк. Әлбәттә, 15 бала табып үстереп кара әле! Ничек белмәсеннәр!.. Ә узган елда әлеге гаилә бөтен республикага танылды. Күп балалы гаиләгә «Ата-ана даны» ордены тапшыралачак. РФ Президенты Владимир Путин узган ел Указга кул куйган инде.

Хәбир һәм Алсу Мөхәрләмовлар Балтач районың Пыжмара авылында яши. Гаилә корганнарына 35 ел булган. Алар турында авылдашлары: «Бик тырыш кешеләр», – диде.

Мөхәрләмовлар ике катлы йортта яши. Аны 2008 елда дәүләт ярдәме белән салып чыкканнар. Гаилә башлыгы гомере буе диярлек тракторда эшләгән. 2019 елда Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы исеменә лаек булган. Бүген дә – шул хезмәттә. Ә Алсу апа гомере буе... бала тапкан, үстергән. Бүген инде лаеклы ялда.

– Унбиш бала! Хатын-кыз сәламәтлеге өчен куркыныч түгелме ул? – дип төпчендем үзеннән.

– Куркыныч инде. Унбишенчесен – төпчек кызымны тапканда, табиблар көчкә коткарып калды. Бала тудыру йортында, уенын-чынын бергә кушып: «Апа, бүтән бала тапмагыз», – дип әйттеләр.

– Күп балалы ана булу максат идеме? – дим, һаман да аптырап.

– Юк, максат түгел иде, Аллаһы Тәгалә үзе бирде. Туасы җан диләр бит әле, шулай булгандыр. Ул-кызларыбыз – безнең иң зур байлыгыбыз. Бу коры сүзләр генә түгел. Яшьлектә әле моны аңлап та бетермисең икән. Ә менә олыгая-олыгая ныграк төшенәсең...

Алсу апа сабыр кеше. Җөмләләрен уйлап кына әйтә, ашыкмый-кабаланмый гына сөйли.

– Сез балаларыгыз белән дә шулай сабырмы? – дим.

– Әйе, сабыр. Шар ярып кычкырганымны хәтерләмим. Безнең балалар бик тәртипле булды, әйтергә дә куркам. Зурраклары кечкенәләрен карашырга ярдәм итте. Элегрәк кием-салым да бер-берсеннән кала иде. Хәзер инде һәркайсына яңасын алабыз. Ни өчен дигәндә, беренчедән, тормышлар җайланды, икенчедән, киемнәрнең сыйфаты начар, тиз туза.

Мөхәрләмовлар миңа кош оясын хәтерләтте: үсә баралар, оядан чыгып оча торалар: бүген яннарында унбиш баланың дүртесе генә калган, алар – мәктәп укучылары, тагын өчесе – студент. Калганнары, зурраклары, инде үз гаиләләре белән яши.

Фото Мөхәрләмовларның гаилә архивыннан

Мөхәрләмовларның биш уллары армиядә булган. Асафны хәрби хезмәткә озату вакытында.

Бу йорттан беркайчан бала-чага тавышы өзелми. Хәзер инде оныклар кайтып тула икән. Алсу апа алардан тую түгел, рәтләп күрми дә кала дияргә була:

– Балалы өйдә гайбәт булмый, диләр. Бу чынлап та шулай. Безнең кеше сөйләргә вакытыбыз юк. Башта ул-кызларыбызны мәктәпкә озатам, аннан йорт эшләренә керешәм. Көн дәвамында берничә тапкыр телефон шалтырый – балалар хәл белешә. Аннан мәктәп укучыларым кайтып җитә. Кайнар ризык әзерләп көтеп торам. Өстәл артында сөйләшәбез, серләшәбез. Бер ата-анадан булсалар да, балаларның холыклары төрле.

Мөхәрләмовлар турында авыл кешеләреннән сорашсаң, барысы да бер фикер әйтә: «Ничек шулай балаларын тәрбияле алганнардыр? Ник бер баласы эчеп, тәртипсезләнеп йөрсен. Укып бетереп, һөнәр үзләштерәләр дә гаилә коралар. Аннан йорт салалар, фатир алалар».

Моның серен ата кешедән сорадым. Хәбир абый йомшак кына болай дип җавап бирде:

– Без балаларны иркәләмәдек тә, типкәләмәдек тә. Хезмәт белән тормыш алып барганлыкны күреп үстеләр. Алар өчен йөзем кызарганны хәтерләмим. Алга таба да шулай булсын. Берәр гаепләре булса, абый-апалары акылга утыртып куя иде. Күп очракта без соңыннан гына белдек. Әниләренә рәхмәт, мин көне-төне эштә булдым. «Өйгә кайт», – дип аптыратмады. Күп итеп мал да карады, кайнар аш та гел өстәлдә булды. Аллаһы Тәгалә бала хәсрәте күрсәтмәсен, шуны гына телим.

...Бала безне аңламый, үсмер чоры, кризисфәлән, дип, ата-аналар бүген психологларга, тагын әллә кемнәргә йөгерә. Ә Мөхәрләмовларга андый белгечләр кирәк түгел. Берәр проблемаң булса, әнә, абыең, апаң бар. Кирәк икән, сүз белән, ә кайчакта кул белән дә акыл биреп алалар...

PRESSA

МОНДА – ЧЫН КОСМОС

Казан педагогы Анна Григорьева «Йөрәгемне балаларга бирәм» Өстәмә белем бирү өлкәсе хезмәткәрләренең бөтенроссия профессиональ осталык конкурсында җиңеп чыкты.

Анна дүрт яшеннән космос темасы белән мавыга. Ул аның бөтен яшәешен били. Әгәр синең этиең, Игорь Григорьев, – университет каршындагы мәктәп-лицейга (бүгенге көндә Лобачевский исемендәге лицей. - **Ред.иск.**) нигез салучы һәм аның беренче директоры, физика һәм астрономия укытучысы икән, башкача яшәү мөмкинмени? Аның йолдызлар, планеталар һәм безнең галәм турында сөйләгәннәреннән соң, космоска гашыйк булмау үзе үк гаҗәп тоелыр иде.

– Космос – минем тормышымның зур өлеше. Мин бары тик үземә бик кызыклы булган нәрсәләр белән укучыларымны кызыксындырырга гына тырышам. Күк гөмбәзе буенча Кояш, Ай, Җир, йолдызлар һәм планеталарның ничек һәм кайсы якка хәрәкәт итүләрен мөстәкыйль рәвештә ачу, күрү һәм тою шатлыгын кичергән бала бу турыда беркайчан да онытмаячак! – дип сөйли Анна.

2017 ел. Казан «Космос разведчиклары»ның әләме МКС та. Ул космонавт Сергей Рязанский ярдәме белән космоска күтәрелде.

Бүген ул – Казан шәһәренең Авиатөзелеш районында урнашкан Мәктәптән тыш эшчәнлек үзәгендә өстәмә белем бирү педагогы. КФУның астрономия һәм космик геодезия кафедрасында өченче курста укыганда ук Анна «космос разведчиклары» отряды оештыра, ул Алексей Леонов исемен йөртә. «Разведчиклар» планетаның ачык космоска чыккан беренче кешесе белән 2016 елда шәхсән танышалар. Ярты ел элек үз отрядларына исем сайлаганда, укучылар мондый уңыш турында хыяллана да алмаганнар әле!

2016 ел. «Космос разведчиклары» космонавт һәм рәссам Алексей Леоновка үз рәсемнәрен бүләк итәләр.

Хәзер Аннаның биш методик программасы бар, әмма «Йөрәгемне балаларга бирәм» Бөтенроссия конкурсында ул нәкъ менә «Космос разведчиклары»н тәкъдир иткән:

– Бу программада мин балаларга уен формасында космоста булып карарга тәкъдим итәм. Безнең отрядта, чын космик корабльдәге кебек, балалар – үз командирлары, штурманнары, экипировщиклары һәм башка космос белгечләре булган экипажларга бүленә. Әлеге профессияләрне без теориядә һәм практикада өйрәнәбез. Әйтик, штурманнарга мин, йолдызларга карап, ничек итеп навигация төзелүе, корабльнең космоста ничек ориентлашуы турында сөйлим. Уен аша балалар маршрутны билгеләргә, навигация приборларының дөрес эшләвен күзәтергә өйрәнә. Бу аларны бик мавыктыра. Әйе, бүген бу алар өчен уен. Әмма, үскәч, бәлки минем укучыларым арасыннан кемдер үз тормышын чыннан да галәм белән бәйләр.

Казанның «космос разведчиклары» программасы буенча конкурсның бөтенроссия этабында Анна Петербург балалары өчен ачык дәрес үткәрү белән генә чикләнми, ул марафонның барлык этапларында да искиткеч нәтиҗәләр күрсәтә. Хәер, шик-шөбһәләре дә була, билгеле:

– Номинация буенча коллегаларым белән танышканда, гаҗәпләндем дә – алар барысы да диярлек экологлар һәм биологлар иде. Ә бит номинация

Фотолар Анна Григорьеваның шәхси архивыннан

табигый-фәнни! Бәлки, ялгышып, тиешле урынга эләкмәгәнмендер дигән фикер дә туды хәтта. Коллегаларымның нинди программа тәкъдим итәчәгем турындагы сорауларына астрономия һәм космонавтика дип җавап бирдем. Бәлки, географиядер, дип сорыйлар. Юк, дим, астрономия һәм космонавтика! Әлбәттә, бик тә, бик тә җиңәсем килде, тик уңышка ахыргача ышанмадым. Һәм, минем исемемне атагач, бик нык дулкынландым. Финалга гаҗәеп кызыклы программалары һәм методикалары булган чын мәгънәсендә талантлы педагоглар үткән иде!

Әмма, ни генә булмасын, киләсе елга «Йөрәгемне балаларга бирәм» Өстәмә белем бирү өлкәсе хезмәткәрләренең бөтенроссия профессиональ осталык конкурсын Казан кабул итәчәк. Анна Григорьева җиңүе нәтиҗәсендә:

– Киләсе конкурс ничек үтәр, мин әлегә белмим. Һәрхәлдә, мондый искиткеч педагогик иҗат һәм аралашу атмосферасына кабат рәхәтләнеп чумачакмын! – ди педагог.

«Космос разведчиклары» очучы-космонавт, космонавтлар отряды командиры, Россия Герое Олег Кононенко белән.

МӘҢГЕГӘ ИСТӘ КАЛА ТОРГАН МИЛЛИ КОД

Татарстанның каклаган казы һәм Казан чәкчәге азык-төлек буенча «Вкусы России» Төбәк брендларының беренче милли конкурсында җиңеп чыкты. Конкурска нәтиҗәләрне узган елның декабрь аенда ясадылар.

«Тыштан май белән капланган каклаган каз суыткычсыз өч ел саклана ала. Кунак килсә – сый әзер. Кунакка барсаң, күчтәнәчкә казыңны ал» – журналист һәм язучы Василий Песковның бу сүзләренә татар казыннан ясалган деликатесның бөтен концепциясе сыйган.

Каклаган каз безнең бабайларны сәяхәтләрендә озатып йөргән, озын юлга чыкканда туклыклы азык саналган. Яңа өйләнешүчеләргә пар каз бүләк итү (берсен – туй өстәленә куярга, икенчесен – кунакларга күчтәнәчкә) традициясе киләчәккә хәерле тормыш теләү символы буларак бүгенгәчә яшәп килә. Ә инде чит илләрнең кайбер кулинария тәм-томнарына санкцияләр кертелгәннән соң, каз, хамон деликатесларын гомумән пьедесталдан читкә этәреп, беренче урынга чыкты.

«Декабрь аенда алты айлык таза, түгәрәк казларны чалабыз. Эчен дә, тышын да әйбәтләп чистартабыз. Эченә тоз тутырабыз – чама белән кило ярым кирәк. Каты кәгазьгә төрәбез. Аннары кибәргә элеп куябыз, иң яхшысы – авыл өенең чормасына. Май аенда алабыз да туңдыргычка тыгып куябыз. Кунаклар килер алдыннан, алып, тозларын кагабыз, юабыз да бер тәүлеккә салкын суга салып калдырабыз. Кирәк кадәрен кисеп алгач, калганын суыткычка куябыз. Анда ул берничә ел саклана ала, ләкин бик сирәкләрдә генә, тиз ашалып бетә», – дип, әнә шундый рецепты белән уртаклашты каз каклау остасы һәм сатучы Фирдәүсә апа.

Каклаган каз – тәмле табынның нигезе булса, алтынсу төстәге, авызда эреп торган чәкчәк – аның таҗы. Бу татлы тәгамне традицион рецепт белән әзерләргә керешсәгез, сез, мөгаен, берике гасыр элеккеге тормышның нинди салмак агышлы булуын, ризыкларның сыйфатына нинди зур игътибар бирелүен, йорт хуҗабикәсе, аның гаиләсе һәм кунаклары өчен һәр табынның нинди мәгънәгә ия булуын аңлый башларсыз.

Фото: Луиза Шарова

Беренче карашка, чәкчәк рецептында бернинди катлаулы нәрсә юк кебек. Йомшак итеп камыр басасы. Аны, җәеп, тасмаларга бүлгәлисе дә саламлап яисә кедр чикләвеге зурлыгында кискәлисе. Иләк ярдәмендә артык оннан арындырасы. Аннары кызган майга камыр төшләрен салып, һәр ягы кызарырлык итеп болгата-болгата пешерәсе генә кала. Шуннан соң инде балны эретергә һәм, аңа бераз шикәр, су кушып, сироп әзерләргә, аны төшләр өстенә сибәргә кирәк. Чынлыкта боларның һәркайсын башкару өчен зур осталык таләп ителә. Шуңа күрәдер, мөгаен, элек бу татлы сыйны әзерләгәндә рольләрне үзара болай бүлешкәннәр: кияүгә чыгасы кызлар камырны баса, җәя һәм кисә, кияүдәгеләр майда кыздыра, ә өлкәнрәкләр, чәкчәккә бал кушып, аны формага китерә.

Бүгенге көндә һәр хуҗабикәнең үз чәкчәк пешерү сере бар. Кемдер, камыр йомшак булсын өчен, аңа спиртлы эчемлек куша, кемдер камырны алдан туңдырылган, аннары эретелгән йомырка белән баса, ә кемдер, кыздырылган төшләрнең артык мае саркып чыксын өчен, аларны салфеткага бушата.

– Бездән еш кына нинди чәкчәк дөрес, ә кайсысы дөрес түгел, дип сорыйлар. Әлбәттә, азык продукты буларак, аның аерым сыйфатлары бар – яңа пешкән булуы, йомшаклыгы, сиропның сыйфаты. Аларны исәпләмәгәндә, һәркемнең үз чәкчәге дияргә була, – ди Казандагы Чәкчәк музеена нигез салучы Раушания Полосина-Сөләйманова. – «Чәкчәгегез әбиемнеке кебек булган!» – дисәләр, безнең өчен иң зур мактау шул.

Чәкчәкнең дә, каклаган казның да һәм милли кухняга караган башка ризыкларының да, тәм сыйфатыннан тыш, тагын бер ягы бар. Алар барысы да тәфсирләп аңлатып торуга мохтаҗ булмаган мәдәни кодны тәшкил итә. Ә инде гасырлардан килгән рецептларны һәм бүген кулланыла торган һәркемгә «аңлаешлы» ингредиентларны уңышлы берләштергән татар кулинариясе – тиз арада үзенә җәлеп итә һәм мәңгегә истә кала торган код ул.

ИНЖЕНЕРЛАР ӘЗЕРЛӘҮДӘ БЕРЕНЧЕ: КИЛӘЧӘК УКУЧЫЛАРЫ

Мәгариф өлкәсендә яңа технологияләр көннән-көн активрак кертелә. Бу технологияләр мәктәп чорында ук акыллы, максатчан һәм төрле юнәлештә үсеш алган, хәзерге дөньяда көндәшлеккә сәләтле балалар әзерләп чыгарырга мөмкинлек бирә. Шундый уку йортларының берсе – гыйнварда биш еллык юбилеен билгеләп уза торган, тәүге эш нәтиҗәләрен ясаган «Лицей – инженерлык үзәге» муниципаль автоном белем бирү учреждениесе (МАББУ) (директоры Венера Хәйретдинова).

Әлеге уку йорты 2016 елның 11 гыйнварында Казанның Совет районында ачылды. Хәзерге вакытта ул өч структур бүлекчәдән тора: Smart Kids[1] балалар бакчасы, Intellectual Linguistic School XXIc+[2] башлангыч мәктәбе, инженерлык лицее. Инженерлык лицеен оештыру бик вакытлы һәм урынлы адым булды: биредә укучылар киләчәктә үзләренә кирәк булачак инженерлык компетенцияләрен үзләштерә. Тикмәгә генә лицей Россия Фәннәр академиясе, «Югары икътисад мәктәбе» милли тикшеренү университеты һәм КМТТУ-КАИның база мәктәбе дип саналмый. Лицей нигезендә профильле төркемнәр булдыру юнәлешендә хезмәттәшлек итү максатыннан, С.П.Королев исемендәге «Энергия» ракета-космос корпорациясе (Королев шәһәре), КМТТУ-КАИ һәм Казан шәһәре Совет районының «Лицей – инженерлык үзәге» арасында килешү төзелгән. Казан шәһәренең «Лицей – инженерлык үзәге» МАББУ шулай ук Татарстан Республикасында Россия Фәннәр академиясенең биш база мәктәбе исемлегенә керә.

2016 елдан КМТТУ-КАИ балалар бакчасында һәм күптелле башлангыч мәктәптә, шулай ук инженерлык лицеенда барлык укыту-тәрбия процессын оештыруның методик һәм методологик үзәге булып тора.

Лицейда уңышлы эшли торган укытучыларның ике дистәдән артыгы – фән докторлары һәм фән кандидатлары, магистрантлар. Алар робот техникасы, заманча технологияләрнең нигезләре, әйберләр интернеты, Arduino[3] һәм башка дисципланаларны укыта.

Лицей белән фәнни җитәкчелек эшен алып баралар: А. Н. Туполев ис. КМТТУ-КАИның белем һәм тәрбия эшләре буенча проректоры, техник фәннәр кандидаты Алексей Лопатин, КФУның Югары бизнес мәктәбе профессоры, икътисад фәннәре докторы Венера Вәгыйзова, педагогика фәннәре кандидаты, лингвистика юнәлеше җитәкчесе Надежда Обухова, «Казан педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең педагогика һәм психология кафедрасы мөдире Гөлсинә Аймәтдинова, Казан шәһәре мәгариф идарәсенең мәгълүмати-методик бүлеге методисты Ирина Бесчастнова. Фәнни-тикшеренү юнәлешендәге уку-укыту курсларын техник фәннәр докторы, профессор Альберт Саттаров, техник фәннәр докторы, КМТТУ-КАИның электрон һәм квант мәгълүмат тапшыру чаралары кафедрасы мөдире Дмитрий Данилаев, техник фәннәр кандидаты, радиоэлектроника һәм мәгълүмати-үлчәү техникасы кафедрасы доценты Евгений Денисов, техник фәннәр кандидаты, радиоэлектроника һәм мәгълүмати-үлчәү техникасы кафедрасы доценты Рафаэль Сәгъдиев, техник фәннәр кандидаты, җылылык техникасы һәм энергетика машиналары төзелеше кафедрасы доценты, А. Н. Туполев исем. КМТТУ-КАИның Корпоратив институты директоры Артур Гимбицкий, «радиотехника» белгечлеге буенча Германия – Россия яңа технологияләр институты магистры, Embedded Systems[4] белгечлеге буенча TU Kaiserslautern[5] тәмамлаган Никита Ильин, КМТТУ-КАИның җылылык техникасы һәм җылылык физикасы кафедрасы аспиранты Александр Кузин. Укучыларның проект

Фотолар «Лицей – инженерлык үзәге»ннән алынды

[1]Акыллы балалар, [2]XXIC.+ интеллектуаль лингвистика мәктәбе, [3]Ардуино, [4]Кертеп ясалган системалар, [5]Кайзерслаутерн университеты.

эшчәнлеге табигый-фәнни юнәлешләрдәге төрле гыйльми хезмәткәрләр, фән кандидатлары һәм фән докторлары җитәкчелегендә гамәлгә ашырыла.

Лицей, үз чиратында, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов тарафыннан хупланган «Инженерлык республикасы» проектының ресурс-методик үзәге булып тора. Әлеге проект кысаларында лицей педагоглары Балтач, Лаеш, Биектау, Балык Бистәсе һәм Кукмара районнары вәкилләренә белем бирә.

2019-2020 нче уку елында гына да лицей укучылары Бөтенроссия олимпиадаларының муниципаль һәм республика этабында 35 призлы урын яулады яки җиңүче булды. Лицей бүген балаларны «Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia) чемпионатына әзерли, шулай ук 2020 елдан «Әйберләр интернеты» компетенциясе буенча әзерлекнең махсуслаштырылган үзәге булып тора. «Җиңел автомобильләрне ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү» компетенциясендә – Алексей Майоров, «Әйберләр интернеты» компетенциясендә Ринель Җамалиев һәм Дамир Газизуллин WorldSkills Russia чемпионатының алтын медальләрен яулады. «Лицей – инженерлык үзәге»н тәмамлаучылар республикабызның һәм илебезнең Мәскәү халыкара багланышлар дәүләт институты, КФУ, Мәскәү дәүләт техник университеты, КДАТУ, КМТТУ-КАИ, КМТТУ-КХТИ, Бонч-Бруевич исем. Санкт-Петербург дәүләт телекоммуникацияләр университеты, СПбДУ, Россия халыклар дуслыгы университеты кебек алдынгы вузларында уңышлы белем ала. Белем учагы С.П. Королёв исем. төбәкара проект конференциясе, «М.П.Симонов исемендәге кышкы укулар» халыкара фәнни-гамәли конференциясе кебек югары дәрәҗәдәге фәнни чаралар уздыра. Лицейның һәр баласы үз белем бирү проектын яклый.

Асылда, төп һәм өстәмә белем, техник дисциплиналар һәм чит ил вәкилләре (АКШ һәм Бөекбритания) ярдәмендә югары класслы тел өйрәтү дәресләрен берләштереп, биредә балалар бакчасыннан алып, югары уку йортына кадәр робот техникасы өлкәсендә уйлап табучылар, тәрҗемәчеләр, айтишниклар әзерлиләр. Монда балаларга шулай ук IT-юнәлешләр буенча өстәмә дисциплиналар («Python[6] телендә программалаштыру», «Java[7] телендә программалаштыру», «Web-программалаштыру», «Векторлы графика», «Scratch[8] технологияләрен куллану») һәм инженерлык юнәлешендәге фәннәр («Әйберләр интернеты», «Электроника», «Raspberry Pi[9] бер платалы компьютеры нигезендә әйберләр интернеты технологиясе» «3D-модельләштерү» «Челтәр технологияләре», Arduino Engineering[10], «Мехатроника») укытыла. Лицейда ХАКСПЕЙСлар – технологик профильле кабинетлар ачылган. Акыллы электроника һәм робот техникасы эшләү өчен, аларга 3D-принтерлар, лазер граверы, фрезер станогы, лартмастерлар һәм лего-конструкторлар белән җиһазландырылган слесарьлык, радиомонтаж, прототиплаштыру лабораторияләре дә керә. Бу җиһазлар өстәмә техник дисциплиналарны өйрәнү өчен кулланыла. Шул рәвешле укучылар заманча цифрлы җитештерү аппаратлары белән эшләү һәм алар өчен программалар язу буенча гамәли күнекмәләр ала. ХАКСПЕЙСлар базасында лицейда КМТТУ-КАИның Яшьләр инновацияле иҗаты үзәге лабораториясе эшли. «Лицей – инженерлык үзәге»ндә белем бирү процессын оештыруның мөһим үзенчәлеге – төп гомуми һәм өстәмә белем бирүнең берләшүе. Өстәмә белем бирү программасы STREAM[11]-белем яңа халыкара парадигмасына туры килә: S-science, T – technology, R – reading, E – engineering, A – art һәм M – mathematics[12].

Әмма биредәге укучылардан башка бу казанышлар коры саннардан гына гыйбарәт булыр иде. Мондагы малайлар һәм кызлар оптимизм хисе, игелеклелек, акыл һәм тәрбиялелек белән аерылып тора. Алар уку өчен кирәкле иң уңайлы шартлар һәм белем бирү процессында кулланыла торган соңгы ноу-хаулар белән яхшы тәэмин ителгән. Балалар бик актив, мавыгулары да бик төрле, чит телләрне һәм информатиканы беләләр, Мария Склодовская-Кюри һәм Стивен Хокингны кумирлары дип саныйлар. Менә шулар инде ул – иң кадерле кадрлар, Татарстан һәм Россияне яңа җиңүләргә алып барырга тиешле киләчәк заман укучылары.

[6] Питон, [7] Ява, [8] Скретч, [9] Распберри Пи, [10] Ардуино Инжиниринг, [11] СТРИМ, [12] S – саенс, T – технология, R – уку, E – инжиниринг, A – арт һәм M – математика.

PRESSA

– **Рубин Кәбирович, әлеге әһәмиятле датаны – консерваториягә нигез салучының юбилеен билгеләп үтүгә пандемия комачауламасмы?**

– Бүгенге кыенлыклар – бу котылгысыз хәлләр, әмма юбилей – музыкаль белем һәм сәнгать системасы үсешендә үзгәрми торган тарихи этап һәм башлангыч хисап ноктасы. Җиһанов җәмгыять һәм мәдәният алдында җаваплылык тойган бөек гражданин иде. Без аның шәхесенең һәм киләчәккә юнәлтелгән эшләренең киң масштабын аңлыйбыз, алар арасында – консерваторияне үстерү һәм Балалар музыка мәктәбеннән зур сәхнәгә кадәр музыкаль белем бирү системасын формалаштыру. Аның урынында башка кешенең шулкадәр күп эш эшләп өлгерүен һәм шундый ныклы нигез корып калдыра алуын күз алдына да китерү авыр. Үзе ныклы нигез салган традицияләрне алга таба да үстерәчәк музыкантларны җәлеп итү, яшьләргә юл ачу ягыннан да. Республикада ул эз калдырмаган бер генә музыка учреждениесе дә юк. Ул үз студентлары турында аларның ата-аналарыннан да ким белми иде. Иҗатта һәм тормышта романтик иде ул. Һәр кылган гамәле белән бу шәхес гадәти соры мохиттән югарырак биеклектә тора белде – рухи биеклектә. Без аның уникаль роялен саклап калдык. Әлеге рояль артында ул композиторлар өчен «инструментовка» курсын алып бара иде.

РУБИН АБДУЛЛИН:
«КАЗАН КОНСЕРВАТОРИЯСЕ – ХАЛЫКАРА КӨНДӘШЛЕК ДӘРӘҖӘСЕНДӘГЕ УКУ ЙОРТЫ»

15 гыйнварда композитор, җәмәгать эшлеклесе, педагог, Социалистик Хезмәт Герое, СССРның халык артисты, Казан консерваториясен оештыру инициаторы һәм аның беренче ректоры Нәҗип Җиһановның тууына 110 ел тулды. Журналыбызга биргән интервьюсында Н. Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе ректоры Рубин Абдуллин үзенең легендар маэстро белән аралашуын искә ала һәм музыкаль белем бирү үзәгенең бүгенгесе турында сөйли.

– **Җиһанов белән ничек таныштыгыз һәм консерватория язмышында ул нинди роль уйнады?**

– Нәҗип Гаязович белән беренче очрашуыбызны искә төшерәм, мин ул чакта махсус музыка мәктәбенә укырга керергә килгән малай идем. Киләчәктә бу мәктәп чыгарылышы укучыларының консерваториягә югары профессиональ әзерлек белән киләчәкләрен аңлап, беренче кабул итү комиссиясенә ул үзе җитәкчелек итте. Сүз уңаеннан, безнең мәктәпкә 60 яшь тула. Хәзер инде һич шикләнмичә әйтергә мөмкин – дөрес сайлаган ул, өлкән буын һәм яшьләр арасындагы дәвамчанлыкны саклап калу мөмкинлеген күздә тотып, киләчәккә юнәлешне дөрес биргән. Бу – алдан күрә белү, нәкъ шуңа күрә дә уку йортының беренче чыгарылышлары хәзер профессорлар, консерваториядә кафедраларны җитәклиләр, мәктәптә аларның үз класслары бар.

Консерватория ачылганчы, Нәҗип Гаязович Татарстан филармониясе һәм опера театрының сәнгать җитәкчесе булып эшли. Ул чакта Мәскәү консерваториясе каршында Татар музыка сәнгате студиясе оешкан була, һәм анда безнең бик күп күренекле композиторларыбыз белем һәм мәдәният нигезләрен үзләштергән. Әмма милли анклав буларак, музыкада милли үзенчәлекне саклап калу өчен, Казанга һәм Татарстанга үз институты таләп ителә. Аның базасында симфоник оркестрның – флейтадан башлап контрабаска кадәр – барлык белгечлекләре буенча музыкантлар әзерләү мөмкинлеге булсын өчен кирәк була ул. Җиһановның «у нас поштучное производство» дигән игътибарга лаек гыйбарәсе һәр музыкантның шәхесен аерым «шомарту»ны күздә тота иде. Рухи өлкәне югары күтәрү өчен музыкантны үстерүнең профессиональ мәктәбе

Фото: Александр Ефремов

кирәклеген бик яхшы аңлый иде ул. Аның энергиясе һәм таланты консерваторияне илнең җимерелгән икътисады һәм чиксез зур кеше корбаннары шартларында, рухи кризис хөкем сөргән сугыштан соңгы авыр елларда ачарга мөмкинлек бирә. Ул 1945 елның 13 апрелендә Халык комиссарлары советы карары белән ачыла.

– Консерваториянең ул вакыттагы эше, беренче нәтиҗәләр һәм күренекле чыгарылышлар турында сөйләгез әле.

– Беренче чыгарылышлар арасында – бүгенге көндә Европа гына түгел, ә бәлки бөтен дөнья сәнгате йолдызы Софья Гобәйдуллина. Софья Әсгатовна, фортепьяно классын тәмамлаганнан соң, Җиһановтан белемен композиция юнәлешендә дәвам итәргә тәкъдимнамә ала – бу талантны шулкадәр нечкә тоемлау түгелмени? Аның белән бергә шулай ук күренекле Алмаз Закирович Монасыйпов та укый – ул виолончелист, композитор һәм дирижёр буларак консерваторияне өч тапкыр тәмамлый. Минем мәктәптәге сабакташларым Миша Плетнёв, Юра Егоров – бер дигән пианистлар, алар бөтен дөньяга танылган. Безнең симфоник оркестр, Натан Григорьевич Рахлин килгәннән соң, консерваториянең актлар залында туды.

Нәкъ менә Җиһанов, учреждениегә орган бирүләрен сорап, СССР Мәдәният министрлыгына кат-кат мөрәҗәгать итте, һәм бу хыял 1972 елда тормышка ашты. Хәтеремдә, бервакыт мин, Рахлин концертмейстеры булып эшләгән чагымда, качып кына ярымкараңгы залга кереп, инструментка сокланып карап тора идем. Көтмәгәндә Җиһановның тавышы ишетелде. Ул, тыюны бозганга бераз шелтәләп алганнан соң, миңа үземне органист сыйфатында сынап карарга тәкъдим итте. Шуннан соңгы тормышым «аңа кадәрге» һәм «аннан соңгы»га бүленде. Җиһанов музыка мәдәниятенең югары дәрәҗәсенә омтылырга рухландыра иде. Әлбәттә, ул билгеләгән барлык максатлар да тулысынча тормышка аша алмады. Планнар да гаять киң колачлы иде бит, ул администратор буларак та хезмәт итте, шул ук вакытта 17 симфония, 10 нан артык опера һәм балет та язарга өлгерде. Бервакыт мин аннан: «Ә сез музыканы кайчан язасыз?» – дип кызыксындым. «Иртән, төшемә кергән барлык фикерләрем һәм теләкләремне партитурага күчереп өлгерер өчен», – дип җавап бирде. Бер үк шәхестә көчле оештыручы, музыкаль иҗат һәм рухи мәдәният үсеше идеяләре «двигателе» яшәде, бу яхшы мәгънәсендә атом-төш коралына тиң симбиоз иде.

– Сез нинди чыгарылышлар әзерлисез? Безнең бүгенге тормыш шартларында яшь музыкантлар белән композиторларга үз-үзләрен табу авыр түгелме?

– Бирегә үз-үзләрен музыкада сынарга теләгән кешеләр килә. Әгәр шул теләк белән янмасаң, син сәнгать өчен югалган дигән сүз. Без иң элек кеше тәрбиялибез, аннары гына музыкантны, скрипачны яисә пианистны. Студентка белем алу системасын нindидер баскыч, трамплин итеп файдалану өчен, күн саен тырышырга кирәк. Һәм бу искиткеч авыр эш. Бүгенге көндә без илнең чираттагы үзгәртеп кору этабына, икътисадый мөнәсәбәтләрнең җимерелүенә һәм сәнгать турындагы карашларның «хезмәт күрсәтү өлкәсе» төшенчәсенә алыштырылуына килеп җиттек. Димәк, сәхнәгә чыгу – ул товар? Әмма бу бит сәнгать идеясен рухилыктан матди түбәнчелек дәрәҗәсенә төшерә. Хәзер барлык массакүләм матбугат чараларыннан «син уңышлы булырга тиеш» дигән сүзләр яңгырый, әмма монда кеше табигатенә карата бик зур диссонанс бар. Ориентирлар менә ничек авышты, «сәүдә» өлкәсенә әйләнү асыл кыйммәтләрнең юылуына китерде. Мин мондый күренешләргә җаным-тәнем белән каршы. Әгәр дә студент фатир, машина сатып алырга тели икән, моны аңлап була. Ләкин бу матди идея аны югары иҗади максатлардан читкә алып китә икән, ул инде «безнең» кеше түгел.

– Консерватория Яңа елга нинди кәеф белән керә?

– Без консерваториядә иң талантлы кешеләрне эзләгәндә сирәк ялгышабыз – биредә абруйлы халыкара конкурсларның йөзләрчә лауреаты бар, яшьләрнең 20 проценты уку процессында ук танылуга ирешә. Педагоглар коллективы – солистлар, уйнаучы тренерлар ансамбле, ә студентлар еш кына үз укытучыларын «рухи аталары» дип саный. Казан консерваториясенең конкурентлык дәрәҗәсе бик югары – халыкара дәрәҗә ул: безнең чыгарылыш студентлары арасында Зур театр, Мариинка, Ковент-Гарден, Ла Скала театрлары солистлары бар. Интернет ярдәмендә безнең системада тәрбияләнгән күп кенә яшь музыкантларга киң мөмкинлекләр ачыла. Алар Берлинда, Чикагода барган кастинглар турында белеп ала... һәм кайчакта китеп тә бара. Киңәшмәләрнең берсендә минем сүзләремнән соң һавада тынлык урнашты: «Россия үз музыкантлары белән Көнбатышка тагын күпме спонсорлык итәчәк?» Шунысын да әйтим: студентларыбызның биштән бере – чит илләрдән килгән. Шуңа күрә без хәзер яшьләргә уңайлы социаль шартлар булдыру өчен тулай торак төзибез. Ел саен консерваторияне 130-140 кеше тәмамлый. КФУ, КАИ яисә КХТИ белән чагыштырганда, бу күп түгел, әмма без зәркән җитештерүе кебек. Җиһанов Казан консерваториясенең дөнья дәрәҗәсендә булуы турында хыялланган иде. Без аның хыялына хилафлык китермибез.

БЕЛЕШМӘ

Нәҗип Җиһановның әсәрләре даими рәвештә консерватория солистлары һәм иҗади коллективларының концерт программаларына кертелә. Опера студиясе Җиһановның «Алтынчәч», «Түләк» операларындагы мирасына мөрәҗәгать итте. «Музыкальная жизнь» журналы версиясе буенча Казан консерваториясе опера студиясенең Нәҗип Җиһанов мирасына мөрәҗәгате 2019–2020 нче концерт сезоны трендларының берсе дип танылды. Даими рәвештә композитор мирасына багышлап халыкара статуслы «Җиһанов укулары» фәнни конференцияләре оештырыла, Нәҗип Җиһанов әсәрләре бастырып чыгарыла. Музыка сәнгатенең әлеге күренекле шәхесе юбилее хөрмәтенә уздырылган Нәҗип Җиһанов исемендәге композиторлар конкурсы турында аерым әйтеп үтәргә кирәк. Истәлекле даталарга концертлар һәм студентларның фәнни чаралары багышлана. Консерватория педагоглары композитор Нәҗип Җиһанов музее белән тыгыз хезмәттәшлек итәләр: лекцияләр укыйлар, концертлар үткәрәләр. Консерваториянең төп корпусы фойесында композиторның бюсты куелган. Җиһанов заманы дәвам итә...

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN



@protatarstan

#ТатарстанВДеталях

#ЧитайТатарстан

#ЛюбимыйТатарстан

#ЖурналТатарстан

#ЖивиВТатарстане

Реклама 16+

Безнең Инстаграмда – «Татарстан»ның йөрәге!

Игелекле эшләр /

Акыллы гамәлләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Стратегиядә беренче урында **нәрсә** булырга тиеш

Татар кызы Мәскәүдә **кемне** ана теленә өйрәтә

Чит илләрдә Яңа елны **ничек** каршылыйлар

ИНДУС ТАҺИРОВНЫҢ ТОРМЫШ ЛИНИЯСЕ

Автор: Руфия Фазылова



Автор фотосы

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

Индус Ризак улы Таһиров, тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе академигы, сәясәтче. 1936 елның 24 маенда Лениногорск районы, Иске Шөгер авылында туа. Урта белемне Әлмәт шәһәрендә ала. 1963 елда – КДУның тарих һәм филология факультетын, аннан соң аспирантураны тәмамлый. 1966 елдан КДУда укыта. 1967 елда – кандидатлык диссертациясен, 1979 елда докторлык диссертациясен яклый. 1980 елдан– профессор, КДУның тарих кафедрасы деканы итеп билгеләнә. 1995 елда – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, 1992 елның июль аенда беренче Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе итеп куела һәм шул вазыйфада 2002 елга кадәр эшли.

– Әти сугышка киткәндә миңа биш кенә яшь иде. Әмма ул көнне бик яхшы хәтерлим. Сугышка әти Лениногорск районының Иске Шөгер авылыннан алынды. Ул вакытта кечкенә энебез Энгельгә бер яшь кенә иде, шуңа әни яшь бала белән өйдә калды. Әтине озатырга станциягә абый белән мин бардым. Ул миннән өч яшькә зуррак. Әтиебез җырга оста, шигъри җанлы, моңлы кеше иде. Тиз арада безне кибеткә алып кереп, мандолина сатып алып бирде. «Мин кайтканчы уйнарга өйрәнегез!» – диде. Әтине сугышка озату авыр булса да, кулда мандолина булгач, кош тоткан кебек сөенештек. Кул болгап, озатып калдык.

Сүзебездә тордык – өчебез дә шул мандолинада уйнарга өйрәндек. Тик әти генә күрә алмады, сугышта һәлак булды... Мандолинада уйнарга безне әниебезнең дусты, мөгаллимә Зифа апа Басыйрова өйрәтте. Ул бу инструментта бик матур уйный иде. Аның бу дөньядан киткәненә биш еллап кына. Шул көнгә кадәр аралашып яшәдек.

Әти 1944 елда Латвияне азат иткәндә һәлак булган. Университетны тәмамлагач, аспирантурада белем алганда әтинең каберен эзләп табу максаты белән яши башладым. 1960 нчы елларда Латвиянең Салдус шәһәрендәге туганнар каберлегендә җирләнгәнен ачыкладым. Шунда әнине дә алып бардык. Әни әти кабере янында намаз укыды, елады, аның белән хушлашты. Әтинең кабереннән җир алып кайтты һәм шул туфракка гөл утыртты. Күзне иркәләп, күп еллар тәрәзә төбендә чәчәк атып утырды ул гөл.

Әти турында тагын шуны әйтәсем килә: бик матур җырлый иде ул. Бу сәләт безгә дә күчкән. Балаларыбыз да җыр-моңга гашыйк кешеләр. Халык җырларына мөкиббән без. Ни кызганыч, бүген халык җырларын бик сирәк ишетәбез. Яшерен-батырын түгел, хәзерге җырлар тыпыр-тыпыр басар, селкенер өчен генә. Күңелгә үтеп кермиләр.

Элек концертлардан бер көч, рух күтәренкелеге алып кайта идек. Сине бик озак озатып йөри торган берәр җыр була иде. Ә хәзерге җырлар күңелдә, истә калмый. Гасырлар буе сакланып килгән милли моңнарыбыз югалып бара сыман. Ә безгә аны югалтырга ярамый. Милли моң, тел – татарның канында. Бу иң кадерле кыйммәтләр.

Әни ялгызы өч ир бала үстерде. Әлбәттә, аңа җиңел түгел иде. Әни Түбән Чыршылы урта мәктәбендә директор вазыйфасын башкарды. Анда күрше авыллардан да килеп укыдылар. Мәктәптә балалар күп, бик авыр еллар. Ни ашарга, ни кияргә дигәндәй... Халыкның күңелен күрү өчен, сугыш вакытында укытучылар концерт, спектакльләр куйдылар. Әнинең безнең белән утырырга вакыты да булмады инде.

> – Россияне Татарстан тарката дип, безне гаепләп тә чыктылар. Һич кенә дә алай түгел. Без, махсус үзебезнең статусны күтәреп, бердәм, яңа барлыкка килгән Советлар илендә яшәүне максат итеп куйдык. Шунлыктан Россия Президенты Борис Ельцин һәм Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, ике делегация төзеп, шушы мөнәсәбәтләрне җайлауга кереште.

Әти сугышка киткәч, без яшәргә Түбән Чыршылы мәктәбенә күчендек. Директор булгач, ике авыл арасында йөргәнче дип, әни шундый карарга килде. Мәктәпнең аерым бер бүлмәсен торак итеп ясадылар. Шунда мич ягтык, ашарга пешердек. Безнең кәҗә бар иде. Ул безгә зур ярдәмче булды.

Сугыш беткәннән соң, без кире әтинең туган авылы – Иске Шөгергә кайттык. Һәм мин гел татарча укыган бала, рус мәктәбенә укырга киттем. Түбән Чыршылыда чагында әни рус китапларын укырга бирә, ә мин аңламый идем. Тик ничектер русча укырга тиз өйрәнелде. Күрәсең, телләр өйрәнүгә сәләт булган. Француз, инглиз, немец телләрен беләм. Французча иркен аралаша алам.

Урта мәктәпне мин Әлмәттә тәмамладым. Иске Шөгердә берничә ел яшәгәннән соң, әнинең туган ягына күченеп киттек. Дөресрәге, әнинең сугыштан кайткан олы абыйсы безне алып китте. «Балаларыңны аякка бастырышырмын», – дип тә әйткән әнигә. Һәм чынлап шулай булды да.

Сәясәт темасына күчкәндә... Татарстан СССР белән союздаш республика буларак килешү имзаларга тиеш иде. 1991 елның 19 августында Минтимер Шәймиев Борис Ельцин белән очрашып, без сөйләшкән документка соңгы нокта куелуын көттек. Ләкин ГКЧП килеп чыкты. Безгә берничә көн җитмәде. Шул вакытта бу документ имзаланган булса, Россиядә ни генә булмасын, без мөстәкыйль дәүләтле халык булыр идек... Нишлисең, тарих менә шундый борылыш алды.

Россияне Татарстан тарката дип, безне гаепләп тә чыктылар. Һич кенә дә алай түгел. Без, махсус үзебезнең статусны күтәреп, бердәм, яңа барлыкка килгән Советлар илендә яшәүне максат итеп куйдык. Шунлыктан Россия Президенты Борис Ельцин һәм Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, ике делегация төзеп, шушы мөнәсәбәтләрне җайлауга кереште.

Кем күпме генә әйтсә дә, татар теленең киләчәге бик зур. Аңа карата кысу күбрәк булган саен, халык ныграк уяна. Һәм бүген моның ачык мисалын күрәбез. Татарстанда гына түгел, чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез дә уянды. Туган телемдә аралашасым килә дип, дөньяның төрле почмакларыннан яшьләр берберсе белән хатлар алыша.

Һәр заман тел, милләт өчен үзенчә көрәшә. 90 нчы елларда «Ирек!» – дип трибуналарга чыгып кычкырсак, «Милләт!» дип мәйданнар җыйсак, бүген алай эшләмиләр. Дөрес, хәзер андый мөмкинлек тә юк. Тик барыбер милләтне сакларга теләүче кешеләр бик күп. Алар социаль челтәрләрдә бу юнәлештә актив эш алып бара. Нишлисең, заманасы шундый: бүген бар кеше дә интернетта.

Хәтта безнең татар яшьләренең актив, кыю, белемле булулары рус егет-кызларының да туган телебезгә карата мөнәсәбәтен үзгәртә. Алар да татарча өйрәнә башлады. Минем шундый берничә конкрет мисалым бар. Бүгенге яшьләр заманча фикер йөртә, һәр милләткә ихтирам белән карыйлар. Һәрхәлдә, мин шулай сизәм, тоям.

Мәчетләрдә татар теле укытуны бик хуплыйм. Безнең халык гомергә мәдрәсәдә белем алган һәм иң акыллы халыкларның берсе саналган. Бүгенге көндә мөфтиятнең йөздән артык курсы бар. Анда бит гади муллалар тел өйрәтеп утырмый, ә шушы эшкә әзерлекле укытучыларны тарталар.

Чит төбәкләрдә яшәүче татарлар белән күп аралаштым. Алар мине, иң беренче чиратта, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының беренче рәисе итеп истә калдырды. Конгресста эшләгән чакта, теләсә кайсы ишеккә барып ачарга мөмкинлек булды. Һәр җирдә колач җәеп каршы алдылар. Бүген Конгресста хәл бүтәнчә, дип уйлыйм...

Милли Шура оештыру Бөтендөнья татар конгрессының дәрәҗәсен үстерү максаты белән эшләнде, дип уйлыйм. Васыйл Шәйхразыевны хөкүмәт кешесе буларак бөтен җирдә кабул итәләр. Тик ни кызганыч, бүген әлеге оешма иҗтимагый булудан туктады, дәүләт структурасына әйләнде кебек. Ә безнең чорда Бөтендөнья татар конгрессы чын мөстәкыйль оешма иде.

Хәтта бүгенге көндә кайбер оешмалар, Бөтендөнья татар конгрессыннан чыгып, Мәскәү татар штабына керергә теләк белдерәләр. Белгәнебезчә, мәскәүлеләрне Конгресс составыннан чыгардылар. Һәм алар үзләренчә яши, эшли. Күптән түгел Мәскәү татар штабы мине дә утырышларына чакырды. Арада яшьләр шактый. Бик күп сораулар яудырдылар. Җанлы сөйләшү, рәхәт очрашу булды ул.

Күп бәхәсләр кузгаткан татар халкының үсеш Стратегиясенең өстән кушылган документ икәнен онытырга ярамый. Һәм аны Конгресс шулай җиренә җиткереп эшләде дә. Стратегиядә беренче урында нәрсә булырга тиеш? Милләт. Аның бүгенгесе, киләчәге. Икенчесе – дәүләт. Татарстанның мөстәкыйль дәүләте булამы-юкмы? Конкрет сорауларга конкрет җаваплар кирәк иде. Хәер, Стратегияне мин бары рәсми документ итеп кенә кабул итәм. Аерым кешеләрдән кала, кем күрер аны.

> “
>
> – Ниндидер авырлык килеп чыкса, кеше бәхетле булганмын икән дип уйлый, сәламәтлеге какшаса да, шундый фикерләр туа. Мин тормышта төрлесен күрдем, кайгы-хәсрәте дә җитәрлек булды, шатлык-сөенечләре дә. Нәтиҗәле гомер кичердем, дип саныйм.

Аерым бер документ түгел, яшәү рәвешебез тантана итәргә тиеш. Монысы иң мөһиме. Бүген Татарстан икътисады, милли яшәеше, башка күрсәткечләр буенча алдынгы урыннарда бара. Татарлар яшәячәк, чәчәк атачак, дип уйлыйм. Монысы – бәхәссез.

КДУның тарих факультетының беренче деканы мин. Шушы факультет эшли башлаганда бездә өч кенә доктор иде. Иң беренче үзебезнең Докторлык советын булдырдык. Нәтиҗәдә егермегә якын доктор үстереп чыгардык. Әле күрше республикаларга күпме тарих галимнәре әзерләдек. Ни кызганыч, бүгенге көндә тарих факультеты юк. Мин җитәкләгән кафедра бөтенләй башка юнәлештә эшли. Хәер, аның университеты да бүтән иде. Моны начар да, яхшы да димим, вакыт күрсәтер. Мин университетның дошманы түгел, үзләренчә хәл итсеннәр...

Ниндидер авырлык килеп чыкса, кеше бәхетле булганмын икән дип уйлый, сәламәтлеге какшаса да, шундый фикерләр туа. Мин тормышта төрлесен күрдем, кайгы-хәсрәте дә җитәрлек булды, шатлык-сөенечләре дә. Нәтиҗәле гомер кичердем, дип саныйм. Ә быелгы елга килгәндә, милләтебез бик зур югалтулар кичерде. Якыннан аралашкан бөек шәхесләр дә китте. Бик аяныч...

Ике ел элек хатыным вафат булды. Өйләнешүебезгә нәкъ 55 ел тулган көнне бакыйлыкка күчте ул. Бик акыллы, тугры хатын иде, төп терәгем булды. Юксынам үзен... Әле менә бүген дә улым белән зиратка барырга җыенабыз.

Ашау режимына килгәндә, үземне чикләмим. Элек нәрсә ашаган булсам, хәзер дә шулай туклanам. Иртән эремчек, бал белән чәй эчәм. Көндез аш ашыйм. Без аны күп вакыт Илдар улым белән бергә ашыйбыз, ул көн саен минем янга килә. Кичен икенче ашларга өстенлек бирәм. Шулай да ашау минем өчен культ дәрәҗәсендә түгел. Күп ашау беркайчан максат булмады.

Көн саен ике сәгать саф һавада йөрим. Физик күнегүләр эшлим, хәтта мәтәлчек тә атынам. Моннан тыш программага эш өстәле артында утыру да кергән. Баш миен эшсез тотарга ярамый...

МӘСКӘҮЛЕЛӘР ТАТАРЧА ӨЙРӘНӘ

Автор: Руфия Фазылова

«И туган тел, и матур тел,
әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем,
син туган тел аркылы...»

Халкыбызның гимнына әйләнгән бу җыр быел тагын да күбрәк яңгырар, мөгаен. Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның карары нигезендә 2021 ел Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде. Җитәкче шул рәвешле туган телләргә игътибар тагын да артыр дип ниятли. Хәер, туган теленә битараф булмаган кешеләргә махсус ел игълан ителмәсә дә, ул Ана телендә сөйләшә, балаларына үз телендә китап укый. Кайда булуына карамастан, милләтем, телем, дип җан ата. Җан ата дигәндә, тәгаен эш эшләүне күздә тотам, мәсәлән, Мәскәүдә яшәүче Лилиана Сафина кебек якташыбызны. Россия башкаласын кыз үзенчә яулый – «Умарта» татар теле мәктәбен ача. Нәтиҗәдә Лилиана дистә ел эчендә Мәскәү татарлары арасында гына түгел, төрле кыйтгаларда яшәүче милләттәшләребез арасында да танылу ала.

– Лилиана, сүзне танышудан башлыйк әле: Кайбыч кызы Мәскәүгә ничек барып чыкты икән?

– Бу сорау ничектер «Мәскәү кайда да, Кайбыч районы кайда» кебегрәк яңгырый. Мин Тау ягында туып-үскән кыз. Туган авылым Иске Тәрбит авылы, Чувашия Республикасындагы Канаш шәһәреннән 30 чакрым ераклыкта урнашкан. Шуңа да 2001 елда Казанга караганда, Мәскәүгә барып кайтасы күпкә җайлырак, ягъни юл уңае иде.

Авылда үскән яшьләр үзләрен баштарак, шәһәр балалары белән чагыштырганда, кимсенгәнрәк итеп тоя шикелле. Миндә дә андый хис булып алды. Тик бездә шәһәр баласында булмаган сыйфатлар күп, мәсәлән, эшнең кадерен белү. Тумышы белән авылдан булган хәзерге җитәкчеләр мисалында бу тагын да әйбәтрәк күренә, дип уйлыйм.

– Сез бер дә кимсенгән кызга охшамагансыз. Казан гына түгел, Мәскәүгә үк киткәнсез бит. Бәлки, биредә калып укырга җиңелрәк булган булыр иде, ничек уйлыйсыз?

– Дөресен генә әйткәндә, татар яшьләренең һәрберсенә: «Татарстанда калып, шунда яшәгез, гаилә корыгыз», – дип теләр идем. Ә минем язмыш китабыма шулай язылган, күрәсең. Мәскәүгә барып белем алырга мәҗбүр булдым. Хәзер инде киресенчә, язмышның шундый борылышына рәхмәтлемен...

Мәктәпне тәмамлагач, Мәскәү дәүләт педагогия университетының филология факультетына – татар бүлегенә кердем. (2000нче елларда шундый бүлек бар иде!) Студент чагымнан ук татар телен укыта башладым. Бүген мин Мәскәү автомобиль-юл техник университетында чит ил кешеләрен рус теленә өйрәтәм. Шулай ук «Умарта» татар теле мәктәбен җитәклим, «Эхо Москвы» радиосында татар телен өйрәтү буенча тапшыру эшлибез.

– «Эхо Москвы» радиокомпаниясендәге проект турында сөйләшик әле. Әлеге проектыгызның максатын нидә күрдегез?

– Татар телен популярлаштыру, ишеттерү, кулллану һәм өйрәтү. Минем өчен бу интеллектуаль эш. Нишләптер безнең халыкта интеллектуаль эшкә, ягъни баш белән эшләүгә җитди караш юк кебек. Кунакка барып кайткач та, гадәттә беренче сорау: «Ничек карадылар?» яки «Ни белән сыйладылар?». «Нәрсә турында сөйләштегез?», - дип, сирәк кенә сорап куябыз. Бу гаиләдә тәрбияләнергә тиештер. Интеллектуаллар – милләтнең рухи мәдәниятен үстерүчеләр. Минемчә, бөтен эш тә акчага гына бәйләнергә тиеш түгел. Әгәр баш мие эштән рәхәтлек таба икән, җанга да ләззәт була ул. Шәхсән үзем бу балансны күптән түгел генә ирештем. Рус җәмгыятендә баш белән эшләүче кешеләргә күбрәк ихтирам белән карыйлар кебек тоела.

> “
>
> – Нишләптер безнең халыкта интеллектуаль эшкә җитди караш юк кебек. Кунакка барып кайткач та, гадәттә беренче сорау: «Ничек карадылар?» яки «Ни белән сыйладылар?». «Нәрсә турында сөйләштегез?», – дип, сирәк кенә сорап куябыз. Бу гаиләдә тәрбияләнергә тиештер. Интеллектуаллар – милләтнең рухи мәдәниятен үстерүчеләр. Минемчә, бөтен эш тә акчага гына бәйләнергә тиеш түгел.

– Бүген без аерым шәхесләрнең, җәмәгать эшлеклеләренең татар теле өчен борчылуларын, хәтта ниндидер көрәш алып баруларын сизәбез. Мәскәүдә бу сиземәме?

– Холкым буенча мин көрәшче. Тик Мәскәү татар теле өчен көрәш алып барырлык шәһәр түгел. Минем миссия – милли үзаңын эзләп йөрүчеләр, руслар арасында туып-үсеп, яшәп, үзен татар буларак саклап калырга теләүчеләргә ярдәм кулын сузу. Укучыларымның уңышларын, аларның бу дөньяга кабат татарча аваз салуларын күргәч кенә, үземә бәя бирә башладым. Һөнәрем үземне яхшырак аңларга, шәхес буларак кабул итәргә ярдәм итте.

– Сезнең курсларга йөрүчеләрне яшь үзенчәлеге, һөнәрләре буенча аерсак, кемнәр алар?

– Дөресен генә әйткәндә, «Умарта»га халык тел өйрәнү өчен генә килми. Тел аша татар мәдәниятенә кагылу теләге бу. Күп очракта әти-әниләре ана телен өйрәтмичә үстергән, туган телсез калган «нарасыйлар». Аерым яшькә җиткәч (ә бәлки, бер вакыйга, бер җыр тыңлаганнан соң) андый кешеләрнең эчләре поша башлый. Эчке диалог югала, чөнки туган телсез татар булу - һәр кеше өчен җан ярасы. Алар буйга җиткән егет-кызлар, абый-апалар, әби-бабайлар булырга мөмкин. Һөнәрләре дә мөһим түгел. Гадәттә, тел өйрәнергә этәргән сәбәпләрнең һәркайсының үз тарихы була. Безнең курсларга килеп, алар шул яраларын дәвалыйлар.

– «Умарта» мәктәбенә татарлар гына йөриме?

– Әлбәттә, күпчелеге тамырлары Россиянең төрле төбәкләреннән булган татарлар. Моннан тыш, башка милләт кешеләре дә байтак: руслар, чувашлар, грузиннар, яһүдләр һ.б. Кырым татарлары шактый. Быел, мәсәлән, Украина егете дә бар. Ул башта үзенең туган телен үзләштергән, хәзер татар телен яратып укый. Катнаш гаиләләрдә туып-үсүчеләр дә күп бездә.

Татар теле белән башка милләт кешесенең кызыксынуын нонсенс итеп карамыйм мин. Ничектер туган телебезнең дәрәҗәсен төшерү кебек була ул. Кытайлар, ник кытай телен өйрәнәсең, руслар, сиңа рус теле ник кирәк, дип утырмыйлар бит... Безгә дә мондый күренешләрне тыныч кабул итәргә өйрәнергә кирәк.

– Татар телен өйрәтү буенча махсус методикагыз бар икән. Шул хакта тәфсилләбрәк сөйләсәгез иде.

– Минем өчен татар теле һөнәр генә түгел, яратып башкара торган кул эшенә әйләнеп китте бугай. Методиканың нигезендә туган телгә карата зур мәхәббәт бар. Бу башны югалттыра торган мәхәббәт... Ә фәнни яктан карасак, татар телен бөтен өлкәдәге кулланылышына өйрәтәм. Кушып-алу булсынмы ул, әдәби әсәрме, татарча постлар язумы, җырларның эчтәлегенә төшенүме, татарча төшләр күрүме... Татар теле турында дөньямны онытып сәгатьләр, көннәр буе сөйләшә алам. Татар телен төрле тирәнлектә өйрәнеп була, шул исәптән гомер буе да.

– Сезнең: «Бер ел эчендә студентны (укучыны) татарча сөйләшергә өйрәтеп була», – дигән сүзләрегезне укыганым бар... Тел өйрәнү өчен аерым бер сәләт кирәкме? Әллә инде теләк булу да җитәме?

– Кешенең теләге белән мотивациясе булса, ул барысын да булдыра. Монда да шулай: теләк, дисциплина, сөйләшергә курыкмау. Әгәр укучы вакыт табып, биремнәрне башкарып барса, максатына ирешә.

Татарча сөйләшергә өйрәнергә теләүчеләрне һәрберсен сукмак буенча ияртеп барырга әзермен, олы юлга чыкканчы. Әлбәттә, бер ел эчендә Дәүләт Советында Татарстанның 2021 елда социаль-икътисад үсеше турында нотык сөйли алмаса да (моның өчен бераз күбрәк вакыт кирәк), көнкүреш турында сөйләшергә өйрәнеп була.

Тагын бер күзәтү: күп кенә рус телле татарларыбызда татарча аралаша башлар өчен ниндидер блок тора. «Татар телендә сөйләшергә оялдым», – ди алар еш кына. Минемчә, бу психологлар эше, монда тирәнрәк карарга кирәк. Моны татар психологиясе белән шөгыльләнүчеләр өчен, бик киң юнәлеш дип уйлыйм.

“

– Тагын бер күзәтү: күп кенә рус телле татарларыбызда татарча аралаша башлар өчен ниндидер блок тора. «Татар телендә сөйләшергә оялдым», – ди алар еш кына. Минемчә, бу психологлар эше, монда тирәнрәк карарга кирәк. Моны татар психологиясе белән шөгыльләнүчеләр өчен, бик киң юнәлеш дип уйлыйм.

– Офлайн укыту белән онлайн укытуның нәтиҗәсе бармы, ничек уйлыйсыз?

– Татар телен өйрәнү процессы иң беренче мәдәнияткә барып тоташа. Бу аралашу урыны, тарихи җирлекләреннән читтә яшәүчеләрне берләштерү чарасы да. Монда аралашалар, эшлекле элемтәләрне ныгыталар, дуслашалар, гаилә коралар. Тыгыз аралашу татар телен үзләштерүгә дә уңай тәэсир итә. Ни кызганыч, онлайн форматта кешеләргә мондый шартлар тудырасы кыенрак. Онлайн татар теленә өйрәнүчеләрне ике төркемгә бүлеп була. Татар телле өлкәләрдә гомер кичерүчеләр, мисал өчен Башкортостанда яшәүче укучыларымның максаты – татар телле мохиткә кереп китеп, туган телдә аралаша башлау. Андыйларга күпкә җиңелрәк, чөнки «татарны очраттың икән – сөйләш» принцибы эшли. Ә Англиядә яки Россиядәге Благовещенск шәһәрендә бу кыен, чөнки өйрәнгән телеңне куллану мөмкинлекләре бик аз. Тик ничек кенә булмасын, бүгенге технологияләр ярдәмендә дөнья күләмендә дуслар табып аралашып яшәргә була.

– «Умарта» проектына матди яктан кемнәр ярдәм итә?

– Матди яктан ярдәм юк. Ә менә мәгълүмати яктан Татарстанның Вәкаләтле вәкиллегенең, төрле иҗтимагый оешмаларының ярдәмен күреп, сизеп яшим.

– Татарстан белән элемтә бармы?

– Әлбәттә, бар. Беренчедән, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның игътибары өчен рәхмәтлемен. Икенчедән, Татарстаныбызда дусларым күп. Өченчедән, минем туган ягым – Кайбыч районының Иске Тәрбит авылы. Бу авылда минем якын кешеләрем, әтием белән әнием, туганнарым яши.

– 17 ел элек башлаган эшегезгә нәтиҗә ясасак, нинди фикергә килдегез? Методика, эш алымнарын үзгәртергә кирәкмиме? Алга планнар нинди?

– Кеше гел үзгәрергә тиеш. Методика гына түгел, карашлар да үзгәреп тора. Укучыларның таләпләре дә гел төрле. Яраклашып кабул итә белергә кирәк, үзеңнең юлыңнан, сүзеңнән тайпылмыйча гына. Гел грамматиканы хурлап утырып эш бармый, грамматиканы юк итү, тарихны сызып атып, юкка чыгару белән бер, дип уйлыйм мин. Аннан терсәкне тешләп булмау ихтималы туарга мөмкин. Йөзгә карап: «Нинди тел бу, килешсез-затсыз!» – дигән заманнарны әле тарих кына түгел, күпләребез хәтерли...

Планнар эшләргә, үсәргә, яратырга, бәхетле һәм исән-сау булырга язсын! Күз курка – кул эшли, диләр бит.

PRESSA

ЯҢА ЕЛ КИЧЕНДӘ...

Әзерләде:
Руфия Фазылова

Бер, ике, өч... – сукты бит Яңа елның сәгате. Әйе, җиһанга яңа 2021 ел килде. Быел Яңа елны бигрәк зур түземсезлек белән көттек: ковид, башка зәхмәтләрнең иске елда калуын телибез... Бирсен Ходай! Барлык борчу-кайгыларны, куркуларны Күсе үзе белән алып китсен...

Ә чит илләрдә Яңа елны ничек каршы алганнар? Кыш бабайга анда нинди мөнәсәбәт? Чит илләрдә яшәүче милләттәшләребездән шул хакта сораштык.

«ДЕКАБРЬ АЗАГЫНДА ЧЫРШЫЛАРНЫ ТАШЛЫЙЛАР»

Наилә Бикчәнтәева, Нью-Йорк

– Башка бик күп илләрдә Яңа елга караш бүтән, ул Россиядәге кебек гаилә бәйрәме саналмый. 31 декабрь алар өчен ел бетүне аңлата, димәк, яңа календарь сатып алып, элеп куярга кирәк. Белгәнебезчә, Яңа елны Петр I уйлап чыгарган. Ә Америкага Петр I законы кагылмаган.

Декабрь аенда Америка халкы да чыршы бизи, дөрес, аның исеме башкача яңгырый – «Раштуа агачы» дип атала. 24, 25 декабрь көннәрендә халык бер-берсен бәйрәм белән котлый, якын иткән кешеләренә бүләк өләшә. Гадәттә, матур итеп төрелгән, бизәлгән андый тартмаларны Раштуа агачы астына куялар. Соңгы елларда бу күренеш Россиядә дә бик популярлашты. Миңа калса, Яңа елга бүләк бирешү безгә чит илләрдән кергән.

Америкада 28 декабрьдә бизәлгән чыршыларны ташлыйлар. Бу Яңа елга мөнәсәбәтне күрсәтә торган төп күрсәткечтер, минемчә.

Раштуа өстәленә махсус аерым ризыклар әзерләмиләр. Төп шарт – өй бизәлгән, бәйрәм табыны мул гына түгел, ямьле дә булырга тиеш.

Минем ирем – Америка гражданины. Алар беркайчан да Яңа елны бәйрәм итмәгәннәр. Ә бергә яши башлагач, ул да минем белән 31 декабрь көнне сәгать унике тулганын көтә башлады. Җиңелчә табын әзерлим, шампан шәрабы алабыз. Ә кайнана гадәттәгечә кичке тугызда йокларга ята. Дөрес, башта бер-беребезне якынлашып килүче Яңа ел белән котлыйбыз. Шуның белән бетте. Беренче вакытларда мин бу гадәткә азрак гаҗәпләнә идем, хәзер инде ияләндем.

31 декабрьне бәйрәм итмәсәләр дә, 1 гыйнварда америкалылар ял итә. Бу рәсми рәвештә шулай каралган. Ә аннан соң халык гадәттәгечә эшкә чыга.

Мин Нью-Йоркның Брайтон-Бич районында яшим. Рус телендә аралаша торган өлкәннәр өчен бакчада эшлим. (Өлкәннәр клубы кебек урын ул. Әби-бабайларны автобус иртән өйләреннән барып ала, кичен кайтарып куя. Барысы өчен дә дәүләт акча түли). Бакчада Яңа елны билгеләп үтәбез, чөнки аларның күбесе Россиядән килгән кешеләр. Ә безнең өчен Яңа ел бит ул бик зур бәйрәм.

Тагын шуны әйтим: Яңа елга, дөресрәге, Раштуага Нью-Йорк әкияти шәһәргә әйләнә – төрле утлар балкып торган җанвар сыннары, агачлар, күз явын алырдай бизәкләр... Сүз белән генә әйтеп бетерә торган түгел. Әлеге гүзәллекне ноябрь азагында тудыралар инде. Бер ай дәвамында шундый әкияти шәһәрдә яшибез, фотога төшәбез. Бу матурлыкны күрергә Европаның төрле илләреннән туристлар килә. Нью-Йорк чын мәгънәсендә бәйрәм рухында яши.

Дөрес, быел пандемия аркасында туристлар юк. Америка инде яздан бирле тулы тормыш белән яшәми. Кибетләргә барып, кием-салымны киеп карый алмыйсың, күңел ачу үзәкләре дә эшләми. Әмма халык мондый күренешне тыныч кабул итә, нишлисең, үзебезнең сәламәтлек өчен бит. Яңа 2021 елда бу зәхмәт юкка чыгар, дип ышаныйк. Бөтен җир шары халкы шуны көтә...

«ОТКРЫТКАЛАР БЕЛӘН ӘРҖӘ ТУЛА»



Лилия Вәлиева, Бельгия

– Дөресен генә әйткәндә, Бельгиядә яшәүче милләттәшләребез Яңа елны каршы алырга Мәскәүгә, Санкт-Петербургка йөрергә ярата. Ә биредә калган очракта 31 гыйнвар төнендә урамга чыгабыз. Татарлар, руслар белән бергә шампан шәрабы аттырабыз. Бер-беребезне Яңа ел белән котлыйбыз.

Бельгиядә, гомумән Европада, Россиядәге кебек, шаулап-гөрләп Яңа елны каршы алу гадәте юк. Биредә төп халык 31 декабрьгә игътибар бирми, дисәм дә була. Шуңа да күпләр, бигрәк тә яшьләр, Яңа елны каршы алырга Россиягә барырга тырыша да. Аларга зур бәйрәм, шоу кирәк.

Ни өчен 31 декабрьгә игътибар юк? Европа ул католик зона. Монда католиклар бик тыйнак, алар андый социаль бәйрәмнәрне уздырмаганнар. Биредә

1 Май, 8 Мартны да билгеләмиләр. Ә менә дини бәйрәмнәрне бик зурлап, хөрмәтләп үткәрәләр. (Шулай да соңгы 20 елда Хэллоуин кебек аерым көннәр барлыкка килде.) Тик дини бәйрәмнәр һәрвакыт беренче урында тора. Мисал өчен, апрель аенда Пасханы үткәрәләр. Элек-электән ул ял көне дип игълан ителгән, бүген дә шулай. Йортларны эчтән дә, тыштан да бизиләр. Махсус зур-зур бүләкләр алалар. Кешеләр бер-берсенә кунакка бара, зурлап табын кора. Кыскасы, алар өчен бу бик кадерле, әһәмиятле бәйрәм.

Бельгиялеләр өчен Раштуа бәйрәме дә бик мөһим санала. Ноябрь уртасыннан ук йортларны матурлап бизи башлыйлар. Нәтиҗәдә Раштуага бөтен җир – урамнар, сәүдә үзәкләре бәйрәм рухына күмелә. (Дөрес, пандемия аркасында, быел чикләүләр булды.) Халык, якыннары белән Раштуа бәйрәмен билгеләп уза. Бу бәйрәмнең табыны үзенчәлекле. Россиядә Яңа елга оливье салаты, каз-үрдәк каклаган кебек, биредә Раштуа өстәленә күркә, бәрәңге ризыклары әзерлиләр. Кайсы йортка керсәң дә, шул ризыкларны күрәсең. Аерма – кемдер аларны үзе әзерли, кемдер кафедан заказ биреп ясата.

24 декабрь кыскартылган эш көне санала, чөнки кичке дүрттә кешеләрнең чиркәүгә – пасторның мессасын (безнеңчә – вәгазен) тыңларга барасылары бар. Шуннан кайткач (ул кичке сигезләр була), табынга утыралар. Хәер, соңгы елларда чиркәүләргә халыкның бик аз йөрүе күзәтелә. Яшьләр ул гадәтләрне оныта башладылар, ә картларның хәле җитми.

25 декабрь – ял көне. Бу электән шулай килгән. Монда тагын бер нечкәлек турында искәртим: Раштуадан соң халык исерми, чөнки алар аз-азлап кызыл аракы гына эчәләр. (Гадәттә Россиядә 1 гыйнвар көнне бик күпләрнең башы авыртып уяна бит.) Югыйсә элек пасторлар Раштуага дип махсус сыра, кызыл аракы ясаганнар. Бу вирусларга каршы тору чарасы саналган.

25 декабрьдә бельгиялеләр шат күңел белән йокыдан уяна. Һәм Раштуа белән котларга туганнарына китәләр. Йорттан йортка йөреп чыгалар. Көне буена сузыла ул. (Сүз уңаеннан, Бельгия кечкенә ил, Татарстаннан өч тапкырга кечерәк. Ләкин анда өч тапкыр артыграк халык яши – 10 миллион чамасы.)

Раштуаның тагын бер символы – открыткалар. Кешеләр ул көнне бик күп открытка алалар, бүләк итәләр. Аны махсус 23, 24 декабрьдә килерлек итеп почтага салалар. Мисал өчен, унбишләре Раштуа белән котлап открытка алу, начар гадәт, хәтта мыскыллау санала.

Соңгы елларда яшьләр 31 декабрь көнне почта әрҗәсенә, Яңа ел белән дә котлап, открыткалар сала башлады. Ләкин аларга барыбер Раштуа белән котлыйм диелгән була, ягъни Бельгиядә Яңа ел открыткалары юк.

Без авылда яшибез. Безнең урамда кешеләр һәр йортның почта әрҗәсенә 23 декабрь көнне открыткалар салып китә. 24 декабрь иртән әрҗә открыткалар белән тулган була.

Гаилә белән Яңа елны бәйрәм итәбез. Дөрес, 31 декабрь көнне телевизордан Президент котлавы, концерт һәм башка чаралар булмый. Ләкин ун еллап инде интернеттан Владимир Путин, Рөстәм Миңнехановның котлавын тыңлыйбыз. (Казан белән ике сәгать аерма безнең.) Сәгать теле уникене суккач, шампан шәрабы ачабыз. Туган җиребездән еракта яшәсәк тә, Яңа елны Россиядәгечә каршы алабыз. Без генә түгел, башка татарлар, руслар да шулай эшли.

«МОНДА ХАЛЫК ТЫЙНАК!»

Айна Зеттерлунд, Швеция

– Беренчедән шуны әйтим: шведлар чынбарлыкта яши торган, тыныч холыклы халык. Аларның безнең сыман фантазия, романтика дип исләре китми. Хәер, кешесенә караптыр инде. Тик нигездә җирле халыкның күбесе шундый дип күрәм.

Швециядә ноябрь азагында ук бәйрәмгә әзерләнә башлыйлар. «Фешта-отвент» чарасы башлана. Ул ничекме? Кешеләр тәрәзә төпләренә күп итеп шәмнәр куя. Башта бер шәм кабызалар, икенче атнага – тагын берне, аннан өченчене, дүртенчене... Раштуа җиткәнче, шул рәвешле шәмнәрне кабызып бетерәләр. Ул шәм савытларының ниндие генә юк, бигрәк тә соңгы елларда берсеннән-берсе матурларны эшли башладылар. Швециядә Раштуа җиткәнче өйләрнең тәрәзә төпләре әнә шулай яктылыкка күмелеп утыра.

Декабрьнең унөчендә, бик зурлап, Изге Люсия көнен уздыралар. Люсия безнеңчә – Кар кызы. Мондый чара мәктәпләрдә, сәүдә үзәкләрендә, урамнарда уза. Мисал өчен, башта һәр мәктәп үзенең Люсиясен сайлый. Гадәттә ул ап-ак чәчле, озын буйлы чибәр туташ була. Башка кызлар да бәйрәмгә ап-ак кием кия. Кар кызы кебек үк, Люсиянең дә башында таҗы була, ул таҗга түгәрәкләп берничә шәм куела. Россиядә Кар кызы турында җырлар, шигырьләр бик күп түгел, чөнки Кыш бабай популяррак. Ә менә Швеция халкы Люсиягә багышлап бик күп җырлар, шигырьләр, төрле уеннар уйлап чыгарган. Әйткәнемчә биредә халык тыйнак. Шуңа күрә дә монда Россиядәге кебек кызу, дәртле биюләр юк. Изге Люсия көнен бәйрәм иткәндә дә салмак кына, түгәрәкләр буенча йөриләр.

Унөченче декабрьне уздырганнан соң, халык Раштуага, Яңа елга әзерләнә башлый. Швециядә бер матур гадәт бар – өлкәннәргә ихтирам күрсәтү. Шуңа да җирле, халык күчтәнәчләр алып, иң беренче картлар йортларына бара. Артистлар да өлкәннәрнең күңелен күрергә ашыга. Мул табын коралар, җырлашып утыралар.

Зур табыннарга шведлар үзләренең милли ризыкларын – «хьенкә» пешерә. Ул һәр өстәлдә булырга тиеш дип санала. «Хьенкә» – дуңгыз

боты. Аны төрле кеше төрлечә пешерә һәм бизи. Тик Раштуа табыны дуңгыз ботыннан башка узмый инде. Ит янына дөге боткасы куела. Тагын табынга бәрәңге ашы да чыга. Эчемлекләрдән глинтвейн – тәмләткечләр кушылган кайнар кызыл шәраб популяр. Глинтвейнны декабрь аенда сәүдә үзәкләрендә бушка тараталар. Махсус мичкәләрдә шәраб җылынып тора. Теләге булган кеше рәхәтләнеп барып эчә ала.

Швециядә дә бүләкләр бирүче әкияти герой бар, аның исеме – Томтен. Ул Санта Клаус та, Кыш бабай да түгел. Тышкы кыяфәте белән күбрәк Россиядәге Йорт иясенә охшаган. Раштуа бәйрәмендә Томтеннарның парадлары була. Махсус костюмнар кигән ир-атлар янына хатыннары да баса (алар Кар кызы ролендә). Иптәшем белән без дә парадка чыккаладык. Ул баянда уйнап, башка Томтеннар белән шәһәр урамнарын әйләндек. Гадәттә парадка оркестрлар да чакыралар. Аннан соң барлык Томтеннар зур сәүдә үзәгенә җыела. Алдан махсус программа төзиләр. (Аерым елларда мин дә булыштым.) Җыр-бию, күңел ачу башлана. Бер якта сәүдә нокталары да эшли – Яңа ел бүләкләре саталар. Соңыннан бик зур салют була.

Мөселманнар бәйрәме булмаса да, Раштуага безнең балалар да җыела. Бу көнне балалар ата-аналары янына килеп, бергә табын артында утыру гадәткә кергән бит. Шушы җирлектә яшәгәч, без дә традициядән читтә калмыйбыз. Яңа елга да җыелабыз. Тагын Россиядән китеп, биредә гомер итүче ватандашларыбыз да килә. Алдан күп итеп бүләкләр әзерлибез. Ә табынга бәлеш, өчпочмак пешерәм. Милли ризыкларыбызны ашап, Россиядәге кебек Яңа елны каршы алабыз.

«ИҢ ПОПУЛЯР ӘЙБЕР – ЛОТЕРЕЯ»

Айзирәк Гәрәева-Акчура, Төркия

– Төркиядә зурлап уздырыла һәм күп ял көннәре бирелә торган ике бәйрәм бар. Алар – Ураза һәм Корбан бәйрәмнәре. Ә Яңа елга монда андый игътибар юк. Чагыштыру өчен бер мисал: Ураза, Корбан бәйрәмнәренә 3-4 көн ял бирелә, ә Яңа елда бары бер көн ял итәләр.

1923 елда Төркия Республикасы төзелгәннән соң, яңа календарь – Миладе кабул ителгән. Шул чорда төрек теленә, халыкның киемнәренә, башка өлкәләргә шактый үзгәрешләр кертелә. Төркия акрынлап Европа тарафына йөз тота. 1936 елдан 1 гыйнвар рәсми рәвештә ял көне итеп игълан ителә. «Ел башы» бәйрәме барлыкка килә. Һәм гаилә эчендә үткән елны озату, яңа елны каршы алу чаралары үткәрелә башлый. Ә соңгы елларда «Ел башы» бәйрәменә игътибар кимегәнлеге сизелә, чөнки аны дини яктан хупламаучылар күбәйде. Шул сәбәпле бәйрәм итүдән баш тартучы гаиләләр дә бар. Шулай да Төркиядә Яңа ел рухы сизелә – кибетләрдә төрле уенчыклар сатыла, зур маркетлар бик матур итеп бизәлә. Әмма быел пандемия белән бәйле аерым чикләүләр кертеләчәк. Мисал өчен, 31 декабрьдә сәгать 21.00дән башлап, 4 гыйнварның 5.00 сәгатенә кадәр карантин игълан ителде. Җирле халыкка өй тирәсендәге кибетләргә генә барырга ярады, ә машина белән йөрергә рөхсәт ителми. Тик әлеге кагыйдә туристларга кагылмый.

Дөнья күләмендә Яңа елга багышланган рекламалар күп булса да, Төркиядә ул чагыштырмача күп түгел. Кыскасы, Россия белән чагыштырганда, Төркиядә Яңа ел рухы бик аз дияргә була.

Дини бәйрәмнәргә яңадан әйләнеп кайтсак, Рамазанны бәйрәм ае дияргә мөмкин. Һәр көн ифтар һәм сәхәр вакытларында махсус туры эфирлар, дини тапшырулар күрсәтелә. Истанбулның мәшһүр мәчетләре янында ифтар вакытында халык җыелып авыз ача. Анда танылган дин әһелләре, дини көйләр уйнаучы музыкантлар катнашында туры эфирда баручы тапшырулар төшерелә... Кафе-рестораннарда гаиләләре, дуслары белән очрашып авыз ачучылар күбәя. Җәйге вакытлар булса, халык сәхәргә кадәр урамда йөрергә мөмкин. Шәһәр паркларында пикниклардан кайтып кермиләр.

Ураза бәйрәменең беренче көнен төрекләр өйдә уздыра. Икенче, өченче көннәрдә өлкән туганнарына, якыннарына, дусларына йөриләр.

Төркия татар авылларында өйдән өйгә йөреп котлашу гадәте бар, ул бик матур уза. Кемгә барып керсәң дә, табын корылган, чәй кайнап тора. Өстәл тутырып кош теле, пәрәмәч кебек милли ризыклар әзерлиләр. Хәтерлим, Төркиягә күченеп килгән елларда төнге икеләргә кадәр шулай «бәйрәмләшеп» йөри идек. Көнгә унар гаиләне бәйрәм белән котлап барган көннәр булды.

Корбан бәйрәменең беренче көнендә бөтен кеше корбан чалу, корбан итен урнаштыру белән мәшгуль. Шуңа да котлашу, бер-береңә йөрү икенче, өченче көннәргә кала. Татарлар да төрекләр кебек үк бәйрәм итә: милли ризыкларыбыз белән бергә корбан итеннән кавырма ясыйлар. (Итне пешереп, бераз кыздыралар.) Төркиядә азык-төлек башка әйберләргә караганда кыйммәт. Корбан чалу да арзан түгел. Мисал өчен, җиде кеше җыелып, уртакка чалган олы мал өчен, ким дигәндә, бер кешедән 20 мең сум чыга. Ә бер сарык 15 мең сум тирәсе тора.

Минемчә, Төркиядә Яңа ел якынлашканда иң популяр әйбер – лотерея. Ул ел дәвамында уйнатыла. Әмма «Ел башы лотереясе» махсус ясала һәм анда гадәттәгедән күбрәк акча уйнатыла. Бу лотереяне кешеләр чиратлар торып алып бетерә... Бик әкәмәт күренеш. Баштагы мәлдә моңа аптырый идем, Төркия бит мөселман кануннары буенча яшәүче ил. Тик аннан аңлаттылар: җыелган акчаның күп өлеше дәүләткә кала һәм хәйрия ярдәме булып төрле фондларга, балалар, картлар йортларына бүленеп бирелә икән. Шуңа күрә дә дин әһелләре каршы килми.

ЯҢА ЕЛ ОТКРЫТКАЛАРЫ

Безнең илебездә Яңа елны каршылау тарихы борынгы гасырларга барып тоташа. Кайчандыр Россиядә Яңа елны 1 сентябрьдә каршылаганнар. Соңгы тапкыр бу 1699 елда булган (дөнья яралышыннан башлап 7208 елда), ә шул ук елның 20 декабрендә Петр I «вакыт исәбен дөнья яралышыннан түгел, Христос туган көннән алып бару турында» фәрман чыгарган. Шуңа ярашлы рәвештә 7208 елның 31 декабреннән соң 1700 елның 1 гыйнвары башланган.



PRESSA

XX гасырда, хакимияткә килүгә үк, большевиклар календарьга яңа реформа үткәрә. 1918 елның 24 гыйнварында Россиядә Көнбатыш Европа календарен кертү турында Декрет кабул ителә: «Россиядә дә, барлык мәдәниятле халыклардагы кебек үк, вакыт исәбен урнаштыру максатыннан, Халык Комиссарлары Советы быелгы гыйнвар аеннан соң гражданнар кулланышына яңа календарь кертергә боера. Моңа бәйле рәвештә: быелның 31 гыйнварыннан соңгы беренче көнне 1 февраль дип түгел, ә 14 февраль, аннан соңгы көнне 15 февраль, дип санарга»

Әмма әлеге яңалык кертелүгә карамастан, Советлар Союзында Яңа ел билгеләп үтелми, чыршылар куелмый, Кыш бабай бүләкләр бирми. 1935 елга хәтле болар барысы да юкка чыгарга тиешле буржуаз мирас булып санала.

Шулай да күпмедер вакыттан соң, ил җитәкчелеге өр-яңа пролетар мәдәният урнаштыру идеясеннән әкренләп китү зарурлыгына төшенә. Илебез тарихындагы кайбер традицияләр, исемнәр һәм вакыйгалар аз-азлап кире кайтарыла башлый. Яңа ел да шулар исәбенә эләгә.

1935 елның 28 декабрендә «Правда» газетасында танылган партия пропагандисты һәм публицисты Павел Постышевның «Әйдәгез Яңа елга балаларга яхшы чыршы бәйрәме оештырыйк» дип аталган мәкаләсе чыга: «Революциягә кадәр буржуазия һәм чиновниклар Яңа елны каршылаганда һәрвакыт чыршы бәйрәме уздырган.

Хаҗи Абдулла Дубина
Архив

PRESSA



Төрле утлар белән балкып торган чыршыга һәм аның тирәсендә күңел ачкан бай балаларына эшче балалары тәрәзә аша кызыгып карап торган. Ни өчен безнең мәктәпләр, балалар йортлары, яслеләр, балалар клублары, пионер сарайлары Совет иле балаларын әлеге искиткеч ләззәттән мәхрүм итә?»

Тиз арада Яңа ел дәүләт бәйрәме статусына ия була. Ә 1948 елның 1 гыйнварыннан яңа елның беренче көне ял көненә әйләнә. Православие Раштуасы исә кабат дәүләт дәрәҗәсендә илдә 1991 елның 7 гыйнварыннан билгеләп үтелә башлый.

Бүген Яңа ел, ихтимал, милләтенә һәм диненә карамастан, барлык россиялеләрнең дә иң яраткан бәйрәмнәреннән берседер. Һәм бүген без аның илебездә ничек уздырылуын искә төшерербез. Казанның күренекле коллекционеры Абдулла Дубин бөртекләп җыйган открыткалар исә безгә бу эштә ярдәм итәр.

С новым годом!
С Новым годом!
МИР
Новым годом

С Новым годом!
Скоро снова встретим
Добрый Новый год,
И большим и детям
Радость он несет.
Новые успехи,
Новые пятерки,
Много новых книжек,
И катки и горки.
Тысячи просторных
Солнечных квартир,
Звездные дороги,
Дружбу, счастье, мир!
БАМ
СССР
С НОВЫМ ГОДОМ!

БУ – КЫЗЫК

Россиядә Яңа ел бәйрәмнәренең баш герое – Кыш бабай, АКШта – Санта-Клаус, Швециядә – Юлтомтен, Монголиядә – Увлин Увгун, Франциядә – Пер Ноэль, Италиядә – Баббо Натале, Кипрда – изге Василий... Исемнәре төрле булса да, аларның тышкы кыяфәте шактый охшаш: озын чал сакал, тун, таяк һәм аркаларына аскан бүләк тулы капчык берләштерә үзләрен.

PRESSA

www.protatarstan.ru
Поиск...
РУС | ТАТ
Подписка!
ТАТАРСТАН
Иҗтимагый-сәяси басма
Где купить журнал "ТАТАРСТАН"
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Яңа ел табынына «Без» салаты
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
22 января 2021
21 января 2021
Иман академиясе
Кече Шырдан: киләчәккә өмет белән...
«Тел ул – мистик субстанция»
Реклама 16+

Мәңгелек кыйммәтләр/

Мәңгелек кыйммәтләр

Акыллы гамәлләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Яңарыш журналисты Фатыйх Кәрими нинди язмышка дучар була

Татар алфавиты нинди үзгәрешләр кичерә

Китап киштәсе нинди китаплар тәкъдим итә

Чыпчык авылы нинди тарихка ия

ЯҢАРЫШ ЖУРНАЛИСТЫ: ФАТЫЙХ КӘРИМИ

Автор: Илдус Заһидуллин

«Татарлар бу илләрдә төрле проходимецлар, поляклар, венгрлар һәм башка Россия дошманнары кулына эләгергә мөмкиннәр. Шуның өстенә, биредәге Европа илләренә охшатып һәм алар йогынтысында зур тизлек белән үсә баручы... Көнчыгыш Европа гыйлеме һәм цивилизациясе югары белем алырга омтылган татарларга күчәргә мөмкин. Ерак киләчәктә... Бохараның урта гасырдан килгән схоластик уку йорты – татар мәктәбенә, ә дини мәсьәләдә татарлар белән руслар арасындагы антипатия мәдәни һәм сәяси антипатиягә әверелергә мөмкин», – дип яза Казан миссионеры татарларны Төркиягә, Мисырга, Гарәбстанга укырга барудан тыярга тәкъдиме язылган хатында. Хат 1886 елның 16 октябрендә эчке эшләр министры граф Д.А. Толстойга адреслана.

Миссионерның тәкъдиме беркадәр вакыттан соң Халык мәгарифе министрлыгының 1892 елның 10 июлендәге циркуляры булып формалаша. Рәсми кәгазьдә ислам илләрендә белем алган мөселманнарга мәктәп-мәдрәсәләрдә педагогик һәм мөгаллимлек эшчәнлеге тыела дип күрсәтелә.

Н.И. Ильминскийның югарыда китергән фаразы өлешчә генә дөрес булып чыга. Чыннан да, Госманлы дәүләтендә белем эстәгән татар шәкертләре, илгә кайткач, милләт өчен хезмәт итеп, схоластик уку йортлары урынына заманча программалы милли мәктәп төзи. Алар башлаган яңарыш мөстәкыйль юнәлешле һәм үзенчәлекле була. Татар җәдитләре Россия хакимиятенә дә, русларга да каршы чыкмый, сәяси карашлары белән күпчелеге либераллар булып, милли-мәдәни автономия булдыру өчен тырыша. Миссионерның «ерак киләчәк» дигән фаразы да ялгыш булып, ул «якын киләчәк» булып чыга. Бу язмабыз фидакарь хезмәте белән шул «ерак киләчәк»не якынайткан шәхесләрнең берсе – Төркиядә белем туплап кайткан татар егете Фатыйх Кәрими турында. Быел аның туына 150 ел.

«...ЙОЛДЫЗ ТӨСЛЕ ЯКТЫ БИРЕП ТОРЫРЛЫК УГЫЛ»

Мөхәммәтфатыйх Кәрими 1870 елның 18 мартында Самара губернасы Бөгелмә өязе Миңлебай авылында мулла булып торучы Гыйльман хәзрәт гаиләсендә дөньяга килә. Хәзрәт Шиһабетдин Мәрҗани һәм ишан Закир Камаловта белем алган һәм чыгышы белән Пенза төбәгеннән була.

Иң гаҗәбе – Фатыйх бу гаиләдә Исмәгыйль Гаспралы йогынтысында дөньяга карашын калыплаштырган икенче буын вәкиле була. Чистай мәдрәсәсендә белем алган этисе, «Тәрҗеман» га-

Фотолар автордан алынды

зетасы фикерләре белән килешмичә, аның мөхәррире белән хат аша бәхәскә кереп, ахыр чиктә үзенекен раслап җиңәр өчен, Бакчасарайга бара һәм аннан... Гаспралы тарафдары булып кайта. Бөгелмә өязе ахуны дәрәҗәсеннән файдаланып, күрше авылларда белем һәм мәгърифәт тарату өчен, шәхси үрнәк белән дә, вәгазьләп тә, матди ярдәм күрсәтеп тә тырыша.

Улы Фатыйх Чистайда яшереп «Тәрҗеман» газетасын алдыра, русча өйрәнә. Мәдрәсә шәкертләрен укыту системасына һәм мөдәррисләре Закир ишан Камаловка каршы сүзләр сөйли. «Камалия»дән 11 ел укыган улын алып кайтып киткәндә Гыйльман ахун, углымда өмет бар икән, дип сөенә һәм аны беркадәр вакытка Уфага, 1891 елның 20 февраленнән Мәхкамәи шәргыядә казый булып эшли башлаган кайнеше Ризаэтдин Фәхретдин гаиләсе тәрбиясенә илтә. Егет, Мәхкамәи шәргыядә имтихан биреп, мөдәррислеккә лаек дигән шаһәдәтнамә ала.

Гыйльман ахун улын 1892 елда Төркиягә укырга җибәргәндә, кыен чакта алып укырсың дип, нәсихәт хаты бирә. Хатның һәр җөмләсе тирән мәгънәгә ия булып, баласы алдына олы максатлар куйган ил агасы фикередәй яңгырый:

«Углым! Мин сине кеше булырга, гыйлем алыр өчен ерак җирләргә җибәрәм. Киләчәктә милләткә файдалы булуыңны телим, сине җибәрүем байлыгым артыктан түгел. Синнән башка биш балам һәм карт атам бар. Шуларның өлешеннән аерып, сине озатам. Безне шатландырырлык, киләчәктә илгә йолдыз төсле якты биреп торырлык угыл булып кайтуыңны телибез».

Иң кызыгы – хатның соңгы берничә җөмләсендә:

«Төркиянең гали мәктәбен бетереп имтихан бирсәң, бәлки Яурупаның берәр мәмләкәтенә барып гыйлем алырга теләрсең, Германия яки Франциягә, үзең уйлап безгә язарсың. Минемчә, әгәр һөнәр-техник эшләр белән кызыксыңсаң, Германиягә, әгәр матур күренеш, әдәбият, көтепханәләр белән кызыксынсаң – Парижга барып. Күбрәк чит телләрне белеп кайтуың тиеш булыр дип уйлыйм. Сиңа вәгъдә биргәнемчә расходлык барыр».

Яшь егеткә Истанбулда чиновниклар әзерли торган «Мәктәбе мөлкия-шаһәнә» югары уку йортына керергә күренекле төрек мәгърифәтчесе Әхмәд Мидхәт ярдәм итә.

Фатыйх биш ел буе укуы өчен түләп барган этисенең өметен тулысынча аклый. Төрек, француз, рус, гарәп һәм фарсы телләрен белүче киңкырлы иҗат әһеле булып танылa, татар милләтенең күренекле нәшире, журналисты, төрле фәннәр буенча дәреслекләр төзүче, педагог, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе буларак ат казана.

Сәйдә һәм Фатыйх Кәримиләр. Оренбург, 1903 елның 18 феврале

ПЕДАГОГ ФАТЫЙХ

1896 елда Ватанына кайткач, Фатыйх Кырымда Исмәгыйль Гаспралы белән якыннан аралашып, башта – Ялтадан ерак булмаган Дәрәкөй авылы кызлар мәктәбендә, аннары, 1897–1898 нче уку елы тәмамланганчыга кадәр, Ялтада мөгаллим булып эшли. Шулай ук мөгаллимнәргә яңа ысул белән укытырга өйрәтү курсларында белем бирә.

Фатыйхның Кырымда башланган укытучылык хезмәте, берничә ай туган авылында укытканнан соң, Оренбургта яңа баскычка күтәрелә. Ул 1899 елның җәй айларыннан башлап, өч сезон дәвамында, 1901 елны полиция туздырганчы, Каргалыда бертуган сәүдәгәр Хөсәеновлар оештырган яңа метод белән укытучы мөгаллимнәр әзерләү курсларын җитәкли, дәресләр бирә. 1901–1902 нче елларда җәдит мәктәбе укытучыларына кулланма рәвешендә «Укытучы вә тәрбияче. Юл күрсәткеч» исемле ике кисәктән торган педагогик хезмәт бастыра. Мәктәпләрне сыйфатлы дәреслекләр белән тәэмин итү өчен, «Кыскача география», «Кыскача гомуми тарих», «Пәйгамбәрләр тарихы» китапларын яза, алар кабат-кабат бастырыла. Шулай ук дөньяви белем бирүче «Хөсәения» мәдрәсәсе хәлфәсе буларак укыта.

ЯЗУЧЫ ҺӘМ ТӘРҖЕМӘЧЕ

Фатыйх Кәриминең сәнгатьле сүз белән искелек яклыларны кискен тәнкыйтьләүгә корылган «Бер шәкерт белән студент» (1899), «Җиһангир мәхдүм» (1900), «Мирза кызы Фатыйма» (1901) исемле әдәби әсәрләре вакытлы матбугат булмаган шартларда җәдитчеләр белән кадимчеләр арасындагы идеологик көрәштә җиңүгә үз өлешен кертә.

Татар хатын-кызларының алгарышын күздә тотып, язучы 1898–1899 нчы елларда шушы катлаулы мәсьәлә буенча төрекчәдән тәрҗемәдә ике китапчык, соңрак французчадан «Төрек ханымнары» (1901) исемле брошюра бастыра.

XX йөз башында Фатыйх Кәриминең сәяхәтнамәләре дөнья күрә. Ул 1899 елның февраль-март айларында алтын приискалары хуҗасы Шакир Рәмиевнең юлдашы һәм тәрҗемәчесе сыйфатында Көнбатыш Европа илләренә эшлекле һәм ял сәяхәте кыла. Юлчы «Европа сәяхәтнамәсе»ндә (1902) күрше халыклар, мәмләкәтләрнең алдынгы тормыш рәвеше, аларның фикер сөреше турында күзәтүләре белән уртаклаша. Беренчеләрдән булып Россиядәге төрки телле укучыга Европаны эчке яктан «ачкан» бу китап берничә тапкыр кабат басыла. Кәриминең «Кырымга сәяхәт» (1904) әсәрендә 1903 елны Бакчасарайга «Тәрҗеман»ның 20 еллык юбилеена бару һәм анда катнашу вакыйгасы тасвирлана. Сәяхәтнамәләр автор аралашкан шәхесләрне, шәһәр җәмгыятьләренең дини һәм мәдәни тормышын төгәл сурәтләве белән бүген дә әһәмиятле.

ЭШМӘКӘРЛЕК-НӘШИРЛЕК ЭШЧӘНЛЕГЕ

Гыйльман ахун, өлкән улының һәм башка балаларының киләчәген уйлап, 30 ел муллалык хезмәтеннән соң «указын» тапшыргач, 1899 елның җәендә гаиләсе белән Оренбургка күченә. Фатыйхка киләчәк тормышында алган белемен файдалану өчен кулай булыр дип, татар типографиясе ачу хәстәренә керешә. Фатыйх Мәскәүдә нәшрият хезмәте белән танышып, бухгалтерлар һәм алман теле курсларында укып кайта.

Әтисе исеменә язылып, Гани байдан әҗәткә алган акча хисабына 1900 елның ноябрендә ачылган басмаханәнең җиһазы иске булса да, биредә 1902 елга кадәр 52,4 мең данәдә 27 исемдә татарча китап бастырыла. Шулай да, заказлар аз булу сәбәпле, басмаханә ныклап эшләп килә алмый.

1902 елның май ахырында, әтисе яшен сугудан үлгәч, энеләрен һәм сеңелләрен укыту һәм урнаштыру Фатыйх җилкәсенә төшә. Гыйльман картның олы улына кылган соңгы яхшылыгы – аңа өйләнергә кәләш сайлап кую була: 1903 елны Фатыйх Уралаева Сәйдә белән никах укыта, бәхетле гаиләдә ике ир-егет үсә.

Сулдан уңга: Гариф Кәрими, Мәрьям Якупова, Фатыйх Кәрими, Өммегөлсем Камалова, Йосыф Акчура, Рокыя Юнусова, Мәрьям Паташева. Истанбул, 1912 елның декабре

Әтисе үлгән елда Фатыйх, сәүдәгәр Гани Хөсәенев белән берләшеп, «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» басмаханәсен ача, заманча җиһазлар алдыра, зурайта. Тик 1903 елда, пайларын сатып, басмаханәдән чыга, иҗат белән шөгыльләнә башлый, көндезләрен репетитор булып миллионер Шакир Рәмиевнең өч баласына сабак бирә, кичләрен сеңлесе Закирәнә һәм хатыны Сәйдәнә укыта.

«ВАКЫТ» ГАЗЕТАСЫ МӨХӘРРИРЕ БУЛГАН ЖУРНАЛИСТ

Татар яңарышында Россиядәге демократик үзгәрешләр һәм татар интеллектуалларының милли капитал хуҗалары белән хезмәттәшлеге хәлиткеч роль уйный. Бу яктан караганда, Фатыйх Кәриминең Шакир Рәмиев, аның вафатыннан соң (1912 ел), энесе Закир Рәмиев белән уңышлы хезмәттәшлеге үрнәк булып тора.

Кәриминең беренче мәкаләләре 1904 елда Тифлистагы «Шәркы рус» газетасында дөнья күрә. 1905-1906 еллардагы демократик атмосфера шартларында матбугат ирегә киңәйгәч, татар җәмгыятенең мәдәни һәм сәяси үсешенә вакытлы матбугат нык тәэсир итә башлый, журналистлар иҗтимагый фикергә йогынты ясаучы шәхесләргә әверелеләр. 1906 елның 26 февраленнән 1913 елга кадәр атнага 2–4 тапкыр, аннан соң һәр көнне зур форматта, шәп кәгазьдә басылып килгән «Ва-

«Фатыйхта – тугры сүз, төпле фикер, хакыйкать, халыкка мәхәббәт, яшьләрне дөньяга туры карашлы итеп үстерү, киләчәккә өмет белән карау... Үзен күрсәтергә теләү, үзен югары тоту кеби ваклыклар Фатыйхта һич юк. Бөек адәмнәрдә генә була торган, чын әдипләрдә генә була торган сыйфатлар – Фатыйхта».

Дәрдемәнд, 1911 ел.

Утырганнар (сулдан уңга): Габдрахман Фәхретдинев, Фатыйх Кәрими, Ризаэтдин Фәхретдин, Закир Рәмиев, Борһан Шәрәф; басканнар: Рәкыйб Рәкыйби, Госман Нури Акчокраклы, Ярулла Вәли. Оренбург, 1909 ел.

кыт» төрле елларда 3–4 мең данә тираж белән киң даирәгә тарала

Мөхәррирнең, бер яктан, эзлекле эш-гамәлләре, искиткеч киң эрудициясе, кешеләр белән тигез мөгамәлә кору һәм редакциягә алдынгы фикерле һәм йөгерек каләмле авторларны, хезмәткәрләрне җәлеп итү осталыгы, икенче яктан, газетада көнүзәк сәяси, халыкара, дини, милли темаларны билгеләп, кызыклы материаллар аша редакциянең сәясәтен тормышка ашыра алуы «Вакыт»ны беренче дәрәҗә татар басмасына әверелдерә.

Татар, башкорт, үзбәк, казах һ.б. төрки халык вәкилләренең фикерен үстерерлек, гражданлык активына чакырып бәхәсләр уятырлык темалар тәкъдим иткән газета булдыру Кәриминең мөхәррир-оештыручы һәм журналист буларак татар милләте иҗтимагый үсешенә керткән иң зур хезмәте итеп бәяләнергә хаклы.

Кәрими «Вакыт»ның һәр санына баш мәкалә яза, башка күпсанлы язмалар белән катнаша. «Вакыт» аны күренекле сәясәтче, милләтпәрвәр җәмәгать эшлеклесе, энциклопедик белемле журналист, киң карашлы фикер иясе итеп таныта. Ул Шәрыкны өйрәнүче галимнәр В. Бартольд, В. Гордлевский, А. Вамбери белән аралаша, языша. «Иттифак әлмөслимин» фиркасе Үзәк комитеты әгъзасы булган мөхәррирнең газетасы да нигездә кадетлар партиясе сәяси платформасында тора. 1917 елның маенда ул, Россия мөселманнарының иң абруйлы уникe эшлеклесе исәбендә, Бөтенроссия съезды президиумына сайлана.

Кыскасы, Оренбургта шушы милли басмалар тирәсендә татар зыялылары төркеме оеша, алар башка төбәкләрдән редакцияләргә яки «Хөсәения» мәдрәсәсенә укытырга килгән зыялылар белән аралашып, язмаларын матбугатта урнаштырып хезмәттәшлек коралар. Бу исемлеккә төрле елларда Оренбургта яшәп алган Галиәсгар Камал, Муса Бигиев, Галимҗан Ибраһимов, Җамал Вәлиди, Шәриф Камал һ.б. керә.

Фатыйхның Балкан сугышы барганда, 1912 елның ноябреннән 4 ай дәвамында Төркиядән «Вакыт»ка юллаган 70 публицистик мәкаләсе авторны татар матбугатында күренекле журналист итеп таныта. Төрекләргә зур симпатия белән язылган «Төркиядән мәктүпләр (хатлар)» исеме мәкаләләр сериясендә автор империясенең череп таркалуын, агониясен тасвирлый, дәүләтнең артталыгын һәм җиңелү сәбәпләрен белем һәм мәгърифәт булмауда, хатын-кызларның хокуксызлыгында (милләтне алга җибәрүчеләр хөр аналардан гына туалар; бер кызлар гимназиясе юк) һәм башка социаль сәбәпләрдә күрә.

Мөхәррир совет властен шатланып каршылый, 1917 елны «Яңа вакыт» газетасын бастыра башлый, шулай ук «Хөсәения» мәдрәсәсен совет татар уку йорты итеп үзгәртү өчен зур тырышлык куя, күп укыта. 1925 елны гаиләсе белән Мәскәүгә күчә, СССР халыкларының Үзәк нәшриятында татар бүлегендә эшли, Көнчыгышны өйрәнү институтында төрек телен укыта.

1930 елны «Эшче» газетасына язган бер мәкаләсендә Фатыйх Кәрими узган тормышын шушы рәвешле бәяли: «Октябрь революциясеннән элек мин милләтче идем: патша хөкүмәтләренең, башка милләтләр шикелле, татар-башкорт халкын кысу һәм изүенә мин милләтчелек, динчелек платформасында каршы торып көрәшә идем...»

Совет хакимияте, башка татар зыялылары белән беррәттән, Фатыйх Кәриминең дә башына җитә. Ул 1937 елда, Төркия файдасына шпионлыкта нахакка гаепләнеп, кулга алына һәм атып үтерелә.



ТАТАР МУЗЫКАСЫНДА САРА САДЫЙКОВА ДӘВЕРЕ

Автор: Мөршидә Кыямова

Татарлар үзенең талантлы кыз һәм улларын данлый, зурлый беләме? Алар белән горурланамы? Бу сорау мине соңгы арада бигрәк тә борчый. Милләт, тел язмышы кыл өстендә торганда шәхесләребез ничектер күләгәдә кала, тарих тузанына күмелә бара кебек. Ә инде эш күрсәткән хатын-кызларга килгәндә, алар бигрәк тә бәһасез кала шикелле тоела.

Фото Әлфия Айдарская архивыннан алынды

БЕЛЕШМӘ

Сара Садыйкова 1906 елның 1 ноябрендә Казан шәһәрендә туа. Шул заманның данлыклы кызлар гимназиясе – Фатиха Аитова мәктәбендә белем ала. Аны тәмамлагач, ул Казан педагогика техникумында укый. Техникумда җыр дәресләре алып барган остазы – татар халкының беренче композиторы Солтан Габәши Сараны хорда җырларга чакыра. 1921 елда Сара Садыйкова, «Бүз егет» драмасында беренче тапкыр сәхнәгә чыгып, җырлап уйнала торган Сәхипҗамал ролен башкара. 1922 елда Сара Садыйкова П.И. Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясендә укый. Сара Садыйкова – Татарстанда беренче хатын-кыз композитор. Салих Сәйдәшев аның үзенә көйләр язып карарга киңәш бирә. Ул 1942 елда Әхмәт Ерикәй сүзләренә «Көтәм сине» тангосын язуы белән композитор буларак эшен башлап җибәрә. Үзенең иҗат гомерендә ул 400 гә якын җыр, 30дан артык спектакльгә музыка, инструменталь әсәрләр яза, ике музыкаль комедия иҗат итә. Аның әсәрләре халык арасында киң популярлык казана һәм татар музыкасының алтын фондына керә. Сара Садыйкова 1986 елның 7 июнендә вафат була.

Сәхифәбезнең бүгенге каһарманы – тәүге татар операсы «Сания»дә Сания партиясен башкарган шәхес, профессиональ җыр сәнгатенә нигез салучыларның берсе, милләтебезгә тәүге тангоны бүләк иткән, татарның беренче хатын-кыз композиторы Сара Садыйкова. Ул – феноменаль шәхес. Колоратур сопрано тавышлы опера солисты булуыннан тыш, бик шәп драма артисты һәм халык күңелен яулап алган музыкаль әсәрләр авторы да. Аның җырлары профессиональ сәхнәләрдә дә, затлы бәйгеләрдә дә, табында утыручы гади кешеләр тарафыннан да хәзергәчә бик яратып башкарыла...

«Халкын яраткан Сара Садыйкова үзенең үлемсез җырлары белән Салих Сәйдәшевтан соң музыкада үзе бер дәвер тотты».

Ренат Еникеев, композитор

ТУГАЧ, ӘТИСЕ КҮЛМӘГЕНӘ ТӨРГӘННӘР

Сара Садыйкованың тормышы, иҗат юлы һәм язмышы гыйбрәтле. Дөньяга аваз салуына кадәр үзенә бертөрле була. Ул әти-әнисе кунакка баргач туган һәм аны әтисенең күлмәгенә төргәннәр.

Ул Казан кызы, әти-әнисе – сәнгать вәкилләре булмаса да, сәнгатькә мөкиббән, яңалыкны алга сөргән, балаларын укымышлы итәр өчен барысын да эшләргә әзер торган Гариф белән Бибигайшә. Биш яшендә үк Сара гармун уйнап, җырлый, килгән кунакларның күңелен ача торган була. Истәлекләрдән күренгәнчә, аның беренче сәхнәсе өстәл асты булган икән. Бәләкәй Сара кунаклардан оялып шулай өстәл астыннан гына «концерт куйган». Күңеленә халык моңнарын сеңдереп үсүче бала Казанның шул заман өчен алдынгы мәктәбе – Фатиха Аитова җитәкләгән кызлар мәктәбендә укый, монда нәни Сара олы тормышта хатын-кызга кирәк булган барлык гыйлемнәрне дә туплый. Биредә булачак композитор «матурлык», «нәфислек» төшенчәләренең чын асылын күреп үсә. Килеш-килбәттән башлап, милләткә хас иң садә сыйфатларны үзендә тәрбияли, бай рухи тәрбия ала. Энҗеле

Сара Садыйкова Галиябану ролендә. 1940 ел.

калфак киеп йөрү культурасын гомере буе саклый. Вакытлар узгач, халык аңа тикмәгә генә «Калфаклы сандугач» дип исем бирмәгән шул инде.

«Үзенең җырлавы, пианинода уйнавы белән теләсә нинди аудиторияне тотып тора ала иде».

Гариф Ахунов, язучы

Илдә советлар хөкүмәте урнашкач, кызлар мәктәбендә дә укыту системасы үзгәрә, әмма Сараның сәнгатькә карата мәхббәте көчәя генә. Әнисе белән театрларга йөри, сәхнәдәге артистларның уйнавына соклана, укытучы булырга хыялланган кызның күңеле сәхнәгә тартыла башлый. Татарның беренче композиторы Солтан Габәши педагогия техникумында укыган кызны Татар дәүләт театрына җырларга чакыра. Биредә инде сәләтле кыз театр әһелләре белән якыннанрак таныша башлый. Аның спектакльләрдә уйнавын, җырлавын күреп сокланучылар ешая. «...Хан кызы Сәхипҗамал ролен уйнаучы Сара туташ Донская теләсә, үзенең тавышы белән, теләсә, хәрәкәтләре белән һәммә халыкта тирән өмид уятты...» Галимҗан Ибраһимов та, кызның талантын тоемлап, аның турындагы мәкаләсендә шушы җылы сүзләрен әйтә.

ОЛЫ ХЫЯЛЛАРНЫҢ ЧЫНГА АШУЫ

Музыкаль урта белеме булмаган Садыйкованы Мәскәүгә укырга җибәрергә карар кылалар. Чит-ят җирдә дә татар кызы сынатмый. 1922-1928 елларда ул Чайковский исемендәге Мәскәү консерваториясе каршындагы музыка технимумының «Ялгыз башкару хокукы белән хор белгечлеге» бүлегендә укый. Мәхәббәтен дә ул Мәскәүдә очрата. Газиз Айдарский – татарның беренче профессиональ режиссеры, профессиональ театрга нигез салучы. Гастроль, иҗади тормыш, мәхәббәт илдәге авыр шартларга бирешмәслек көч өстәгәндер.

Сара Садыйкова тормыш иптәше Газиз Айдарский белән. 1924 ел.

Сара Садыйкова кызы Әлфия Айдарская белән. 1936 ел.

Егет белән кыз арасында хатлар йөри. *«Хөрмәтле вә гыйззәтле Сара туташ! Минем Сезне уйламаган бер генә минутым да юк. Сезне көн саен күреп яшәсәм дә, өзелеп сагынам... Мин дөньяда Сезнең белән очрашкан көннән бирле чиксез бәхетле... Сара туташ! Без бергә булырга, гомергә бергә булырга, бергә, бер тормыш корып яшәргә тиешбез. Сезнең ризалыгыгызны көтәм...»*

Ил өчен шактый катлаулы, зур үзгәрешләр чорында – 1924 елда алар гаилә корып җибәрә. Гаилә тормышы, Мәскәүнең атаклы педагогларыннан белем алу яшь иҗатчыны канатландырып кына тора. Константин Станиславский сабаклары яшь артист иҗатында тирән эз калдырган. Газиз Айдарский оештырган «Эшче» театрының примасы дәрәҗәсенә ирешә Сара. Музыкаль әсәрләрдән «Зәңгәр шәл»дә – Мәйсәрә, «Кандыр буе»нда – Фәридә, «Галиябану»да – Галиябану, «Аршин мал алан»да – Асия һ.б. рольләрне уйный. Әмма тормышында зур югалтуларга да юлыга, сөйгәне белән аерым яшәү (берсе – Казанда, берсе – Мәскәүдә), иренең вакытсыз үлеме, билгесезлек, юклык, ялгызы бала үстерү... Белемгә омтылган ханым 1934 елда Мәскәү консерваториясенең Татар опера студиясендә укый башлый. Аны 1938 елда бишлегә генә тәмалый һәм опера сәхнәсендә беренче пландагы рольләрне башкару хокукы биргән таныклыкка ия була.

«Әти бакыйлыкка күчкәндә, мин кечкенә идем әле, – ди Әлфия Айдарская. - Әтиле чагымда Мәскәүдә булган елларымны да хәтерлим. 10 яшемә кадәр Бишбалтада дәү әниләрдә яшәдем. Ә аннан үземә һөнәр үзләштерә башладым. Әнкәй минем янга Ленинградка килеп-китеп йөрде, биегәннәремне күзәтә, уңышларыма сөенә иде. 300 баладан нибары 12 баланы гына сайлап алдылар. Бөек Ватан сугышына кадәр шунда укыдым. Аннан соң Уфага киттем. Ә аннан әнкәй мине Казанга алып кайтты. 1941 елның көзеннән Казанда эшли башладым. Әнкәй бик түзем, гадел, шул ук вакытта искиткеч

таләпчән кеше иде. Мин Ленинградта укыганда, дәү әни үлгәнен дә миңа хәбәр итмәде. Укуыма зыян килер дип уйлагандыр инде. 1940 елда дәү әти вафат була, бу кайгылы хәбәрне дә миннән яшерделәр. Казанга кайткач, әни мине кырыс тәрбияләде. Хатын-кыз эшләренең барысына да өйрәтте. Үзегез беләсез, Ленинградта без тулай торакларда яшәгәндә, йорт эшләрен бик белми идек. Киреләнсәм: «Бу кадәр дә Айдарский булырсың икән!..» - дип әйтә торган иде. Ә инде аңа ошый торган гамәл башкарып куйсам: «Вот, моя школа!» – дип сөенә торган иде».

Әлфия Айдарская, олы яшьтә булуына да карамастан, бүгенге көнгә кадәр әнисе мирасын бөртекләп җыеп китаплар бастыра. Моңарчы яңгырамаган әсәрләрен, Сара Садыйкова язган шигырьләргә кадәр эзләп таба, радио, телевидение фондында сакланып калган язмаларын барлый, ел саен туган көненә багышлап Казанда, Мәскәүдә, үз көче белән яшь башкаручыларны туплап, композитор әсәрләреннән торган җыр кичәләре оештыра.

Композитор буларак танылганчы, Сара Садыйкова опера һәм драма артисты буларак зур уңыш казанганын әйтеп уздык. Аның Көнбатыш Европа һәм рус классикасында тәрбияләнүе «татар халкы кызы» булып калуына һич комачауламаган. Милли фольклорны яхшы белүе, татар халык җырларын дөрес итеп һәм тирән моң белән башкаруы үзе язган милли көйләрнең дә дәрәҗә-абруен бик югары күтәргән.

Сара Садыйкова Сания ролендә. 1925-1926 нче еллар.

Сара Садыйкова, Мәскәү. 1938 ел.

«ХАЛЫКНЫҢ ҖАНЫН АҢЛЫЙМ, ДИСӘҢ...»

«Мин халыкчанлыкны Сәйдәшчә аңларга тырышам. Тик халыкчан дигәннән, халык та мәңгегә бертөрле генә булып калмый бит, ул да үзгәрә. Әйтик, «Кара урман» җыры чыккан заманнарда халыкның тормышы да башкачарак, җырлары да сагышлырак булган. Ә хәзерге заман яшьләре сузынкы көйне түгел, ритмны, җитез хәрәкәтне ошатарак төшә, чөнки тормышның ритмы шундый. Димәк, шундый көй язарга туры килә: үзе халыкчан да булсын, әмма анда хәзерге заман сулышы да сизелеп торсын!» Композитор Сара Садыйкова әнә шулай һәр әсәрен йөрәге аша уздырып иҗат итә.

Нинди генә жанрда язса да, әсәрләрендә үз халкының рухын саклап кала алган, җырларын төрле бормалар белән бизәгән. Алар, әйтерсең лә, ноталарның биш юлына гына сыеп бетә алмый. Аларны киңлеккә юллап, мәхәббәт белән сугарып, халык күңеленә җиткерә композитор. Җырлары үз заманын актив сурәтли. Шуның белән бергә алар гаҗәеп тирән мәгънәле дә. Бөек Ватан сугышы чорында «Көтәм сине», Г. Камал исемендәге театрның 50 еллыгына «Театрыма» дигән җырлары туган. Галәмгә беренче тапкыр кеше очкач, «Юрий Гагарин» да аның иҗатыннан читтә калмаган.

Юмарт, киң күңелле кеше буларак, истәлекле вакыйгаларга, шәхесләргә, республика авыл-

Сара Садыйкова җырчы Гөлсем Сөләйманова белән.

фикерне кыйбла итеп алмый. Милли тамырларга хилафлык килмәслек итеп яза һәм аларны югарырак дәрәҗәдә күрсәтүгә ирешә. Солтан Габәши, Салих Сәйдәшевлар кебек үк музыка сәнгатенең төрле юнәлешенә үз өлешен кертә. Гомеренең соңгы мизгелләрендә Сара Садыйкова опера язарга хыялланганын белдерә. Бу хактагы фикерен Туфан Миңнуллинга да җиткерә. Драматургның тарихи темага либретто язуын үтенә. Әмма бу соңгы хыялы тормышка ашмый кала... Күләмле зур музыкаль сәхнә әсәре Сара Садыйкованың үзенә багышлап иҗат ителергә тиеш, ул моңа бик лаек. Ә бит заманында Салих Сәйдәшев Сара Садыйковага атап җырлар язган...

Яшь буын үзенең данлыклы милләттәшләре белән горурланып үсәргә тиеш. Композиторның музыкаль мирасы фәнни яктан да җентекләп өйрәнүне көтә. Байтак еллардан бирле һәйкәл мәсьәләсе дә чишелмәгән табышмак. 2021 ел – композиторның юбилей елы. Сара Садыйкованың 115 еллыгында эчтәлекле, нәтиҗәле чаралар оештырылыр, дип ышаныйк.

шәһәрләренә багышлап язган җырларын аерым җырчыларга, музыкантларга рәхәтләнеп тараткан. Шуңа да җырларының күбесе шәхси кулларда истәлек булып калган.

– Әнкәйнең җыр иҗаты татар эстрада сәнгатенең бер чыганагы булды һәм аның үсешендә зур роль уйнады, яшьләр иҗатына яңа этәргеч бирде. Бу композитор татар музыкасының җыр тарихында иң беренче булып танго, фокстрот, блюз стилен файдаланды, – ди кызы Әлфия Айдарская.

Театрдан хаксызга куылгач, Садыйковага М. Горький исемендәге клубта хор җитәкләргә туры килә. Опера сәхнәләреннән төшерелгәч тә, умыртка баганасын нык тота. Шушы хорда да күпме талантларга ачылырга мөмкинлек бирә. Алар арасында җырчы Флюра Сөләйманова да бар.

«Сара Садыйкова – Солтан Габәши, Салих Сәйдәшев васыятьләренә тугрылык саклап, татар музыкасына күпкырлы сәләтен багышлаган кеше. Бернинди рәсми таянычы булмый торып, ул туктаусыз берсеннән-берсе гүзәл әсәрләрен иҗат итте».

Мәхмүт Нигъмәтҗанов, музыка белгече

ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗНЕ ӘРӘМ ИТМИК, ӘЛӘМ ИТИК!

Без үзебезнең данлыклы талант ияләре белән горурлана белергә өйрәнергә тиеш. Татар музыкасының җыр сәнгатен борынгы халык көйләре белән тоташтырган, алар арасында күпер салуга ирешкән Сара Садыйкова да Мәскәүдә төрле педагоглардан белем ала, әмма хәзерге читтә укып кайткан яшьләр кебек, «сәхнәдә ни кылансаң да ярый» дигән



Сара Садыйкова шагыйрь Хәсән Туфан белән.

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ...

Зөһрә Сәхәбиева, Татарстанның халык артисты:
– Халык көйләре һәм композитор Сара апа Садыйкова җырлары белән дөньяга чыккан җырчы дип саныйм үземне. Сара апаның җырлары минем репертуарымда зур урын алып торалар, махсус үзем өчен дә берничә җыр язды ул. Ә инде аның «Җидегән чишмә»сен беренче булып башкаруым – иҗатымда бик әһәмиятле вакыйга, зур эшем булды. Сара апа белән бик күп гастрольләрдә бергә йөрдек. Ул безгә – яшь артистларга – бик игътибарлы булды. Бер генә нәрсәгә дә битараф калмас иде: ничек җырлыйбыз, нинди әсәр башкарабыз, сәхнәдә үзебезне ничек тотабыз, ничек киенәбез, чәчләребезне ничек йөртәбез – барысына да игътибары җитте. Бервакыт причёскама бәйләнде: «Нигә син маңгаеңны ачык йөртәсең? Тәкә маңгай шикелле... Маңгай чәчеңне кис!.. Маңгаеңа төшереп йөре! Маңгаең артык биек, чәчең белән капларга кирәк!» – ди. Мин каршы киләм, аңа да карамастан, Сара апа сиздермичә генә килде дә кайчы белән бер тотам маңгай чәчемне шарт итеп кисте дә алды.. «Менә ничек чибәрләндең!» – дип көлә үзе... Сара апа белән Гомәр абыйның «Җидегән чишмә»се инде менә 50 елдан артыкка сузылган иҗат юлымда аерылгысыз юлдашым, илһам чыганагым.

Рафыйк Юныс, язучы, журналист:
– 1978 елдагы әңгәмәбез вакытында Сара апа Садыйкова үзе әйткән сүзләр: «Мин тумас борын ук, әнкәйләр белән кунакка барам. Кунаклар ашап-эчеп, шаулашып-гөрләшеп утырганда: «Мин монда!» – дип разбой салам. Халык аптыраушта, бала төрергә әйбер тапмыйлар. Әткәйнең кулмәген салдырып, көлә-көлә: «Әйдә, атасының сөекле кызы булсын!» – дип, шуңа төриләр...» Кемне төргәннәрен белсәләр икән алар!

Кунакта күңел ачу мәҗлесендә дөньяга аваз салган шанлы композитор Сара Садыйкова үзенең бер көен текстсыз гына язган, җырның хәтта исемен дә куйган әле. «Әй, язмыш, язмыш» дип атаган ул аны һәм текст тудырыр өчен көйне Сибгат Хәкимгә биргән. Олуг шагыйребез дә текстны язмышка тәбәп язган. Аларның үз язмышларына тәбәлмәдеме икән бу әсәр?

1986 елда алар Чехов базары янындагы хастаханәдә икесе дә берьюлы чирләп ятканнар. Мин Сара апаның хәлен белергә барган идем, ләкин ул Сибгат абый турында әйтмәде, чөнки анда иканлеген белмәгән икән. Сибгат абый да Сара апаның хастаханәгә кергәнен белмәгән. Бер-бер артлы дөнья куеп, икесен дә Яңа бистә зиратына җирләделәр. Капкадан керүгә үк, уң якта 34 ел янәшә ята алар.

Җырлар иҗат итүгә Сара Садыйкова Татар дәүләт опера һәм балет театрының җитәкчелеге тарафыннан хаксыз рәвештә театрдан куылганнан соң, озакка сузылган газаплы еллар аша килә.

Айдар Фәйзрахманов, Татарстанның халык артисты:
– Сара апа Садыйкова белән беренче танышуым 1981 елда Ташкент каласында М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры артистларының гастроле вакытында булды. Мин әле студент, читтән генә күзәтәм. Сара апаны тамашачы күтәп ала, алкышларга күмә – ул бик тыйнак, мөлаем, үзенә генә хас милли киемнән. Яшьләргә бик ихтирамлы, җылы карашлы, өмет баглап, алга сөрүче артист.

1986 ел, Мәскәү каласы, Союзлар йортының Колонналы залы. Муса Җәлилнең 80 яшьлек юбилей кичәсе. Мин, үзем баянда уйнап, Сара Садыйкованың Илдар Юзеев сүзләренә язылган «Чит илләргә чыксаң» җырын башкарам. Җырны бик яраттылар, алкышларга күмделәр. Илдар абый Юзеев, кайту белән, бу алкышларны Сара апага җиткерә, әлбәттә. Казанга кайткач, Сара апа, мине эзләп табып, үзенең Татарстан урамында урнашкан фатирына чакырып, рәхмәтләр белдерә. Үзе уйнап, җырлап, җырларын тәкъдим итә...

Бүгенге көндә дә Сара Садыйкованың бу җыры үзенең моңы, көй агышы, аһәңе белән җыр сәнгатенең өлгесе булып тора. Мәшһүр Илдар Юзеевның: «Чит илләргә чыгып гыйбрәт ал», – дигән сүзләре дә бик актуаль. Шөкер, бүген дә Сара Садыйкованың иҗаты милли җыр сәнгатенә кыйбла булып кала бирә.

Рөстәм Гыйльфанов, Татарстанның атказанган артисты:
– Моннан 5–6 ел элек миңа Сара Садыйкованың кызы Әлфия Айдарская мөрәҗәгать итте. Сара Садыйкованың әсәрләреннән торган концерт әзерлиләр икән. «Тенор кирәк, җырларсың микән?» – ди. Мин, әлбәттә, бик сөенеп ризалаштым, концертта 6 җыр башкарырга булдым. Гадәттә мондый моң кичәләре композиторның халыкка таныш булмаган, моңарчы бик яңгырамаган әсәрләреннән тора. Шулай итеп, беренче концерт уңышлы гына үтте. Ул гадәттә Казанның Марсель Сәлимҗанов исемендәге Актёрлар йортында уза. Менә шуннан башлап, мин бу концертлар циклында даими катнашып килəм. Бүгенге көнгә Сара Садыйкованың төрле елларда иҗат ителгән 25ләп җырын җырладым, һәр концерт аерым темага багышлана, яисә берәр бәйрәм яки вакыйга уңаеннан үткәрелә. Әйтик, сугыш тематикасын колачлаган, Татарстанның шәһәр, авылларына аталган концерт-кичәләр оештырылды. Соңгы концертыбыз ТАССРның 100 еллыгына багышланды. Әлеге җыр кичәләре бик зур әһәмияткә ия, беренчедән халыкка моңарчы яңгырамаган җырлар ирештерелә, икенчедән, без, артистларның да, репертуары байый, алар бит мәңгелеккә күңелдә уелып кала. Сара Садыйкованың җырларын башкару бик җиңел дип әйтмәс идем. Алар шактый киң диапозонлы. Ләкин алар шулкадәр күңелгә ятышлы һәм киң сулышлы, милли, моңлы җырлар.


ئاچق هەم قاراکمی حەرفلەر بلەن باسلمان یازولار.

ئیتالییە بلەن گیرمانییە ئاراسندا ئشلەرن ئاربیتراژ یولی
بلن کیلشب یاساو تورندا بولعان دوگوۋرعا بوگن ریمدە قول قو-
یلدی. یاسالعان دوگوۋرعا قاراعاندا گیرمانییە بلەن ئیتالییە ئا-
راسندا دوستلق بلەن کیلشب عادەتدەگی دیپلوماتییە یولی بلەن گی-

- ە - ە - ە - ە - ە -

قازاق تلندە بر نیچە یول یازو

امیریکە قوراما ئشتاتلرنڭ ئبر بولەک تەڭز اسکەری نانکنکە
بارب ئتوسبتی. کانتون اسکەرنڭ الدی نانکننک توبندە ئان-
دن اسکەری بوگون - ەرتەگ نانکندی دە بەرب شمار دەسەدی.

ЕГЕРМЕНЧЕ ЕЛЛАР: ХӘРЕФ РЕФОРМАСЫ

Автор: Нурия Мифтахетдинова

Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы оешуның беренче елларында ук матбугатта язу чуарлыгын бетерү, сәнгати стильләр белән баету, укылышын уңайлы итү максатыннан гарәп шрифтларын камилләштерү эшчәнлегенә киң җәелеп китә. Бүгенге көндә 1921–1928 нче еллар аралыгында барган үзгәрешләр «Матбагат хәрефләре реформасы» буларак билгеле. Бу юнәлеш – танылган галимнәр, мөгаллимнәр, полиграфистлар һәм дөньякүләм танылган тюркологлар белән берлектә Республика җитәкчелеге ил күләмендә алып барган җитди эшчәнлек нәтиҗәсе.

«ТЕЛ ЯРЫШЫ»

1921 елда Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты яңа хәрефләр хәзерләү буенча ярыш игълан итә. Ярышта Һади Максуди, Иван Харитонов, Мөхәммәд Идрисов, Әхмәтҗан Мостафин һ.б. катнаша. Җиңүче итеп Мөхәммәд Идрисов проекты билгеләнә һәм ул ясаган үрнәкләр буенча 7 комплект матрица эшләнә, хәреф коела. Музейда аның әлеге өлкәдәге эшчәнлеген чагылдырган документлар бар: остаханә ачу турындагы кенәгә, Мөхәммәд Идрисовның эшчәнлеген уңай бәяләгән аттестат (бәяләмә).

Әмма бу күркәм башлангыч авыр икътисадый шартларда беркадәр тукталып кала. 1926 елда камилләштерелгән гарәп шрифтын типографияләрдә куллануны гамәлгә кую, гомумән, гарәп язуын саклап калу зарурлыгы туа.

Бакуда 1926 елның 26 февраленнән 5 мартына кадәр үткәрелгән Беренче бөтенсоюз тюркологлар съездында төрки халыкларның латинга күчү мәсьәләсе карала. Съездда катнашкан Татар-

фотолар ТР Милли музее фондларыннан

стан вәкилләре арасында гарәп язуын гамәлдә калдырырга тырышучылар да, латинга күчәргә теләк белдерүчеләр дә була.

Съезддан соң республикада гарәп һәм латин төркемнәренең эшчәнлеге активлаша. Шул ук елның 8 апрелендә «Яңа татар әлифбасы җәмгыяте» оеша, «Яналиф» нәшриятында латин шрифтында китаплар басыла, 1927 елның февралендә «Яналиф» журналы чыга башлый, шул ук елның маенда латин хәрефләре белән «Әлифба» китабы дөнья күрә, димәк, яңа язу уку-укыту процессына да үтеп керә.

Гарәп язуын саклап калучылар нәшриятта, укыту барышында матбагаттагы җитешсезлекләрне камилләштерү юлларын эзли. Шул юнәлешнең берсе – 1926–1928 нче елларда кабат хәрефләр реформасын гамәлгә кертү. Советлар Союзының төрле почмакларыннан килгән вәкилләр катнашлыгында 1926 елның 20 октябрендә узган хәреф конференциясе төрек-татар матбагат хәрефләренең реформа юлларын билгеләде. Биредә хәреф проектлары да карала. «Мәгариф» журналында, «Кызыл Татарстан» һ.б. эйдәп баручы республика вакытлы матбугатында яктыртылып, әлеге эшчәнлек киң җәмәгатьчелеккә дә җиткерелә.

Мөхәммәд Идрисов (беренче рәттә, уңнан беренче).

«ХӘРЕФЧЕ» ИПТӘШЛӘР

«Кызыл Татарстан» газетасының 1926 елның 16 сентябре санында анонс рәвешендә басылган мәкаләдә катнашучылар исемлеге күрсәтелә. «Киңәшмәгә хәреф төзәтү эшләре белән шөгыльләнгән түбәндәге иптәшләр тавыш бирү хакы белән катнашачак: 1. Кырымнан – Госман Акчураклы; 2. Казахстаннан – Әхмәд Байтурсин огълы; 3. Мәскәүдән – Мөхәммәд Идрисов; 4. Габдрахман Бурнашев; 5. Уфадан – Шаехзада Тукаев; 6. Бөредән – хәрефче Гата Исхаки; 7. Казаннан – Галиәскәр Камал; 8. Машиначы Шәйхгали; 9. Матбагачы Л. Вахидов; 10. Хәреф кисүче Ибраһим Зәйнуллин; 11. Хәрефчеләрдән Г. Алпаров, Г. Шәрәф, 13. Хәсән Гали; 14. Г. Нугайбәк; 15. Һади Максуди; 16. Г. Измайлов.

Болардан башка хәреф төзәтү эшләренә әһәмият бирүче иптәшләрнең киңәшмәгә катнашулары иректә булачак. Аерым төрек җөмһүриятләренең мәгариф комиссариатларыннан да берәр вәкил чакырылачак».

(Кызыл Татарстан. 1926 ел, 16 сентябрь.)



Р. С. Ф. С. Р.
Татарская С. С. Республика
ТАТСОВНАРХОЗ
Центральный Производственный
Отдел
Кустсекция
14 февраля 1923
№ 802

УДОСТОВЕРЕНИЕ

Настоящее удостоверение выдано ИДРИСОВУ, Мухамету Ибрагимовичу, в том, что его мастерская по применению восточных шрифтов к пишущим машинам и словолитне, на Фуксовской ул. в доме 5, зарегистрирована в Кустсекции Ц.П.У. Татсовнархоза 14-го Февраля 1923 г., за №223, на основании декрета от 7-го Июля 1921 г., как мелкопромышленное предприятие, пользующееся наемным трудом.

Гербовый сбор в размере 20 руб. и канцелярский – 1 руб. уплачены.

Зам. Начальника Ц.П.У.
Инженер/Бедер
Завед. Кустсекцией / Пудовик

Хәреф комиссиясе төзелә. Проектларга беренчел күзәтү ясала, төзәтмәләр кертелә. Әлеге юнәлештәге эшчәнлек нәтиҗәләре «Мәгариф» журналында бастырыла:

1. Киңәшмәгә тәкъдим ителгән проектлардан И. Харитонов, Хәсән Гали, Әхмәтҗан Мостафа, Фаик Таһиров, Муллашов проектларында гарәп язуының гомуми күренешен нигездән үзгәртелгәнлектән матбугатта гамәлгә үткәрү мөмкин түгел.

2. Иптәш Урманче проектын хәзергә кадәрге басма хәрефләргә нигез булган нәсех язуыннан ераклашканлыктан гомуми матбугат өчен текст хәреф итеп алына алмый. Ләкин «ай» кебек шәкелләрне төзәтү белән хәреф төрләндерүдә бер стиль итеп алынуы мөмкин табыла.

3. Киңәшмәдә каралган проектлардан (әлифба тәртибе белән) Алпаров, Идрисов, Бурнашев, Тукай, Шәрәф иптәшләрнең бергә калдырылган шәкелләре киңәшмә тарафыннан кабул ителгән әсәсларга муафыйк табылып, болар һәммәсе дә матбугатта текст хәрефе итеп куллану өчен ярасалар да, хәрефләрнең формаларын ачыграк итү һәм бөтен сүз шәкеле күрсәтүләре һәм матурлык ягыннан беркадәр җитешсезлекләре булганлыктан төзәтмәләр кертелергә тиеш.

(Хәреф ислахы турында Казанда 1926 елның октябрендә җыелган киңәшмәнең карары. Мәгариф.1926 ел.)

ҖИҢҮЛӘР ҺӘМ НӘТИҖӘЛӘР

Хезмәтләрне тәртипкә салу, кимчелекләр өстендә эшләү ел дәвамында алып барыла. Конференциядә матбагат хәрефләрен башта 4 шәкелдән 2 шәкелгә, аннан соң якын арада баш хәрефләргә якын булган бер генә шәкелгә калдырырга дип карар чыгарыла. Хәреф реформасы турындагы карарларны тормышка ашыру, төрле җирләрдәге тәҗрибәләрне бергә җыйнап өземтә ясар өчен, Татарстан Мәгариф халык комиссариаты 1927 елның 20 май киңәшмәсендә төрек-татар хәрефләренең реформа проектларына ярыш игълан итә. Советлар Союзының төрле төбәкләреннән вәкилләр катнаша. Жюри рәисе итеп Мөхәммәд Таһиров билгеләнә. Әгъзалар: Зыя Насыйров, Самат Шәрәфетдинов, Галимҗан Шәрәф, Лотфи Вахидов, Бакый Урманче, Гаяз Максудов, Гали Рахим, Ибрагим Кулиев, Габдрахман Измайлов.

Жюрига барлыгы 150 проект тәкъдим ителә. Аларның һәммәсе дә диярлек кулланылышта булган төньяк (Казан) һәм көньяк (Истанбул) матбугат хәрефләре стиленә якын итеп эшләнгәннәр. Комиссия бу проектларның һәммәсен аерым альбом рәвешендә бастырып таратуны да күздә тота. Конкурска тәкъдим ителгән проектлар матбугат хәрефләре реформасын гамәлгә ашыру халык өчен «җиңел язуы» да күз алдында тотыла.


Отдел к №1.

Т.С.С.С. СОВЕТ НАРОДНЫХ КОМИССАРОВ Татар.Соц.Сов.Респ.
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛАМИ, ...Отдел "9 " апреля 1924 г.
№ 2073, Казань ,Татсовнарком, тел.Совнаркома № 8-49 и
№ 32.

АТТЕСТАТ.

Пред"явитель сего гравер Идрисов Мухамет Ибрагимович действительно гравировал и выполнял в период времени с 1921г. до начала 1923 года по договору с Тройкой по реформе татарско го шрифта при Татсовнаркоме 7 комплектов матриц реформирсванных татарских печатных шрифтов, в основу которых были положены образцы и начертания, установленные Идрисовым М.И. и принятые по специальному конкурсу Академическим Центром Татнаркомпроса.

Выполненные им матрицы (около 400 штук) были приняты Трой кой по реформе татарского шрифта и переданы для неограниченно эксплоатации в Казанскую Государственную словолитню. В настоящее время по ним отливаются шрифты и постепенно в употребление как в Татарской печати АТССР и други стей, так отчасти в печати и других восточных народ СССР.

Вводимая реформа имеет для восточной печати гро значение и будущность.

Гражданин Идрисов,будучи единственным достаточ цированным специалистом в данной области среди тат порученное ему задание умело и преданно.

Бывш.председатели Тройки по реформе татарского шрифта в разное время - Подписи

9/1У-24г.

Печать. Секретарь Тройки - (Г.Шараф)


Шараф Галимджан Шарафович (1886-1950), языковед.

Архив Казанского ... АН СССР
ФОНДА 20
ОПИ И 3
ЕД.ХР. 45

1926. Тукаев Шахзаде – зав. Уфимской мастерской шрифтов „Образцы шрифтов". На первом листе автограф автора: „На память товарищу Шарафу Галимджану. Шахзада Тукаев." 15 февраля 1926 г. Брошюра, на татарском языке, арабском шрифте. На 32 листах

1926 Тукаев Шаһзадә – Уфа шәһәренең хәрефләр мастерское мөдире. „Хәрефләр үрнәге" Беренче биттә „Галимҗан Шәрәф истәлеккә. Шаһзадә Тукаев"; дигән афтограф. 15 февраль, 1926 ел. Брошюра татар телендә, гарәп шрифтендә. 32 биттә

Конкурска нәтиҗәләр 1927 елның 24 сентябрендә ясала. Мәскәүдән – Мөхәммәд Идрисовның һәм Габдрахман Бурнашев, Казаннан Ибраһим Зәйнуллин белән Котдус Фәхретдиновның проектлары, Уфадан Шәйхзадә Тукаевның афиша хәрефләре проекты сайлана.

Матурлык, кисү-кою ягыннан иң пөхтә эшләнгән итеп Мөхәммәд Идрисовның төрле кегельләрдә эшләнгән проекты беренче урын ала. Бу проект буенча эшләнгән хәрефләр бөтен төрек-татар дөньясында матбугат хәрефләре буларак кулланылышка кертелә.

Конкурста җиңүчеләр: беренче урын – Мөхәммәд Идрисов, икенче урын – Ибраһим Зәйнуллин белән Котдус Фәхретдинов, өченче урын – Шәйхзадә Тукаев. Җиңүчеләр акчалата премияләр белән бүләкләнәләр.

Милли музей фондында Мөхәммәд Идрисовның эшчәнлеген чагылдырган архив саклана. Аны музейга Мөхәммәд Идрисовның туганнары тапшырган. Шул архивта 1927 елда үткәрелгән конкурс вакытында төшкән фото да бар. Төшүчеләрнең күбесе репрессияләнгән. Хәзерге вакытта шәхесләрне барлау эше дәвам итә.

Мөхәммәд Идрисовның типографиядә басу өчен эшләнгән нәсех гарнитурасы үрнәкләре турында аттестат.

Шаһзадә Тукаевның агачтан игълан хәрефләре мастерскоенда эшләнгән хәрефләр үрнәге турында мәгълүмат. Уфа.



КЫШКЫ ЯЛЛАРНЫ – ЗАТЛЫ КИТАПЛАР БЕЛӘН!

Автор: Луиза Янсуар

Китап киштәләрендә быелгы елның тәмледән-тәмле китаплары пәйда булды. Шулар арасында мин икесен аеруча көтеп алдым. Болар – сәнгать турында һәм сәнгатьтәге шәхесләр турында безнең дөньяга карашыбызны формалаштыручы, еллар буе затлы контент белән сөендерүче гүзәл ханымнарның – Сати Спивакова белән Дарья Златопольскаяның яңа тупланмалары. Бу яңа китаплар – Яңа ел ялларында укыр өчен менә дигән күчтәнәч. Нәкъ менә иркен һәм талгын көйләнешкә күчеп, уйланып һәм гамьләнеп...

КИТАП КИШТӘСЕ



СОКЛАНУ ЭСТЕТИКАСЫ

Сати Спивакова.
«Нескучная классика. Еще не все».
АСТ, «Редакция Елены Шубиной», 2020.

«Камертон», «Нескучная классика» кебек атаклы телетапшырулар алып баручысы Сати Спивакованың «Культура» каналында 15 елдан артык барган циклы мәдәниятнең хәл-әхвәлен күзәтеп баручыларга бик яхшы таныш, дип уйлыйм. Бу тапшырулар аша без чорыбызның күренекле шәхесләрен тирәнрәк белдек, аларның күңеленә һәм фикерләренә, ә димәк ки, галәмнәренә дә якыная төштек. Мин үзем Сати Спивакова тапшырулары аша тулы бер буын тәрбияләнде һәм затлы мәктәп алды, дип исәплим.

Заманында «Нескучная классика» тапшырулар циклын Сати Спивакова Майя Плисецкая белән ачып җибәрә – бу инде легендага әверелгән тарих. Яңа китабында ул беренче тапшыру алдыннан булган сөйләшүне дә китерә. Ул чакта, «Нескучная классика»ның чишмә башында, Майя Плисецкая болай дигән була: «Әлбәттә, киләм, Сатенька. Мин бит бик яхшы аңлыйм – миннән башласаң, программа уңышлы булачак. Ә бу бик мөһим!» Чынлап та, беренче кунакның кулы да, аяклары да җиңел булып чыга, бу тапшыру исә иң затлы цикллар исемлегенә керә. Әлеге затлылык тапшыруның рейтингын да булдыра, шулай ук аның масштабын, колачын да гаять киңәйтә. Шушы дистә ярым вакыт аралыгында «Нескучная классика» аша узган сәнгатькәрләрнең исемнәре генә дә бик күпне сөйли: Михаил Шемякин, Татьяна Черниговская, Шарль Азнавур, Алла Демидова, Теодор Курентзис, Фанни Ардан, Гия Канчели, Хибла Герзмава, Хосе Каррерас, Николай Луганский, Валентин Гафт, Елена Образцова, Дмитрий Хворостовский, Дина Рубина, Роберт Уилсон, Сергей Юрский, Соломон Волков, Андрей Кончаловский, Борис Эйфман, Григорий Соколов һ.б., һ.б.

Сати Спивакова тапшыруы – акыллы әңгәмәдәш белән гәп кору форматы. Һәм мин тагын шуны да өстәр идем: сокланып, яратып гәп кору форматы. Безнең бүгенге цинизм чәчәк аткан чорда аның кадере дә – әнә шунда, ягымлы булуында. Бәлки, шуңа да профессиональлек турындагы сөйләшү, табигый рәвештә, тормыш, язмыш турындагы сөйләшүләргә күчә. Биредә шәхесләр һәм кешеләр кисешә, аларның кыйпылчыклары да, бөтенлеге дә уч төбендәгедәй күренә. Бигрәк тә кызыклы сөйләшүләр арасында мин үзем кызыл җеп булып сузылган шул теманы алыр идем: нәрсә ул бүгенге кырыс һәм каршылыклы чорда – гармония? Ни ул – кешелеклек? Әнә шул сөйләшүләр Сати Спивакова тапшыруын галәми масштабка, фәлсәфи категорияләр яссылыгына чыгара да.

«Нескучная классика» телетапшырулары циклын «Культура» каналы архивларында һәм Ютуб-каналда табарга мөмкин. Яңа ел ялларында карар өчен – менә дигән акыллы, кызыклы, затлы тапшырулар шәлкеме.

«Бу китапны язаргамы, юкмы дип озак икеләндем. Беренче китапта мин инде кайбер әңгәмәләрне бастырган идем бит. Кешеләргә тагын китап ник кирәк, тапшыруларны Интернетта табып карарга мөмкин ич», – ди Сати Спивакова үзе. Әмма пандемия чорында, вакыт төшенчәсе башкача ваемлана башлап, анализлау ноктасында ул шуны аңлый: яңа китап – әңгәмәләр циклы гына түгел, ә үзеңне һәм яшәгән дәвереңне анализлау, аңлауның да бер этабы ул. Беренче китаптан соң монда авторның үзенең дә үткән юлын күрергә мөмкин, һәм бу әле аның соңгы китабы да булмас кук тоела.

Китап мантыйк ягыннан да, рефлексия тудыру көче ягыннан да гаять минималистик һәм тыйнак итеп төзелгән, автор артык бер генә жестка да урын калдырмый, монда – спартан кырыслыгы һәм антик чорныкына тартым диярдәй эстетика. Һәм менә шул җәлеп итә, сихерли дә. Минем үземә авторның «кычкырып тормавы» да бик ошады. Гадәттә, моннан котыла алмый документалистика һәм эссеистика, нон-фикшн жанрында эшли торган затлар.

«Иң якын кешеләр белән тапшыру эшләү авыррак, – ди Сати Спивакова. – Минем өчен иң авыр интервью тормыш иптәшем Владимир Спиваков белән булды (ә ул программа кунагы буларак 3 мәртәбә чакырыла. – **Авт.**). Спиваковка минем белән бер кадрда бик үк уңайлы булмады шикелле». Әнә шулай итеп без тапшырулар лабораториясенә дә аяк атлыйбыз. Әмма безне артык түргә җибәрмиләр, болай булган очракта, әнә теге затлылык җуелыр иде. Калсын ике арада үтә күренмәле пәрдә – шулай булырга тиеш тә, юкса, без бүген болай да инде күренекле шәхесләрнең эчке киеменә кадәр үтеп кердек. Болай иткән хәлдә, хөрмәт итәрдәй ни калсын?!

«Нескучная классика», белгәнебезчә, ул әле мәгърифәт, белем бирү форматын да күздә тота. Тапшыру вакытында без тамашачылардан сораулар ишетәбез, алар күзлеге һәм рефлексиясе аша шәхесне бәялибез. Китап, аңлашыла ки, моннан азат. Әмма Сати Спивакова ничектер гаҗәеп бер эффектка ирешә алган: китапны укыганда, миндә бер үк вакытта мин бу шәхес белән йөрәккә-йөрәк дигән тәэсир дә кала, тирә-яктагы аудитория һәм эпоха сулышы тәэсире дә.

«Минемчә, китап якты булып чыкты, – ди автор. – Ул – минем тапшыруга килгән һәм минем белән үз язмышларының бер өлешен бүлешкән кешеләргә бүләгем. Сайлау бик авыр булды – кемнәрне кертергә, кемнәрне калдырырга... Бик зур бер әңгәмәне кертергә теләгәч, редактор Елена Шубина болай диде: «Сати, китапның төпсәсе бу кадәрне чыдата алмаячак...»

КИТАП КИШТӘСЕ

АЯУСЫЗЛЫК БЕЛӘН ШӘФКАТЬ ЧИГЕНДӘ

Дарья Златопольская.
«Настоящее. Диалоги о силе, характере, надежде».
Эксмо, 2020

«Белая студия»нең стериль, әмма, шуңа да карамастан, гаҗәеп нур белән өретелгән атмосферасын кичкән каһарманнар үзләрен ничек хис итәдер, анысы, әлбәттә, сер. Әмма без, аларны тыңлаганнан соң, тәгаен үзгәреп калабыз, ул студиядән башка кешеләр булып чыгабыз, монысына иманым камил.

Кара-каршы кәнәфиләрдә утырып сөйләшкәндә, уңайлымы икән, юкмы шәхесләргә, белмим, әмма без алар белән бергә катарсиска килми калмыйбыз – күз яшьләрен дә күргәнебез булды безнең тапшырулар (порталлар дияр идем!) вакытында, уйга талуларны да, моңарчы яңгырамаган ихлас тәүбәләрне дә... Һәм – ни генә булмасын – утәли караган Дарья Златопольская карашында бер кәлимә хөкемдарлык яисә казыйлык чалымы да юк, ул һәрчак – герое ягында, ул тапшыру дәвамында аның өчен көрәшә. Юк, позицияләре белән килешә, аклый, безне тәэсирләндерергә, сокландырырга тырышмый. Ул каһарманнарын артык ихтирам итә, болай эшләмәслек дәрәҗәдә.

Аяусызлык белән шәфкать чигендә калып, әңгәмә кору – ул ничек бирелә? Бәлки, нәкъ менә шушы язмышларны үзең аша кичерү этәрәдер, китерәдер дә «Настоящее» кебек китапларны язуга. «Культура» каналында 2012 елдан бирле шимбә кичләрендә чыгып килгән тапшырулар циклын даими һәм кат-кат караучыларның берсе буларак, миңа Дарья Златопольскаяның үзенең рефлексиясе дә гаять кызыклы. 200 дән артык әңгәмә, алар арасында Россия һәм дөнья сәнгатенең йолдызлары – музыкантлар, актерлар, язучылар, композиторлар, галимнәр, режиссерлар, руханилар, медиумнар...

Тапшыруда яңгыраган төшенчәләр аша ниндидер ачкыч кодларга килергә мөмкин булуы турында Дарья Златопольскаяның инде әйткәне бар иде. Һәм менә китапларында ул шуларга орына да. Орына да, шунда ук ботарлап, эченә кереп карамый, таркатмый, ә саклык белән якын килергә тырыша... Менә, «ватан» төшенчәсе – аны без ничек аңлыйбыз? Берәмләп-берәмләп – ничек тә, күмәкләп – ничек. Безнең шәхесебез белән «ватан» төшенчәсе арасында тәңгәллек – ни дәрәҗәдә? «Ватан» («родина») сүзе искиткеч монументаль, әйтерсең, ул – тынлы оркестр», – ди Дарья Златопольская. Мин, укучы буларак, шунда ук тамырларымның кубарылуын тоям – ә миндә ул төшенчә, яңгырауга ук, ирендә сөт тәмен тоюга китерә, әйе, әйе, әнә теге сөтне, әле Дәрдемәнд язып калдырганны...

Менә «ватан» төшенчәсе аша без тормыш реалийләренә һәм дәвер кыйпылчыкларына тоташа башлыйбыз. Һәм йөрәк камерасы конкретрак детальләргә фокуслана башлый – шәһәр, ишегалды, таган, комлык... безнениләр тәрбияли һәм, кеше буларак, билгели. Ә нәрсәләр, яраларга әверелеп, җөйләнгәннән соң да кан саркып тора?

Ни өчен соң китапның исеме – «Настоящее» дигән сорау туа. Гәрчә без бөтен ракурслардан торып Вакытны һәм Җирлекне бәялибез, үзебезнең урынны тәгаенлибез икән? Юкка гына түгел. «Хронотоп» төшенчәсе ул әле тышкы катлам белән генә түгел, ә йөрәк элпәсе белән дә турыдан-туры бәйле. Бу сорауга җавап – «Белая студия»нең барлык тапшыруларында да анык тоемлана, китапта та кереш сүздә үк ассызыклана.

«Әгәр без тулаем менә шушы, хәзерге, мизгел белән тоташып бетәбез икән, әгәр безнең каршыбызда шушы мизгелдә утырган кеше бөтен барлыгыбызны били икән, менә шушы мизгелдә эшләгән эшебез безне тулаем җәлеп итә һәм үзенә баштанаяк чумдыра икән, – бу чын яшәүнең үзе, дигән сүз. Әмма безнең аңыбыз еш кына компьютер мониторын хәтерләтә, әйтерсең, аңарда бик күп вкладкалар ачылган. Алар баш миенең эшчәнлеген акрынайта һәм энергияне суыра. Ачык космоска беренчеләрдән булып чыккан Алексей Леонов миңа әңгәмә барышында әйткән иде: галәмдә тиешле гамәлләрне башкарганда, һәр конкрет мизгелдә аңны кабызган килеш тотарга һәм һәр гамәлне тиешле вакытында үтәргә кирәк. Әгәр анда перспективаларны анализлый башласаң, секунд эчендә кабул ителә торган карарлар өчен акыл тизлеге җитмәс иде. Ә синең гамәлләреңнән бит кешеләр гомере тора...»

Дарья Златопольская маңгайга терәп нәтиҗәләр ясамый, ул аларны фиксацияли генә. Әмма без аның уйларының аргы ягында гаять күп кешеләрнең фикерләре сөземтәсе белән язмышлар спектры ятканын бик яхшы аңлыйбыз. Менә шушы мизгелдә, галәмдә һәм вакыт кыйпылчыгы эчендә булуның, ахыр чиктә, Кешелек омтылган иң зур максатлардан берсе икәнлегенә инануын китерә ул. Бәлки, бу әле бәхеткә илтә торган иң ачык сукмак та, дип җөпләп куя.

Әңгәмәләрне укыганда, аларны уратып алган интертекстуаль кыр да зур ләззәт бирә. Бер геройдан икенчесенә күчүеңне сизми дә каласың ә бу табигый тоташканлык, чөнки без – бер дәвер балалары. Әйе, төрле система, тәрбия, инанулар белән яшәүчеләр, анысы хак. Ләкин һәммәбезнең дә Чынлыкка ышанасы килә, мизгел эчендә Мәңгелекнең барлыгына инанасы... Димәк ки, бәхетлерәк тә буласы.

Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

Яхшы рекламаны тормыш таләп итә, осталар ясый, барысы да кабул итә.

Иван Егоров, VI чакырылыш ТР Дәүләт Советы депутаты, «Ак Барс» холдинг компаниясе» АҖ генераль директоры, гыйнвар аенда үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Илшат ГАНИЕВ,
«Майский» теплица комбинаты» ЖЧҖ генераль директоры

«Начар җитәкче нәрсә эшләргә кирәклеген белә,

Ә яхшысы моны ничек эшләргә кирәклеген күрсәтә».

Анатолий Васильевич Луначарский

УҢЫШ, НӘТИҖӘЛЕЛЕК, АБРУЙ

– Хөрмәтле Иван Михайлович!

Шәхсән үз исемемнән һәм теплица комбинаты хезмәткәрләре коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйм!

Тормыш юлыгыз – күркәм уңышларга, республика агросәнәгать комплексында эшләүче хезмәттәшләрегез һәм халык арасында абруйга, хөрмәткә ирешүнең һәм хезмәт сөючәнлекнең искиткеч үрнәге. «Ак Барс» холдинг компаниясе» АҖ генераль директоры буларак, Сез республиканың агросәнәгать комплексын, илнең азык-төлек өлкәсендәге иминлеген үстерүгә һәм Россия Федерациясе күләмендә оборона сәнәгатен ныгытуга бәйле иң җитди мәсьәләләрне хәл итәсез. Гаять бай эш тәҗрибәгез, компетентлыгыгыз, оештыру сәләтегез һәм икътисад тармагындагы мәсьәләләрне яхшы белүегез нәтиҗәсендә Сез җитәкләгән компания Татарстан Республикасының алдынгы предприятиеләренең берсенә әйләнде. Югары профессиональлек, искиткеч җаваплылык һәм эшкә сәләтлелек, төбәк проблемаларын тирән белү Сезне Татарстан территориясендә иң хөрмәтле һәм нәтиҗәле идарәчеләрнең берсе итте. Төрле җитештерү проблемаларын чишү максатына белгечләрне туплый, кызыксындыра һәм оештыра белү сәләтегез һәркемгә яхшы мәгълүм, бу Сезне дәрәҗәле җитәкче, бихисап күп юнәлештәге эшләр башкарыла торган зур предприятие башлыгы итеп күтәрде.

Сезнең тырышлыгыгыз нәтиҗәсендә холдинг компаниясе бүген Татарстан Республикасы икътисадында мөһим роль уйный. Күпсанлы хезмәт коллективларыннан торган федераль әһәмияткә ия предприятиеләрнең эре берләшмәсендә генераль директор булып та, республика парламентында халык ышанычын яулаган депутат сыйфатында Сез закон чыгару эшчәнлеге өчен вакыт табасыз. Сезне VI чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы тәҗрибәле коллегам һәм зур профессионал буларак хөрмәт итәм. Сез иҗтимагый эшчәнлек белән дә җитди шөгыльләнәсез – Әфганстандагы хәрби хәрәкәтләрдә, Төньяк Кавказ төбәгендә терроризмга каршы операцияләрдә катнашкан ветераннар тормышында актив катнашасыз, Татарстан җирендә халык гореф-гадәтләрен саклап калырга булышасыз, яшьләргә спорт белән шөгыльләнү эшен оештыруда ярдәм итәсез һәм үсеп килүче буын вәкилләре арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалыйсыз. Сезнең һөнәри һәм иҗтимагый эшчәнлегегез үзенә йөкләнгән бурычларга җаваплы мөнәсәбәтнең ачык үрнәге һәм күпкырлы җитәкче өлгесе булып тора. Аграр бизнесны үстерү буенча коллегагыз, Татарстан Республикасы халкын һәм Россиянең эре сәнәгать үзәкләрен яңа җыелган яшелчә продукциясе белән тәэмин итү өчен җаваплы хезмәттәшегез буларак, тармак үсешенә һәм авыл хуҗалыгын модернизацияләүгә, авыл территорияләрен торгызу өчен эш урыннары булдыруга керткән өлешегезне дә билгеләп үтәм.

Хөрмәтле Иван Михайлович! Юбилеегыз көнендә Сезгә озын-озак еллар буе корычтай сәламәтлек, мөһим вазыйфагызда яңа проектларны тормышка ашыруда һәм ният-максатларыгызга ирешүдә уңышлар телим! Сезгә дәвамлы гаилә бәхете һәм иминлек насыйп булсын!

Реклама

Фото «Майский» теплица комбинаты» ЖЧҖ тарафыннан бирелде

Владимир Иванов, «Дәүләт гамәли оптика институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ генераль директорының беренче урынбасары – фән буенча урынбасары, техник фәннәр докторы, профессор, Россия һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, гыйнварда үзенең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

ГИПО

Виллен Балоев, «Дәүләт гамәли оптика институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ генераль директоры

ОЕШТЫРУЧЫ, КОНСТРУКТОР ҺӘМ КӨЧЛЕ ҖИТӘКЧЕ

– Хөрмәтле Владимир Петрович!

«Дәүләт гамәли оптика институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ коллективы Сезне чын күңелдән 70 яшьлек юбилеегыз белән тәбрик итә!

Предприятиедә хезмәт куйган 47 елдан артык гомерегезнең егерме елында Сез аның җитәкчесе вазыйфасын башкардыгыз. Бу чорда институт фәнни тикшеренүләрнең һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләренең яңа юнәлешләрен актив үстерде, шул рәвешле киләчәк уңышларга нигез салды. Әлеге елларда берләшмә җитештерү базасын ныгытты, илебездәге оптик-электрон приборлар ясау тармагының төрле юнәлешләрендә алдынгы позицияләрне яулады. Предприятие коллективы Сезне, беренче чиратта, фәнни һәм җитештерү эшчәнлеген оештыручы, кайбер мөһим эшләнмәләрнең баш конструкторы, үз тырышлыгын институт алдында торган бурычларны хәл итүгә гел тугел, аның ерак киләчәккә караган перспективаларын тәэмин итүгә дә юнәлдергән көчле җитәкче буларак белә. Техник яктан яңадан коралдану, кадрлар белән тәэмин ителешне ныгыту, өметле эзләнү-тикшеренү эшләрен алып бару мәсьәләләренә һәрвакыт зур игътибар бирдегез. Бай тәҗрибәгез һәм тирән белемегез, тиешле нәтиҗәләргә ирешә алуга чиксез ышанычыгыз «Швабе» оптика холдингы һәм аңа караган институт бурычларын хәл итүдә һәрвакыт принципиаль һәм актив позициягез өчен нигез булып тора.

Ташып торган энергия, үз-үзеңә һәм кешеләргә карата таләпчәнлек, иң мөһим урынны күрә-аера һәм коллективны тиешле тарафка юнәлтә белү кебек шәхси сыйфатларыгыз бүген илебездә приборлар төзү лидерларының берсе булган предприятиенең күркәм уңышларына ярдәм итте.

Без предприятиенең көндәлек эшчәнлеген оештырудан тыш та нинди колачлы эшләр башкаруыгыз һәм бүген дә аларны дәвам итүегез турында яхшы беләбез. Сез Россия Федерациясе Хәрби-сәнәгать комиссиясенең фәнни-техник советы әгъзасы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, Казан югары уку йортларының диссертация советлары әгъзасы да булып торасыз. Фәнни һәм иҗтимагый эшчәнлегегездә Сез беренче чиратта эш мәнфәгатьләрен алгы планга куясыз.

Фидакарь хезмәтегез Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, төрле министрлыклар, ведомстволар һәм оешмаларның югары бүләкләре белән лаеклы билгеләп үтелде. Сез – Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе, Фән һәм техника өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте премиясе лауреаты. Шулай ук Почет ордены, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләндегез. Татарстан халыкларының гореф-гадәтләрен һәм мәдәни мирасын саклауга даими игътибарыгыз ике тапкыр Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесенең Рәхмәт хаты белән билгеләп үтелде.

Сез хәл итә торган мәсьәләләрнең киңлеге һәм катлаулылыгы хәзер дә югары дәрәҗәдә кала бирә. Сезгә алга таба да иҗади уңышлар телибез, илебезнең оборона сәләтен күтәрү максатында Сезнең кул астында җитештерелгән яңа эшләнмәләрне сынауда уңай нәтиҗәләр, кызыклы тикшеренүләр насыйп булсын! Чираттагы катлаулы бурычның уңышлы хәл ителүеннән канәгатьлек хисе кичерүегезне телибез. Юбилеегыз көнендә Сезгә, хөрмәтле Владимир Петрович, нык сәламәтлек, гаилә җылысы, оныкларыгызның шат йөзе һәм янып торган күзләре белән куандыруын, иминлек һәм бәхет телибез.

Реклама

Фото «Дәүләт гамәли оптика институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ тарафыннан бирелде

Альберт Кәримов, Татарстан Республикасы премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, гыйнвар аенда юбилеен билгеләп үтә.

КМПО

Дамир Кәримуллин,
«КМҖБ» АҖ
генераль директоры

УҢЫШЛЫ ҖИТӘКЧЕ

– Хөрмәтле Альберт Әнвәрович!

«Казан моторлар җитештерү берләшмәсе» АҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне туган көнегез белән тәбриклим, бездән иң җылы котлаулар һәм изге теләкләрне кабул итегез!

Сезнең бөтен эшчәнлегегез республикабыз тормышы белән тыгыз бәйләнгән. Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә министры вазыйфасы бик зур киеренкелек, җаваплылыкны күз уңында тота, чөнки сәнәгать тармагы күп очракта икътисадның үсеш дәрәҗәсен билгели.

Сез көн саен Татарстан сәнәгатен үстерү белән бәйле четерекле мәсьәләләрне хәл итәсез. Инновацияле проектларны гамәлгә кертү, сәнәгый һәм инновацион эшчәнлеккә дәүләт ярдәме механизмнарын формалаштыру һәм аларны тормышка ашыру, инвестицияләр җәлеп итү юлыннан уңышлы алга барасыз. Сезнең фидакарь хезмәтегез нәтиҗәсендә эшкуарлык тармагын оештыру һәм үстерү, аны модернизацияләү өчен уңайлы шартлар тудырыла. Хәзерге көнгә инде күп эшләр башкарылды, әмма иң мөһиме һәрвакыттагыча әле алда көтә!

Сез – бай тәҗрибәгә ия җитәкче. Хезмәт вазыйфаларыгыз ныклык, үткен акыл һәм тирән аналитик фикерләү сәләте таләп итә, һәм Сез бу сыйфатларга ия. Сезнең белән бергә республика файдасына эшләвебез белән чын күңелдән горурланабыз һәм шатланабыз!

Сезгә киләчәктә дә эшегездә яңадан-яңа үрләр яуларга, ниятләгән барлык проектларны гамәлгә ашырырга насыйп булсын. Һәр эштә уңышлар, яңа идеяләр, сәламәтлек, оптимизм һәм бәхет телибез! Көч-куәтегез һәрчак ташып торсын, ә тырыш хезмәтегез һәрвакыт лаеклы нәтиҗәләргә китерсен!

Реклама

ТАТЭНЕРГО

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

ЭШКӘ СӘЛӘТЛЕЛЕК ҺӘМ МАКСАТЧАНЛЫК

– Хөрмәтле Альберт Әнвәрович!

Шәхсән үз исемемнән һәм «Татэнерго» АҖ хезмәткәрләре исеменнән юбилеегыз уңаеннан ихлас котлауларны кабул итегез!

Сез Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән уңышлы җитәкчелек итәсез. Республикабыз сәнәгатен ныгыту юнәлешендәге мөһим дәүләт мәсьәләләрен хәл итүгә керткән өлешегез бәяләп бетергесез. Күп кенә колачлы проектларны гамәлгә ашыру шәхси тырышлыгыгыз һәм Сез җитәкләгән министрлыкның нәтиҗәле эше бәрабәренә мөмкин булды. Сезнең көндәлек хезмәтегез – эшлеклелекнең югары дәрәҗәсе, максатчанлык һәм һөнәри осталык үрнәге.

Хезмәттәшләрегез Сезне алдан күреп эш итәргә сәләтле җитәкче, тәҗрибәле дәүләт эшлеклесе, шәп оештыручы буларак хөрмәт итәләр. Сез – югары дәүләт бүләкләренә лаек булган күренекле белгеч, тәҗрибәле стратег. Предприятиебезгә, республиканың барлык энергетика тармагына карата даими игътибарыгызны һәм ярдәм күрсәтүегезне аеруча ихтирам белән әйтеп үтәм.

Хөрмәтле Альберт Әнвәрович! Сезгә эшегездә һәм шәхси тормышыгызда чын күңелдән уңышлар, кызыклы проектлар һәм яңа казанышлар телим! Бәхет, иминлек һәм нык сәламәтлек Сезгә!

Реклама

Фото «КМҖБ» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды. Фото «Татэнерго» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды

Виллен Балоев, «Дәүләт гамәли оптика институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ генераль директоры

ЮГАРЫ ПРОФЕССИОНАЛЬЛЕК ҺӘМ ОСТАЛЫК

– Хөрмәтле Альберт Әнвәрович!

Юбилеегыз көнендә «Дәүләт гамәли оптика институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» АҖ коллективы һәм аның җитәкчелеге исеменнән ихлас котлауларымны кабул итегез!

Сезгә хас югары профессиональлек һәм осталык, карарлар кабул иткәндәге игътибарлылык, сабырлык, кешеләрнең тырышлыгы алга куелган бурычларны хәл итүгә алып барачагына ышаныч һәм оптимизм, камил зирәклеккә, төпле белемгә әйләнеп, Сезгә Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы командасы белән нәтиҗәле җитәкчелек итәргә мөмкинлек бирә.

Үз һөнәри эшчәнлегегездә Сезгә республикабыз тормышының барлык өлкәләрен дә өйрәнергә һәм белергә, аларны бөтен ил үсешенә хас тенденцияләр белән чагыштырып, Татарстан өчен бик мөһим күп мәсьәләләр буенча федераль үзәк белән әңгәмә корырга туры килә. Икътисадый үсешнең төп күрсәткечләре буенча республикабызның һәрвакыт алдынгы позицияләрдә торуында Сезнең өлешегез зур.

Тыйнаклыгыгыз һәм үз-үзегезгә таләпчәнлегегез, конструктив әңгәмә кора белүегез, тирә-юньдәгеләргә игътибарлы мөнәсәбәтегез хезмәттәшләр һәм фикердәшләрегезнең ихтирамын яулады, республика һәм аннан читтәге предприятие директорлары арасында зур абруен казанды.

Үзегезгә һәм якыннарыгызга сәламәтлек, бәхет, иҗади энергия һәм иминлек телибез!

Реклама

Илнур Сәгъдиев, «Казанкомпрессормаш» ГАҖ идарәче директоры

ЧЫН ПРОФЕССИОНАЛ

– Хөрмәтле Альберт Әнвәрович!

«Казанкомпрессормаш» ГАҖ коллективы исеменнән Сезне 45 яшьлек гомер бәйрәмегез белән чын күңелдән котлыйм!

Без Сезне тәҗрибәле дәүләт эшлеклесе һәм чын профессионал, куәтле тормыш энергиясенә, табигый мөлаемлык белән оештыру талантына ия искиткеч кеше буларак беләбез һәм хөрмәт итәбез. Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгын җитәкләп, Сез инновацияле технологияләр кертү һәм республиканың товар җитештерүчеләрен чит илләрдә актив таныту, пропагандалау хисабына илебез сәнәгатенең көндәшлеккә сәләтлелеген арттыру белән бәйле мәсьәләләрне хәл итүгә зур өлеш кертәсез.

Сезгә хас һөнәри осталык, стратегик фикерләү, тирән тәҗрибә, нәтиҗәле һәм үз вакытында карарлар кабул итә белү республика сәнәгате үсешенә һәрвакыт ярдәм итә. Сез сәнәгать предприятиеләрен техник яктан яңадан коралландыру һәм яңарту-камилләштерүгә, шулай ук бизнеска үз вакытында һәм уңышлы дәүләт ярдәме күрсәтүгә аерым игътибар бирәсез. Бу исә республика икътисады һәм сәнәгатенең аеруча мөһим тармакларында импортны алыштыру юнәлешендә уңышлы эш алып барырга мөмкинлек тудыра. Бу тантаналы көндә исә предприятиебезгә күрсәткән ярдәмегез, заводны алга таба үстерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәребезгә карата игътибарлы мөнәсәбәтегез һәм конструктив хезмәттәшлек өчен ихлас рәхмәтемне һәм хөрмәтемне белдерергә рөхсәт итегез.

Хөрмәтле Альберт Әнвәрович, сайлаган тормыш юлыгызда яңа казанышлар өчен үзегезгә хас үҗәтлек һәм зирәклек сыйфатын саклап калуыгызны, туган республикабыз хакына игелекле эшегездә уңышлар телибез.

Бәхет, сәламәтлек, иминлек һәм иң изге теләкләр Сезгә!

Реклама

Фото «ДГОИ» ФҖБ» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды. Фото «Казанкомпрессормаш» ГАҖ матбугат хезмәтеннән алынды

Роза Гатина,
«Дәүләт химик продуктлар фәнни-тикшеренү институты» ФКП директоры

ИЛ ХАКЫНА ЭШ

– Хөрмәтле Альберт Әнвәрович!

«Дәүләт химик продуктлар фәнни-тикшеренү институты» федераль казна предприятиесе коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне чын күңелдән юбилеегыз белән котлыйм!

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы җитәкчесе вазыйфасында куйган тырыш хезмәтегез нәтиҗәсендә илебезнең оборона-сәнәгать комплексы ныгый бара, Татарстан заводлары продукциясе белән кызыксыну югары дәрәҗәдә кала. Сез республика оборона предприятиеләрен үстерүгә һәм модернизацияләүгә, сәнәгатькә яңа технологияләр кертүгә һәм яңа сату базарларын булдыруга һәрвакыт аерым игътибар күрсәтәсез. Олы бурычларны алга куя һәм нәтиҗәләргә ирешә белү, фәнни нигездәге производстволарны һәм инновацияле алымнарны үстерү өчен стратегик карарлар кабул итү сәләте Сезне зирәк идарәче итеп танытты. Сезнең хезмәт – оештыру талантын һәм эшлеклелек сыйфатларын илебез үсеше хакына хезмәт итү белән бергә кушканда, күп эшләр башкарырга мөмкин икәнлегенә ачык мисал.

Россиянең дары ясау тармагында бөтендөнья хәрби-оборона сәнәгатенең яңалыкларын уйлап табучы алдынгы предприятиеләреннән берсенең җитәкчесе буларак, эшебездә булышлык күрсәтүегез өчен рәхмәтемне белдерәм.

Хөрмәтле Альберт Әнвәрович, җаваплы хезмәтегездә киләчәктә дә уңышлар, бәхет, ныклы сәламәтлек һәм иминлек телим!

Алексей Слободинский,
«КАПО-Композит» АҖ генераль директоры

ЭШ КЕШЕСЕ

– Хөрмәтле Альберт Әнвәрович!

Шәхсән үз исемемнән һәм предприятие хезмәткәрләре исеменнән юбилеегыз уңаеннан ихлас котлауларымны кабул итегез!

Бүген Сез, ирешелгән үрләр турында искә төшереп, киләчәккә максатлар куя торган мөһим көнне билгеләп үтәсез. Сезнең хезмәт юлыгыз – сайлаган һөнәргә тугрылык, эшкә сәләтлелек, оештыру осталыгы һәм, һичшиксез, талантның берләшү-ярашу үрнәге. Татарстан Республикасы премьер-министры урынбасары – Татарстанның сәнәгать һәм сәүдә министры вазыйфасында Сез республика сәнәгатен модернизацияләү һәм сәүдә тармагы эшен яхшырту буенча күпсанлы мөһим эре проектларны һәм анык тәкъдим-башлангычларны гамәлгә ашырдыгыз.

Сезне чын профессионал, тәҗрибәле белгеч, ышанычлы җитәкче һәм һәрчак уңышлы нәтиҗәгә ирешергә омтылган өметле идарәче буларак беләләр. Композит материаллардан сыйфатлы әйберләр җитештерүче предприятие җитәкчесе буларак, Сезнең авиасәнәгать эшчәнлегенә игътибарыгызны һәм тармакның актуаль мәсьәләләрен хәл итүгә булышлыгыгызны билгеләп үтәм.

Хөрмәтле Альберт Әнвәрович! Җаваплы эшегездә чын күңелдән уңышлар телибез һәм ярдәмегез өчен рәхмәт белдерәбез! Үзегезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек, уңышлар, иминлек насыйп булсын!

Реклама

Фото «ДХП ФТИ» ФКП матбугат хезмәтеннән алынды. Фото «КАПО-Композит» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды

Фото «Кукмара Металл савыт-саба заводы» АҖ тарафыннан бирелде

Азат Заһидуллин,
«Кукмара Металл савыт-саба заводы» АҖ генераль директоры

Kukmara
Сделано в России
Since 1950

Сәнәгатькә ярдәм

– Хөрмәтле Альберт Әнвәрович!

Предприятие коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйм!

Мондый истәлекле көндә Сезгә Татарстан Республикасы сәнәгатен үстерүгә керткән өлешегез һәм ният-максатларыбызны хуплавыгыз өчен рәхмәтемне җиткерәм. Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры вазыйфасындагы эшчәнлегегез иң югары мактауга лаек, чөнки республикабыз файдасына хезмәт куеп, Сез тармакны модернизацияләү белән бәйле мөһим дәүләт бурычларын нәтиҗәле хәл итәсез. Сезнең тырышлыгыгыз нәтиҗәсендә Татарстан җитештерүчеләренең продукциясе кулланучыларның тиешле игътибарын яулый, яңа партнерлар һәм өметле сату базарларын таба, шул рәвешле бөтен илгә һәм дөньяга республиканың сәнәгать потенциалын күрсәтә.

Үз тарафымнан исә, предприятиебез тормышында катнашып, һәр яктан зур ярдәм күрсәткәнегез өчен рәхмәт белдерәм. Сез сәнәгать тармагы җитәкчелегендә торган чорда, Татарстан индустриясе чәчәк атсын өчен, предприятиебез үз продукциясенең сыйфатын күтәрүгә йөз тота.

Хөрмәтле Альберт Әнвәрович! Җаваплы вазыйфагызда киләчәктә дә яңадан-яңа үрләр яулавыгызны телим! Муллык, бәхет, уңышлар һәм ныклы сәламәтлек Сезгә!

Реклама

Вячеслав Козлов, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башлыгы, февральдә үзенең 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Фото Аксубай муниципаль районы матбугат үзәгеннән алынды

Камил Гыйльманов,
Аксубай муниципаль районы башлыгы

– Хөрмәтле Вячеслав Михайлович!

Сез күркәм юбилеегыз – 65 яшьлегегезне билгеләп үтәсез. Күршеләрчә һәм дусларча әлеге бәйрәмегез белән котларга рөхсәт итегез! Сезне принципиаль, гадел булуыгыз, бәхәсле чакларда уртак фикергә, карарга килергә юллар таба белүегез өчен чиксез хөрмәт итәм. Хезмәттәшләрегез дә Сезне, район башлыгы буларак, нәкъ менә әлеге сыйфатларыгыз өчен ихтирам итә, дип уйлыйм. Сезнең аркадашларыгыз арасыннан һәркем өчен бик кадерле бу.

Сез – авыл хуҗалыгы белгеченең дә, идарәченең дә иң күркәм сыйфатларын үзендә туплаган эшсөяр. Туган районыгыз, авылыгыз, кырлар һәм фермалар өчен, район башлыгы буларак кына түгел, Яңа Чишмә туфрагының чын улы буларак та ихлас күңелдән тырышасыз. Кайда туган, шунда яраган дип, нәкъ менә Сезнең кебек шәхесләр турында әйтәләрдер.

Сезгә хас сыйфатларның тагын берсе – һәрвакытта да күзгә карап дөресен, турысын әйтү. Сез дустанә мөнәсәбәттә булган, үзегез белән фикердәш кешеләрне генә түгел, ышанмыйча, шикләнеп торганнарны да инандыра белү сәләтенә ия – монда Сезнең зирәклек һәм җитәкчелек стиле һәм, әлбәттә, төрле вазыйфаларда эшләп тупланган тәҗрибәгез чагылыш таба.

Сез колхозда бригадир ярдәмчесеннән башлап, район башлыгына кадәр саллы хезмәт юлы үттегез. Шактый катлаулы елларда туган районыгызны, аннан соң – Чистай районын һәм яңадан Яңа Чишмә районын җитәкләргә туры килде.

Яңа Чишмә районын бүген аның башлыгы Вячеслав Козловтан башка күз алдына китерү дә кыен. Сезгә алга таба да районыгызны үстерү юлында зурдан-зур уңышлар телибез! Һәрвакытта да ныклы сәламәтлек, иминлек, бетмәс-төкәнмәс дәрт-дәрман юлдаш булсын! Авырлыклар килгәндә яныгызда үз җилкәсен куярга әзер тугры дусларыгыз, фикердәшләрегез һәм ышанычлы нигезегез булсын!

ЧЫПЧЫК

Автор:
Руфия Фазылова

ДУСЛЫК ЯШӘГӘН ҖИРДӘ

Яңа елда да татар авыллары турында язуыбызны дәвам итәбез. Бу юлы Биектау районының Чыпчык авылында булдык. Төрле милләт вәкилләре яши торган зур сала ул. Географик яктан да, икътисадый яктан да уңышлы җирдә урнашкан – кул сузымында гына Казансу елгасы яры, тимер юл да авыл яныннан уза. Әнә шулар авылның тарихына йогынты ясаган да инде. Хәер, бүгенгесенә дә тәэсирен дәвам итә...

Фото: Александр Ефремов

АВЫЛГА КАЙТАРУ ПЛАНЫ

Чыпчык бик зур, 1925 кеше яши анда, 500 дән артык йорт бар. Илле ике процентын – татарлар, кырык җиде процентын – руслар, калганын башка милләт вәкилләре тәшкил итә. Чыпчыкны авыл дип әйтү бик үк дөрес булмас, сала ул. Биредә ике катлы унсигез йорт бар. Авыл кешеләре сүзе белән әйтсәк: «Бай чагында салынган йортлар».

Бу якларда яшәүче кешеләр яхшы хәтерлидер: Чыпчыкта атаклы «Дружба» совхозы булган. Игенчелек, терлекчелек, яшелчәчелек – оешма авыл хуҗалыгының барлык тармакларын да колачларга тырышкан. Бүген совхоз юк инде, авыл җирләре агрофирмага карый. Шулай да халык эшсезлектән интекми. Үз эшләрен ачкан кешеләр байтак. Коркачык станциясе Чыпчыкка терәлеп диярлек тора. Ә иң мөһиме – Казан якын. Поездга утырасың да ярты сәгатьтә башкалада буласың. Чынлап та, яшәү өчен бик уңайлы урын. Урта мәктәбе, балалар бакчасы, мәдәният йорты, шифаханәсе, кыскасы, халыкның тормышын уңайлы итү өчен барлык мөмкинлекләре дә бар.

Рәшит абый Мөбәрәкзядин авылның иң абруйлы кешеләренең берсе – мәчет мулласы. Тормыш иптәше Зәйтүнә апа белән илле сигез ел бергә гомер итәләр. Өч бала тәрбияләп үстергәннәр. Гаилә башлыгы озак еллар «Дуслык» совхозында агроном булып эшләгән, Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре исеменә ия. Зәйтүнә апа исә төрле елларда авыл җирлеге башлыгы, балалар бакчасы мөдире булып эшләгән. Чыпчык урта мәктәбендә татар теле, әдәбияты укыткан.

– Чыпчыкка күченеп килгәнгә кырык җиде ел булды, – диде Рәшит абый. – Тумышым белән Балтач районының Түнтәр авылыннан мин. 1937 елда туганмын. Сугыш чоры баласы. Гомер тавык кебек җирдә казынып узды. (Көлә.)

Зәйтүнә апа – Киров өлкәсеннән, Балтач районына терәлеп торган авылда туып-үскән. Арча педагогия училищесын тәмамлагач, юллама белән Түнтәр авылына килгән. Шунда Рәшит абый белән танышканнар.

– Рәшит ул вакытта Казан дәүләт авыл хуҗалыгы институтының соңгы курсында укый иде, – дип искә алды Зәйтүнә апа. – Танышкач та озак тормадык, никах укыттык. Кулына диплом алгач, Рәшитне агроном итеп Биектау районына җибәрделәр. Шуннан бирле бу як кешеләре без.

Яшь гаилә – Мөбәрәкзядиннар – Чыпчыкка килгәндә, «Дружба» совхозы инде оешкан була. Аның җитәкчесе, алга карап эш йөртә торган директор Мансур Билалов, яшьләрне бик җылы кабул итә. Гомумән, директор совхозга килгән һәр гаиләне колач җәеп каршы ала. Бу аңлашыла да: совхоз зур, җирләр күп, димәк, эшче куллар кирәк. Шуңа да яшьләрне кызыксындыру макса-

– Танышкач та озак тормадык, никах укыттык, – ди Мөбәрәкзядиннар.

Мөхәммәдиевлар оныклары белән.

тыннан, җитәкче, иң беренче эш итеп, Чыпчыкта ике катлы йортлар салдыра башлый.

– Чыпчыкка килгәч тә, ике катлы йортларның берсеннән безгә фатир бирделәр, – дип искә ала ул елларны Зәйтүнә апа. – Тик без анда озак яшәмәдек, үзебезгә йорт сала башладык. Авыл җирендә торып ничек фатирда яшәмәк кирәк? Балаларны башлы-күзле итәсе булыр, дидек. Кысан фатирдан ничек чыгарып җибәрербез, дип, көн саен иремә әйтә килдем...

Башта Мөбәрәкзядиннарга җир бирергә теләмиләр. Янәсе, бер кеше йорт салып чыкса, бүтәннәр дә кызыгыр, дип уйлый җитәкчелек. Ләкин югары белемле агроном сүзендә нык тора – авыл башыннан җир ала. Һәм үз көче белән йорт сала башлый.

«ХОРОШО ПОЁШЬ!»

Чыпчык авылы җитмешенче елларда әнә шулай җанлана. Ел саен егермеләп яшь гаилә килеп урнашып тора. Араларында татарлар күп була. Арча, Балтач, Саба, хәтта Казаннан кадәр бирегә күченеп киләләр. Гел рус телендә аралашкан авыл акрынлап «татарчалаша». Үз өйләрен салып чыгучылар да елдан-ел арта.

Җирле халыкның тормышы яхшыра. Совхоз әйбәт хезмәт хакы түли, авыл гөрләп тора. Тик... татарлар пошаманга төшә – мөселман зираты юк. Инде якын-тирә татар авылларда мәчетләр салалар, ә биредә Корбан, Ураза гаетен укырга да урын юк...

– Татарлар вафат булгач, кайда җирләдегез? – дим Рәшит абыйга.

– Кешеләрне, үлгәч, туган җирләренә алып китеп җирлиләр иде. Күрше Байкал авылында да күмгәләдек. 1999 елда татар зираты өчен бер гектар җир бирделәр. Авыл халкы ярдәме белән аны яшел калай белән әйләндереп алдык. Капка, кирәк-яракларны саклау өчен йорт та эшләп куйдык. Район башлыгы безнең авылда ике тапкыр семинар үткәрде. Чыпчык зиратын башка авылларга да үрнәк итеп куйды. Ел саен 1 майда барлык мөселманнар да җыелып өмә үткәрәбез. Читтән дә кайталар.

Инде зиратлы булгач, авыл халкы, мәчет кирәк, дип җилкенә башлый. Һәм теләкләренә ирешәләр дә!

– 2008 елда мәчеткә нигез салынды, – диде Зәйтүнә апа. – Кызыбыз Мәликә бер иганәче тапты. Безнең авыл кешесе түгел үзе, тик аның күңелендә Аллаһ йорты салдыру теләге булган. Шуңа да безнең авылны мәчетле итәргә ярдәм итте ул мәрхәмәтле кеше. Дөрес, авыл халкының аерым кешеләрнең дә көче күп керде.

Озын сүзнең кыскасы, Чыпчык халкы шулай мәчетле була. Йөз квадрат метрлы Аллаһ йорты бүген юл кырыеннан ук балкып тора. Бу урында шуны да әйтим: Чыпчыкта яңа чиркәү дә бар. Аны элеккеге урынында төзегәннәр. (Совет чорында чиркәүне ишкән булалар.) Нәтиҗәдә, бер авылда ике гыйбадәтханә халыкка тыныч кына нур тарата.

– Руслар, башка милләт вәкилләре белән бик тату яшибез, – диде авылның мулласы Рәшит абый. – Мәчет салганда да ислам динендә булмаган авылдашлар ярдәмгә килде. Мәчеттән азан әйтеп кайтканда, руслар: «Ай, бабай, хорошо поёшь», – дип калалар. Динебезгә, үзебезгә дә хөрмәт белән карыйлар. Хәер, без дә шулай. Бер-беребезне дини бәйрәмнәр белән котлауны әйткән дә юк. Күчтәначен күтәреп, иң беренче рус күршең керә.

ГАРМУНЧЫ УМАРТАЧЫ

Алда әйтелгәнчә, Чыпчыкта яшәүче татар гаиләләренең күбесе җитмешенче елларда күченеп килгән кешеләр. Ирле-хатынлы Мөхәммәдиевларның исә тарихлары бүтәнчәрәк. Гаилә башлыгы Исмәгыйль абыйның үсмер еллары күрше Байкал авылында узган. Инде гаилә корганнан соң, Чыпчыкка күченгәннәр. Әлеге дә баягы теге ике катлы йортларга кызыгып килгәннәр.

– Тумышым белән Спас районыннан мин, – дип сүзен башлады Исмәгыйль абый. – Әти умартачы иде. Миңа ун тулган елны Байкалга – умартачы йортына килеп урнаштык. Әти шул ук елны йорт салып чыкты. Йөзләгән баш умарта әтигә дә, әнигә дә җитте. Әле мин дә кортлар янында йөрдем.

Исмәгыйль абый өчен Чыпчык ят түгел, бишенчедән сигезенчегә кадәр биредә укыган ул. (Байкалда башлангыч мәктәп кенә булган.) Инде кулына диплом алып, гаилә коргач, тормыш аны янә үсмер чагы үткән якка кайтара.

– Фирдәвес белән гаилә коргач та, бер елдан артык Казанда кеше фатирында яшәдек. Чыпчыкта бушка фатир бирәләр дигәч, 1974 елда кайтып киттек. Фатир дигәннән, егерме алты квадратлы, бер бүлмәле торак иде инде ул. Ике бала белән яшәргә бик авыр анда. Шуңа да биш елдан соң бу нигезгә йорт салып кердек. Ул вакытта монда кыр иде. Әти мәрхүм умартачы бит: «И улым, бигрәк җилле урын икән. Кортлар асрый алмассың инде», – дип, чын-чынлап борчылды.

Тик Исмәгыйль абый сер бирми – ата-бабасының шөгылен дәвам итә. Бүген дә ихатасында ике оя кортлары бар.

– Соңгы елларда кортлар бик үлә шул, – диде, уфтанып, әңгәмәдәшем. – Тирә-як авылларда яшәүче умартачылар да шулай ди. Кырга агулы ашламалар сибәләр, бөтен сәбәп шунда. Элеккеге кебек тынычлап корт асрап булмый хәзер. Оясыоясы белән үлгәч, күңел төшә. Бүтән кортлар аласы да килми...

Мөхәммәдиевлар бер кыз, бер ул тәрбияләп үстергән. Үзләре кебек үк зыялы, тәртипле балалар. Исмәгыйль абый авылның атаклы гармунчысы.

– Чыпчыкка килгәнемә кырык биш ел булды, – диде Гөлфия Хәйретдинова.

Бүген дә сәхнә, табын түрендә. Фирдәвес апа матур җырлый. Дөрес, иреннән аермалы буларак, хәзер сәхнәдә чыгыш ясамый инде.

– Яшьләргә юл бирдек, – дип елмайды ул.

– Тумышыгыз белән кайсы яклардан, – дип кызыксынам хуҗабикәдән.

– Лаеш районының Татар Янтыгы авылыннан. Туган авылдан киткәнгә илле ел була инде. Гомер буе Чыпчыкта яшәгән кебек хис итәм үземне. Без килгәндә биредә капкалы йортлар да аз иде. Руслар капка-койма куеп бик азапланмыйлар бит.

– Гаҗәп, капкасыз йортларны күрмәдек. Гомумән, кайсында руслар, кайсында татарлар яшәгәнен белеп тә булмый, – дим.

– Хәзер шулай ул. Җитмешенче елларда нык сизелә иде. Бездә бит күршеңә карап эш йөртү гадәте бар. Йортлар сала башлагач, руслар да безнең кебек капка-койма ясады, тирә-якны пөхтәләделәр. Безнең ике якта да руслар яши. Күз төшерерсез, бөтен җирләре ялт иткән. Тәртипле, зыялы кешеләр.

– Әйе, – дип сүзгә кушылды Исмәгыйль абый. – Күршеләребез бик әйбәт. Көн саен кич белән бергә йөрергә чыгабыз. Берәр йомыш төшсә дә, иң беренче эш итеп, алар капкасын шакыйбыз.

«ИШЕК БИКЛӘШ ЮК ИДЕ...»

Заманында барлык яшьләрне үзенә җәлеп иткән йортларны да карап чыктык. Гөлфия Хәйретдинова шундый торакларның берсендә яши. Җитмеш дүрт яшендәге әлеге ханым чәч, каш ясамыйча, кибеткә дә чыкмый икән.

– Чыпчыкка килгәнемә кырык биш ел булды, – диде Гөлфия апа. – Казанда туып-үскән кыз мин. Кечкенә кызым белән шушы ике бүлмәле фатирга күченеп килдем. Кызым хәзер Коркачык станциясендә мәктәптә эшли – балаларга биология фәнен укыта.

Гөлфия апа күп еллар Мүлмә авылында кибетче булып эшләгән. Лаеклы ялга чыккач, үзе өчен яңа дөнья ачкан – бәйли, картиналар ясый. Җәй буе бакчасында яши икән, көзгә кергәч, фатирына кайтып, кул эшләренә тотына.

– Тик тора алмыйм, эчем поша, – ди Гөлфия апа.

– Бу безнең китапханәнең иң күп укучысы, – дип сүзгә кушылды Чыпчык авылы китапханәчесе Фәния Әглиуллина. – Гөлфия апа бик күп укый. Кая барса да, китаплар алып кайта. Мәдәният йорты фойесында аның кул эшләреннән күргәзмәләр ясыйбыз. Балаларга бәйләү серләрен дә өйрәтә.

– Ә сез бәйләргә кемнән өйрәндегез? – дим Гөлфия апага.

– Әнинең апасы бик оста иде. Ун яшемдә бәйләргә ул өйрәтте. Дөрес, кулга энә тотмагач, яшьлектә өйрәнгән тәҗрибәм онытыла башлаган иде инде. Тик, утыргач, тиз искә төште.

Гөлфия апа кул эшләрен күбесенчә бүләк итәргә ярата икән. Дөрес, бер өлеше үзендә дә калган. Стенада картиналары эленеп тора, бәйләнгән карават япмалары да бар.

Инде ул яшәгән фатирга килик. Аш бүлмәсе кечкенә генә – 6 квадрат метр тирәсе. (Хәер, ул заманда барлык йортлар да шулай төзелгән.) Ике бүлмәле фатирның зурлыгы кырык квадрат та юк. Аңлашыла ки, кырык ел элек төзелгән йорт шактый таушалган кыяфәттә.

– Миңа җитә, – диде Гөлфия апа. – Зур гаилә белән яшәргә кыенрак инде монда. Әмма без бик күңелле яшәдек. Балалар үскәндә йорт гөрләп тора идек. Ишек бикләш тә юк иде. Хәзер инде йорт белән бергә кешеләр дә картайды, күбрәк өлкән яшьтәге кешеләр калды монда.

...Менә шундый ул Чыпчык. Мәчете, чиркәве дә булган күпмилләтле сирәк авылларның берсе. Толерант яшәүнең чын үрнәге. Сокланып та, азрак гаҗәпләнеп тә кайттык. Теләк бер – ике милләт гомергә шулай тату яшәсен, бер-берсенә булган ихтирамны балалар да дәвам итсен. Хәер, шик юк, оясында ни күрсә, очканында шул була, диләрме әле? Балаларның дуслыгы мәктәп эскәмиясеннән үк башлана бит.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

Фәния Әглиуллина, Чыпчык авылы китапханәчесе:
– Казан ханлыгы чорында Чыпчыкта татарлар яшәгән. Ләкин Иван IV гаскәрләре чукындыру сәясәте алып бара башлагач, җирле халык тау-таш арасына күченгән. Ә бу җирләргә, үз чиратында, руслар күченеп утырган. Тик авылның исемен үзгәртмәгәннәр, бары «Чыпчуги» дип руслаштырганнар гына. Авылның исеменә килгәндә, ул бик борынгы исем. Казан ханлыгы чорында яшәгән татарлардан калган дип карала. Мөгаен, Чыпчык исеме кош белән бәйледер.

facebook.com/protatarstan

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН TATARSTAN

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

Реклама 16+

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

Качману Сочельнигы.
Татарстанның Лаеш районы
Рождествено авылы.

Татарстанда 1 501 369 рус кешесе яши
(2010 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча).

2021

**ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ**

Фото: Фанил Марсетдинов

Мариларның Шорыкйол бәйрәме.
Татарстанның Кукмара районы Починок-Кучук
авыл җирлеге.

Татарстанда 18 848 мари кешесе яши
(2010 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча).